Кәүсәрия Шафикова

# Күз яшьләрең — көмеш тамчы



Парчалар

Нәсерләр



Кәүсәрия Шафикова

# Күз яшьләрең — көмеш тамчы

*Нәсерләр, парчалар*

УФА
«КИТАП»
2001

ББК 84 (2-Рус-Тат)
Ш 30

**Шафикова Кәүсәрия**

Күз яшьләрең — көмеш тамчы. Нәсерләр, парчалар. Уфа: Башкортстан «Китап» нәшрияты, 2001. — 144 бит.

Кәүсәрия Шафикованың исеме укучыларга күптән таныш. Шагыйрәнең фаҗигале язмышы да мәгълүмдер, шәт: Корчагин, Маресьев, үзебезнең Ибраһим Гыйззәтуллиннарның батырлыгын кабатлап яши ул. Аның бу китабына төрле темаларга язылган нәсерләре, парчалары тупланды. Әсәрләрдә замандашларыбызның күңел дөньясы, кичерешләре, хис-тойгылары тормышчан күренешләрдә ачыла. Язмыш тәкъдире белән нинди генә хәлләргә юлыкканда да, матурлыкны күрә, яшәү ямен аңлый белергә чакыра язучы. Аның йөрәгеннән тамган тетрәндергеч моң тамчылары беркемне дә битараф калдырмас, мөгаен.

ТП — 97

ISBN 5-295-02525-X

© Шафикова К. Ф., 2001



## *Җир шары*

Илдар төрле төстәге пластилинны бергә кушып түп-түгәрәк итеп йомарлаган да, кулында әйләндереп-әйләндереп, миңа күрсәтә. Мин аны йомры күмәч ясаган дип торам, ә ул: «Бу — Җир шары!» — ди. Әйе, игътибар белән карасаң, Җир шары картасына охшаган икән.

— Менә бу яшел җире — урман, — ди Илдар. — Анда куяннар да, аю, бүреләр дә яши. Безнең урмандагы кебек кошлар да сайрап тора, күбәләкләр оча, тәмле җиләкләр пешә, матур-матур чәчәкләр үсә. Ә бу зәңгәре — зур балыклар йөзә торган диңгез. Сарысы — безнең авыл кырындагы арыш басуы. Анда комбайннар да бар. Бу кара урын — зәңгәр тракторы белән Фәнүс абый сөргән җир!

— Ә бу кызылы нәрсә? — дим.

— Бу — канлы җир, — ди Илдар. — Сугышта күп кеше үлгән. Яраларыннан аккан кан туфракка сеңгән дә, ул шуңа кып-кызыл булып калган.

Илдар кулындагы бәләкәй туп кадәр пластилинны — Җир шарын кулыма алам. Әйе, Җир шарыбыз канлы шул. Әле мәктәпкә дә йөрмәгән Илдар сугыш турындагы кинофильмнар карамаса, сугышта бер кулын яки аягын калдырып кайткан бабайларны күргәне булмаса, Җирнең канлы икәнен белмәс иде, әлбәттә. Без дә, сугыштан соң туган буын, сугышның никадәр коточкыч икәнен киноларда күреп кенә, китаплардан укып кына беләбез. Һәм без сугышны кайтмый калганнарның һаман да сандык төпләрендә сакланган соңгы хатларында, ул, хәтәр елларда кулларына «кара кәгазь» алган аналар, тол хатыннар күз яшендә күрәбез. Әледән-әле апаабыйларның: «Мин әтиемне күреп белмим, сугыштан кайталмаган!» — дигән сүзләрен ишетеп торабыз. Бу сугыш тавышы булып ишетелә. Җир-күкләрне тетрәткән ул тавышның күңелләрдә тынганы юк әле. Тәннәрендә сугыш ярасы йөрткән карт солдатның ыңгырашып сызлануы безнең күңелләргә сугыш куркынычы булып күчкән. Җир шарыбыз турында, кешелек язмышы турында уйлый-уйлый, пластилин Җир шарын кулымда әйләндерәм. Җир йөзендә сугыш афәтләре һаман да бар шул. Бүген дә кешеләр яралана, бүген дә кешеләр үлә.

Илдар бүгенге дәһшәтле бәрелешләр турындагы документаль фильмнарны да үткән сугыш күренешләре дип карый. Ул куркыныч үткән дип уйлый. Заводларда бары тик матур машиналар, көчле тракторлар, зәңгәр күк йөзенә ак сызык

сызып очкан зур самолетлар гына эшләнә дип беләм, атом кораллары да эшләнгәнен белми ул. Якты дөньяны челпәрәмә китерергә әзер торган явыз бәндәләрнең дә барлыгын белми. Ә мин аның киләчәге өчен борчылам. Дөнья хәлләре тынычланырга ирек бирми.

— Бу чынлап та Җир шары, — димен пластилин шарны Илдарга биреп. — Җир шары бик кадерле. Утта да янмасын, бозга да туңмасын, берүк.

Илдар башка вакыттагы кебек сораулар яудырмады, Җир турындагы уйларымны бүлдерәсе килмәгәндәй, янымнан тыныч кына уенчыклары янына китеп барды. Балалар кулындагы матур уенчыкларны җил-давыллар тартып алмасын, шат уйнап үссеннәр сабыйлар. Җиребезне алар бәхете өчен имин саклыйсы иде.

## *Йөрәкләргә дулкын кага*

Илләрдән илләргә күчеп дөнья әйләнәсең, дулкын. Ярсып ярларга килеп кага торган, диңгез, океаннар өстендәге корабларны чайкалдырып тирбәткән гади дулкын түгел, дөнья халыклары йөрәгенә каккан дулкын син! Дөньяга иминлек теләүче халыкның күңел яктысыннан, йөрәк җылысыннан хасил булган Тынычлык дулкыны! Изге ният белән кузгалдың, дулкын! Син көчле-куәтле, синең шавыңда көрәш авазы: «Җир шарында атом коралларына, гомумән, бер генә сугыш коралына да урын булмасын! Җирдә кеше яшәсен, тормыш чәчәк атсын! «Шушы сүзләрне миллионнарча кабатлаудан яралган дулкын син, Тынычлык дулкыны! Без, кешеләр,

сиңа ышанабыз, син сугыш афәтләренең юлын кисәчәксең. Җирдә атом фаҗигасе кабатланмаячак. Бар дөньяга ишеттереп Хиросима: «Атом фаҗигасенә юл куярга ярамый! — дип чаң суга. — Ярамый, ярамый, ярамый!...» Кешелек дөньясына тынычлык кирәк, ул тынычлык даулый. Бүгенге көн беркемне дә тынычлыкта калдырмый, күпне күргән, өлкән яшьтәме ул, үсеп кенә килгән буынмы, һәркем тынычлыкны яклап тавыш бирә. Дуслык кабызган учакларда бомбалар, атом ракеталарының макет, рәсемнәре яндырыла. Җир шарын көл итәргә уйлап табылган бөтен кораллар Җир йөзеннән юк ителәчәгенә ышаныч арта бара. Син, тынычлык дулкыны, Җирдәге бөтен пычраклыкны юып үт, бозыклыкны җимереп ташла. Мәңгелек бул, дулкын! Дулкын өстендә тирбәлгән Җир шарында гүзәллек иҗат итеп Кеше яшәсен!

## *Табигать һәм кеше*

Сүз дә юк, матур син, табигать! Һәр мизгелең үзенчә гүзәл, сихри ямь белән тулы. Кеше синнән бер генә минутка да аерыла алмый. Сине күрмәсә, тоймаса, уйламаса — аңа яшәү юк! Без, кешеләр, синең сандугачлы, умырзаялы язларыңа, шау яфраклы, җылы яңгырлы җәйләреңә, мул уңышлы бакча-кырларга алтын нурларын түгеп килгән көзләреңә, ап-ак карлы кышларыңа гашыйк булып, шатланып, җырлап яшибез. Һәр мизгелдә күңелне иркәли алырлык наз бар. Битләрдән сөеп искән йомшак җилләрең, көч сынашырга дәшкән давылларың бар синең. Әйе, без, кешеләр, сиңа сокланабыз һәм синең

белән көрәшәбез, табигать! Синең матурлыгың белән беррәттән кыенлыклар китереп чыгарган көчең дә бар. Юл яздырыр бураннарың, үтә суыкларың, язгы ташкыннарың белән көрәшергә туры килә. Көйсез чакларың бар синең, эссеңдә куырылган яфрак-үләннәрне, иген басуларын күреп, җан көя. «Әй, яңгыркай, яусаңчы», — дип сәгатенә ничә тапкыр әйтәсең. Яңгырның бер тамчысы мең дәва булыр иде бит. Ә яңгыр юк та юк. Туфрак кибеп тузанга әйләнә бара, күңелне куркуга сала. Игеннәр генә һәлак булмаса ярар иде, дип көне-төне борчылып уйланасың. Җирне кочып җәелгән тамырларда яшәү дәвам итә, чөнки алар — Җир куенында. Җирне юкка гына Җир-ана димиләр бит. Җирдә тамырларга яшәү биргән бәрәкәт бар. Беркөнне коеп яңгыр ява. Җир яңгырны тыны белән тартып ала.

Аңлап бетерүе кыен сине, табигать. Аяз көннәр көткән чакта, яңгырларың белән жанга тиясең. «Басу тулы иген, харап кына итә бит, ай, туктаса!» Бу сүзләрне кайсыбыз гына әйтми микән?! Менә шунда инде киеренке көрәш башлана. Табигать кырыслыгы белән көрәшә хезмәт кешесе. Аңа уңышны ничек тә югалтусыз җыеп алырга кирәк: яңгыр түгел, таш яуса да, кырдагы игенне келәтләргә салырга тиеш ул. Тир түгеп үстерде бит, хезмәтенең җимешен күрергә, шатланырга аның хакы бар. Табигать куйган кыенлыкны җиңәчәк ул, уңыш кар астында ятып калмаячак!

Көзләр төрлечә килә. Кояшлы көзләрдә авыл хуҗалыгы эшчәннәренә: терлекчегә дә, игенчегә дә ул кадәр үк авыр булмый. Көзләр яңгырлы килсә — җиңеллекне көтмә инде. Терлекче тездән пычрак ярып маллары янына ашыга, иген-

че — кырларга юл тота. Авыл җирендә чын хезмәт кешесе, халыкка бәхет бирүче ил батыры яшидер ул. Әйе, бу чынлап шулай, авыл эшчәннәре җиң сызганып эшләмәсә, кыенлыклардан куркып калса, тормыш болай ук мул булмас иде. Тук халыкның күңеле көр, көннәре рәхәт үтә. Табигать куйган авыр сынауларны җиңеп чыга кеше. Тырыш хезмәте белән җиңә ул аны. Иң зур көч хезмәттә, аны җиңәр көчнең булуы мөмкин түгел!

## *Карлар булып явам*

Яз ае булса, гүзәл умырзая булып, туган җирем туфрагында тамырланып, якты кояшка үрелер идем. Язның назлы җилләрендә тибрәлә-тибрәлә, бар да ишетерлек итеп: «Кешеләр, күңелегездә яз кояшы балкысын, көннәрегез гөлчәчәкле болын кебек ямьле булсын. Еласагыз да шатлыктан гына елагыз, күз яшьләрегез яз тамчысы кебек саф булсын!» — дияр идем.

Җәй ае булса әгәр, гел җылы яңгыр булып түгелер идем җиремә. Бакчадагы түтәлләргә, иген кырларына, урманнарга, җиләкле аланнарга һәр тамчым шифа булыр иде.

Әгәр бүген алтын көз булса, бакчаларда алма булып пешәр идем. Әйе, алма булып пешәр идем дә, җәй буена хезмәт тирен җиргә тамызган уңганнар алдына өзелеп төшәр идем.

Кыш! Әлеге кыш аенда ап-ак карлар булып явам мин. Карлар булып җиргә төшәләм, агачларга бәс булып сарылам. Челтәр-челтәр кар бөртекләре мин, һава тулып җилфердим дә, иңнәргә, чәч-керфекләргә кунам. Яңа ел кары

ımин, миндә — аклык, миндә — сафлык, миндә — шатлык. Дуслык та, мәхәббәт тә саф булсын өчен ап-ак карлар булып явам мин бүген. Килер җәйләр шау чәчәкле, игеннәр тук башаклы булсын өчен карлар булып явам! Юлчыларның юлы — ак, уйлаган уйлар — якты, тормышка ашасы хыяллар җем-җем килгән йолдызлы кар өсте кебек матур булсын. Яңа ел туган минутларда яуган карлар дөньяга иминлек теләп ява. Теләкләр кабул булсын, дуслар. Амин!

## *Матурлык артканда*

Буранлы кыш үтеп, язның беренче тамчылары тама башлауга барыбыз да куанабыз. Яз — өлкәннәрнең дә, балаларның да чиксез шатлыгы, күңел бәйрәме.

Язның матурлыгы көн саен арта бара. Һава җылына, җилләр назлы исә, гөрләвекләр җырлый-җырлый ага бу көннәрдә. Тәрәзә башы саен күк күгәрченнәр гөрли, ялангач куакларга кунып чыпчыклар чыркылдаша. Тупыл башлары чопчобар — кара каргалар оя кора. Бу әле язның башлануы гына, алда әле аның шау-гөр килеп торыр чаклары. Сыерчыклар килгәч, елгаларда боз кузгалгач, басуга буразналар сызарга тракторлар чыккач, яз тагы да матуррак була. Карны тишеп чыккан беренче чәчәге — умырзаялары, ямь-яшел, хуш исле бөреләре, җылы ләйсәне бар язларның. Хәер, язның матурлыгын санап кына бетерерлек түгел. Аны һәркем үзенчә күрә, тоя, ишетә. Язгы аваз шагыйрьгә шигырь булып ишетелсә, композиторга ул җыр булып яңгырый.

Язның янә бер яме — кошлар. Капка баганасына кадакланган оясы түбәсенә кунган сыерчыкларның бер сызгырып җибәрүе генә дә ни тора! Шуңа да яз дигәч, тәүдә ерак сәфәр киткән канатлы дусларыбыз искә төшә. Яратабыз кошларны, кайтуларын сагынып көтәбез. Әле мин кошлар турында «дусларыбыз», «яратабыз», дидем. Дуслык, ярату турында сүз башлавым юкка гына түгел.

Кошның зәңгәр күккә күтәрелеп канат җилпи-җилпи очканын күзәтү, куакларга кунып иртә-кичен сайравын тыңлау, оясыннан егылып төшкән нәни кошчыкны яки имгәнгән кошны кызганып кулларыңа алу, җылы тыныңны өреп иркәләүләр генә — кошларны ярату түгел. Кошларны ярату — кошлар турында хәстәрлек, аларны көтеп ала белү. Бик ерактан, күпләребез китаплардан укып кына, кинофильмнардан күреп кенә белгән ерак илләрдән кайта бит алар. Юллары ерак, авыр кошларның. Ераклык та, авырлык та куркытмый аларны. Кайталар, туган-үскән, канат ныгыткан җирләрен сагынып кайталар. Онытмыйк без кошларны, каты бәгырьле булмыйк, кунак көткән кебек көтик без аларны. Алар безгә җыр алып кайта, без аларның җырларын тыңлый-тыңлый язларда, җәйләрдә яшибез.

Тышта яз. Матурлыкка соклана белү генә аз, матурлыкка күңел матурлыгыңны өсти белсәң, тормыш тагы да гүзәлрәк булыр. Кошлар кунып сайрар ботакларны сындырмыйк. Табигатькә карата мәхәббәт шаулап чәчәк атсын.

## *Апрель*

Тәрәзәмне ачып куйдым әле — җил керсен. Ап-ак пәрдәләрне җилфер-җилфер китереп уйнасын әле апрель җиле.

Ачык тәрәзәдән бөркелеп кергән яз һавасы күкрәгемә тула, сулыш иркенәя, рәхәтлекнең чиге юк. Апрель җиле кебек саф, йомшак җил булмыйдыр ул. Ә кояш апрельдә генә шулай якты буладыр. Күк йөзе нинди матур! Ак болыт кисәкләре күк йөзенә ямь генә бирә. Күленә кайткан аккошларны хәтерләткән ак болытлар ләйсән яңгыры бит ул, шатлык яңгыры. Беренче яңгырның көмеш тамчылары төшүгә яшь үлән чыкты да инде. Җир яшел күлмәген киде. Кайсы гына якка карама — агачлар, агачлар. Агачларда берьюлы миллион бөре ачыла, һавада — бөре исе. Бөреләр ачылганда табигатькә өр-яңадан гашыйк булам мин. Шушындый матур көннәре булган өчен әллә нинди хәлләргә калганда да дөньядан туймыйм, яшәгән саен яшисем килә.

Апрельдә кайткан кошлар белән куак аралары тулган. Кайда да сайрый алар, куак арасындагы оясы янында да, тал-тирәк тибрәтеп тә. Яңа язга яңа җыр алып кайта алар. Онытылып бер тыңласаң, рәхәтлектә бер гомер яшәгәндәй буласың. Бүген үзгәрәк, кошлар бүген һәрвакыттагыча сайрамый, алар шигырь сөйли бүген. Әйе, әйе, шигырь сөйлиләр. Тирәктәге кошлар гына түгел, тәрәзә кәрнизендәге күгәрченнәр дә, искән җил дә, яшел үлән, бөреләр дә, бакча артында гына чылтырап агып яткан елга да, өстәлемдәге савытка куелган ап-ак умырзаялар да, тәрәзә төбе саен чәчәккә күмелеп утырган гөлләр дә шигырь сөйли кебек бүген.

*Яз елмая күктә кояш булып,*
*Яз елмая җирдә гөл булып.*
*Яз елмая яңа шигырь булып,*
*Яз елмая якты көн булып.*
*Яз елмая кайнар сөю булып,*
*Яшәү булып җиргә килә ул.*
*Яз — ул яшьлек, яз ул — күкрәп яши,*
*Елый белми, бары көлә ул.*

Бүген — шигърият бәйрәме. Дөнья шигырь тыңлый. Шигъри аваз җирләрне, күкләрне яңгырата. Чөнки бүген — 26 нчы апрель, сөекле шагыйребез Габдулла Тукай туган көн. Шигъриятне үлемсез иткән ул.

Кояшсыз да, хыялсыз да, җырсыз да яшәү мөмкин түгел. Апрель җилләренә йөземне куеп, мин шул хакта уйлыйм һәм тирә-ягымны күзәтәм, тыңлыйм. Бу җырлы көндә басуга тырмага чыккан тракторлар гөрләвендә дә хезмәт җыры, киң кырлар җыры аеруча дәртле булып ишетелә. Күңелемдә канатланган җыр-тургайларын кырларым күгенә очырам.

*Җыр-тургаем, күккә күтәрел дә*
*Матурлыгын җырла җиремнең.*
*Бездә язлар шулай ямьле була*
*Бәйрәмнәре белән Илемнең.*

## *Яз бәйрәм булып килә*

Ярсу ташкыннары, җырчы гөрләвекләре, яшел бөреләре белән Җиргә янә яз килде. «Яңа яз, якты яз, кешелек тормышына бәйрәм китергән яз, саумы! — дип бар тавышка дөнья яңгыратып эндәшәсе килә бүген. Кырык биш ел элек

яз илгә Җиңү белән килде. Язның шау-шуына, сайрар кошлар тавышына «Ура!» тавышлары килеп кушылды. «Ура!» — диде газиз балакае яу кырында ятып калган ана да, аяк-кулы өзелгән, ярасыннан кан саркып торган солдат та. Күз яшьләре белән әрнеп, сулкылдап Җиңү язын каршы алды халык. Сөйгән ире хәбәрсез югалган тол хатын да, «Фашистларны үтереп бетереп кайта минем әти!» — дип, юкка гына өметләнеп йөргән бала да «ура!» кычкырды ул язда. Җиңел генә килмәде Җиңү: кан, күз яше белән килде ул. Асыл ирләр, сылу кызлар йорт-илләренә әйләнеп кайталмады.

Кырык бишенче тапкыр инде яз бәйрәм булып килә. Ату, шартлау тавышлары онытылып бетәргә дә тиеш кебек тә бит, юк, онытырга мөмкин түгел ул дәһшәтле елларны. Сугыш җимергәнне төзәтеп бетереп булмый һаман, күргәннәрне, кичергәннәрне онытып булмый. Ялгызлык, ятимлек булып уелган бит ул җаннарга. Сугыш! Нинди коточкыч! «Сугыш була күрмәсен, сугыш була күрмәсен!» — дип тибә йөрәкләр. Теләкләребез кабул гына булсын берүк, кабат давыл купмасын! Язлар җитү белән Җир йөзе яшәрә, күңелләр көрәя. Йөзләрдә — елмаю, кулларда — чәчәк бәйләме. Чәчәкләр — җиңү белән кайткан солдатларга, чәчәкләр — яу кырыннан кайтмый калган якыннарыбызның исемнәре язылган һәйкәлләргә. Бәйрәм көн булса да, өзгәләнеп яшен түгүчеләр бар шул бүген дә. Кайтып килгән кошлар төркемен күргәндә: «Кошкайларым, көзен киттегез дә, язлар җиткәч кайтып киләсез. Ә ул кайтмады. Көт, кайтырмын, диде дә, кайталмады. Мин көттем, 45 ел буе көттем. Һаман көтәм, кайтмаячагын белсәм дә, көтәм шул!» — дип бәгырьләре телгәләнә

аларның. Язның иң күркәм чәчәкләре мәхәббәтләрен саф килеш саклап, күп еллар буе көтә белгәннәр өчендер, мөгаен!

## *Һәйкәл янында*

Менә, ал байракларын җилфердәтеп тагын килеп җитте 9нчы Май! Кайчандыр илебез күген каплаган кара болытны таратып, җылы җилләр искән көн бу. Тилмереп көтеп алган көн! Мәңгелек нурлары белән күңел дөньяларын балкытып чыккан ул көнне кояш. Авыр яралысы да, аяксыз-кулсызы да, егерме миллион арасында якыннарын югалтучылар да шатлыктан елаганнар ул көнне. Юкка гына кан коелмаган бит, югалтулар юкка гына булмаган.

*Дошманга бирмәдек, гөлләргә бизәдек,*
*Күтәрдек даннарын Ватанның.*

Бүген бәйрәм! Кулларына чәчәкләр тотып һәйкәл янына килүчеләр арасында фашист пулясыннан һәлак булган солдатның әнисе, хәбәрсез югалган солдатның хатыны, танкы эчендә янып һәлак булган солдатның сөйгән кызы, әсирлектә җәзалап үтерелгән солдатның улы, дошман самолетларын бер-бер артлы кара төтен итеп күккә очырган, ләкин үзе дә һәлак булган очучының оныгы һәм сугыш кырындагы коточкыч хәлләрне үз күзләре белән күреп, дошманны үз өнендә дөмектереп, илгә Җиңү белән кайткан солдат үзе да бар. Һәйкәл янына килгән һәркем күңеленнән һәлак булган якын кешесе белән сөйләшә. Без аларның сөйләшкәнен ишетеп торабыз.

Бар дөньяга ишетелерлек итеп ана йөрәге тибә.

— Син беркайчан да кайтмассыңмы инде, улым?

— Кайталмыйм, әнкәй, кайталмыйм.

— Мин картайдым, улым, бик картайдым.

— Мин кайгылы иттем, сине, әнкәй, мин картайттым. Үлмәгән булсам, син әле япь-яшь булыр идең, әнкәй. Яраларым авыр иде шул...

— Синең яраларың минем йөрәгемдә, балам. Беләм нинди яра икәнен. Төзәлми торган яра — сугыш ярасы бездә, улым.

— Елама инде, әнкәй, елама. Озаграк яшәргә тырыш.

— Яшәдем, улым, сине көтеп яшәдем.

— Ачуланма, әнкәй, көткәнсеңдер.

— Ачуланмыйм, улым. Син туган илгә азатлык яулаганда һәлак булдың бит. Ил онытмый сезне. Сез бит барыгыз бергә 20 миллион. Рәхмәт сезгә, һәр тамчы каныгыз Җиңүгә илтте. Бүгенге рәхәт тормыш өчен рәхмәт.

Инде ир белән хатын сөйләшкәнне ишетәбез:

«Хәбәрсез югалды» дигән хәбәр «үлде» дигән хәбәрдән дә авыррак икән. Үле туфрагы суыта, диләр бит. Ә мин сине әле дә көтәм.

Кыз баланың беренче хисләре кульяулыкка чәчәк итеп чигелә. Сугышка киткәндә синең кульяулык почмагына җыр да язылган иде:

*Очрашмабыз дигән шомлы уйлар*
*Килмәсеннәр синең башыңа.*
*Син кайтканда, алсу чәчәк тотып,*
*Мин чыгармын синең каршыңа.*

Син дә миңа хатларыңны җыр белән яздың:

*Әгәр көтсәң, сандугачтай сайрап,*
*Уятырмын язгы таңнарда.*

*Өметеңне өзмә, син көт кенә,*
*Булсам да мин әллә кайларда.*

Көттем. Дөньяда юк икәнеңне белгәч тә өметемне өзмәдем. Кулсыз-аяксыз кайтсаң да, без бергә булыр идек. Авырлыкларны без мәхәббәтебез көче белән җиңәр идек. Кайталмадың...

Әтисе фронтка киткәндә 5 яшьтә калган малайның күңелендә сугыш яши.

— Хәтеремдә, әткәй, син мине кулларыңа күтәрдең дә: «Улым, мин сугышка китәм. Син зур үс. Мин тиз кайтырмын», — дидең. Хатларың килгәнне дә хәтерлим. Сугыш беткәч: «Нигә һаман минем әткәй кайтмый», — дип, әнкәйнең алдына капланып елаганым да хәтеремдә.

— Безне тереләй күмделәр, утта яндырдылар, астылар, суйдылар, башларыбызны балта белән чаптылар. Безнең үлем әнә шундый булды, улым.

— Нигә әткәй, нигә шулай җәзаладылар сезне?

— Туган илне сатмаган өчен, улым.

— Туган илне саталармыни, Туган ил бер генә бит?!

— Сатканнар да булды, улым. Без сатмадык. Илне сатсам, син мине сагынып хәтерли алмас идең. Син минем белән горурлана аласың.

*Соңгы хатлар — өчпочмаклы хатлар!*
*Исән әле алар бүген дә.*
*Саклана лар алар, саклана лар*
*Яу ярасы булып күңелдә,*
*Дәү әниең сандык төбендә.*

Сандык төбендәге хатларны инде оныклар алып укый.

— Дәү эти, мин сине дәү әнием сөйләве буенча беләм. Син әйбәт кеше булгансың. Мин дә синең кебек очучы булырга телим.

— Очучы бул. Минем дәвамым бул, кадерле оныгым. Тик сиңа тыныч, кояшлы күктә генә очарга язсын. Сезнең буын һәм сездән соңгы буыннар да сугыш күрмәсен. Илнең иминлеген саклагыз.

Күңелләр борчулы. Бигрәк тә сугышта булганнар тыныч йокы йоклый алмый бүген. Яралары сызлый, күргәннәре онытылмый. Киләчәкне уйлап борчылалар.

*Баш калкыта тагы кара елан,*
*Тешләрендә — зәһәр агуы.*
*Төшләрендә күрә тагы кеше*
*Һәлакәтле елан чагуын.*

Күкрәге тулы орден-медальләрен чыңлатып, сугыш һәм хезмәт ветераны һәйкәл янына килә. Кайтмый калган яудашларын искә ала ул. Чал чәчләрен сыйпап, майның йомшак җилләре исә. Балаларына, оныкларына:

*Атылганнар, асылганнар безгә*
*Гамьсез булырга соң кушамы?*
*Уяу булу кирәк кешелеккә,*
*Йокламаган чакта дошманы, —*

дип кабат-кабат әйтә ул. Аның күңелендә бер генә теләк, без барыбыз да шул теләккә кушылабыз.

*Үткәннәрнең кара кайгылары*
*Күз алдына килә күрмәсен:*
*Үлем бөркеп, атом тузаннары*
*Җир өстенә күтәрелмәсен!*

## *Алмагачлар чәчәк аткач*

Мөхтәрәмә карчык яз айларын көтеп ала. Бигрәк тә май аен, әллә нинди бер ашкыну, якты өмет белән көтә ул. Еллар гына түгел, бер кеше гомере үтте бит инде, барыбер элеккечә, яшь чагындагы кебек, буранлы кышларның тизрәк үтеп китүен, яз җитүен көтә. Инде ничәнче тапкырдыр сандыгын ача солдат хатыны, сандык төбендәге хатларны алып күкрәгенә кыса. Саргайган хатларны кулына алу белән иренең тавышын ишетә кебек: «Мин госпитальдә ятам, борчылма, ярам төзәлеп килә инде!» Мөхтәрәмә артык кайгырмый, ярасы төзәлә икән бит, исән, аллага шөкер! Янә иренең тавышы: «Мин янә сугышам, котлар очарлык хәлләр монда. Үләләр, бик күпләр кире кайталмаячак. Мөхтәрәмә кадерлем, син мине көт, өметләрне өзмик әле, мин кайтырмын кебек. Бишектә калган улымны баш очыма күтәреп шатланырмын әле мин. Улыбызны йөгереп йөри, сөйләшә, дип язгансың. Мин кайткан да хәбәр бирермен, каршы алырга басу капкасы янына икәүләп килерсез. Әле без ут эчендә!» Бу тавыштан соң ут җанны өтеп ала, сулыш алуы авыр булып китә, күкрәккә саф һава түгел, төтен, кан исе кереп тула сыман. Мөхтәрәмә карчык яулык очы белән күзләрен сөртә. Экраннардан сугыш турындагы кинолар караганда да елый ул. Ничек еламассың, хатларда да шулар язылган лабаса! Ире чынбарлыкта күргәнне ул кино итеп карый. Йөрәккәең ярылыр! Нишләп әле бөтен дөньяны ут алмаган, ничек туктатканнар ул вәхшилекне?

Менә бу хат иң зур өмет уятканы, әнә шул өмет белән яшәде инде Мөхтәрәмә һәм Мөхтә-

рәмә кебек тол хатыннар. Хатыннар гына түгел, ата-аналар, балалар өмет белән яшәде.

«Минем кадерлеләрем, Җиңү көне якынлаша! Исән-сау күрешербез дип ышанам. Сез дә ышаныгыз, без фашистны өненә куып китердек. Быелгы яз Җиңү белән килә, алмагачлар ап-ак чәчәккә төренгәч, бәйрәм итәчәкбез!» Менә шушы сүзләргә ничек ышанмассың?! Шатлыктан ярсып типкән иде солдат хатынының йөрәге. Әле дә элекке өмет яңара түгелме соң?

Язлар килгән саен, шулай өметләнеп, көтеп типте йөрәк. Тик солдат кына кайтмады шул, кайталмады. Үле хәбәре килсә дә, көттеләр аны, алмагачлар чәчәк аткан саен көтәләр. Мөхтәрәмә карчыкның чәчләренә алмагачның ап-ак чәчәкләре сибелгән кебек. Чәчләр агармаслык булдымыни: ялгызлык, ялгыз бала үстерү, илле ел буе әллә кайтыр дип өметләнеп көтү! Әйе, үлгәннәр кайтмый. Ә, бәлки, үлмәгәндер, авыр яралар алып озак дәвалангандыр, кайтыр юлы ураудыр? Җиңү якынлашканын белгән бит, җиңү язы килде, көтегез, дигән!

Җиргә бәйрәмле яз килде, илленче тапкыр килде ул. Илленче тапкыр Мөхтәрәмә һәм аның кебек көтә белгәннәр матур киемнәрен киенеп, урамга чыгалар. Сугыш яланында калганнар һәйкәленә чәчәкләр илтәләр алар, илгә иминлекләр тели-тели һаман юлларга карыйлар.

## *Уяу бул!*

Бишектә сабые бар ана тыныч йоклый аламы соң — төненә ничә тапкыр бүленәдер аның йокысы?! Тынгысыз көннәрен, йокысыз төннәрен

санамый ана кеше. Баласы өчен җанын бирергә әзер бит ул: бөтен авырлыкны иңнәренә алган, сабыр итә, түзә. «Тыныч йокымны балам үскәч йокlargмын», — ди ул, тик баласы тыныч йокласын, куркып, елап уянмасын берүк. Дөньялар имин булса, баласының шат-бәхетле булып үсәчәгенә ышана ана. Изге теләкләр теләп үстерә бит ул аны. Тормышны сөеп, аңа тик матурлык кына өстәп яшәүче кеше булуын тели.

Еллар үтә, әмма ана тыныч йоклый алмый. Ничек тыныч йокласын инде, улы ил чигендә сакта тора бит. Ана да улы белән бергә. Әледәнәле ана йөрәге еракларда хезмәт итүче улына эндәшә: «Улым, күз нурым, берүк әйбәт хезмәт ит. Мин синең белән горурланам: әнә бит нинди ил чиген ышанып тапшырырлык улым бар икән! Уяу бул, улым, тыныч илебезнең чиген үтеп керүче булмасын. Тормышыбыз яменә явыз җаннар кул сузмасыннар, бәхетебезне урламасыннар. Өстебез бөтен, тамагыбыз тук, киләчәгебез тагы да яктырак, матуррак булсын. Ә бу инде сезнең кулда, улым. Сез, ил сагында торучылар, һәрчак ил кушканны үтәсәгез, курку белмәсәгез, бәхетле тормыш дәвам итәчәк. Ил чиген җимереп, сугыш кермәсен берүк! Мин синең белән горурланам да, шул ук вакытта синең өчен борчылам да, улым. Исән-сау кайтып, туган җиреңә хезмәт итеп яшәгәнеңне күрә алсам иде. Менә шуларны уйлап, төннәр буе йоклый алмыйм мин.»

Менә шулай иле, улы өчен янып тибә ана йөрәге.

Күптәнмени әле улы йоклаган бишек янында ана үзе сакта тора иде. Менә улы ил, ана алдында изге бурычын үти. «Улым, уяу бул», — дип, өзгәләнеп тибә ана йөрәге.

## *Ай яктысы*

Әссәламегаләйкем, Сөембикә! Синең матурлыгыңны безгә дә күрү насыйп булды, аллага шөкер! Синең бүгенгедәй шат йөзеңне күреп яшәргә язсын, иншалла! Ничә еллар буе синең ак йөзеңә күтәрелеп карарга оялдык ич без, әйе, оялдык. Ә йөзең ак идеме соң?!

Караңгы күңелләрнең кара шәүләсе каралткан иде ич сине, көн дә күтәрелеп чыккан кояш та яктырта алмады синең йөзеңне, Сөембикә! Боек идең, авыр иде синең хәлең. Ничәмә-ничә еллар буе янына якын килеп хәлеңне белүче булмады. Көлмәдең син, үксеп-үксеп еладың, калфагыңдагы бизәкләр белән бергә гүзәллегеңне тәмам җуйдың. Ел саен килгән язлар тирәңә гөлләр сипсә дә, синең күңел күтәрелмәде. Караңгы төннәрне яктыртып ай калыккан чакларда авыр суладың, күзләреңә мөлдерәмә яшь тулды. Үткәннәреңне уйладың, хәтереңдә бар да яңарды. Үткәннәрең ал да гөл генә булмаса да, киләчәкнең коточкыч икәнен белеп тетрәндең син, Сөембикә! Йокымсырап барган кешелекне уятырга, упкынга төшеп баручы тормышны коткарып калырга кирәк икәнлеген искәрттең.

Туды шундый заман, кеше кеше икәнлеген онытты. Әйтерсең лә мәңгелеккә килгән бу дөньяга: алла дияргә гарьләнә, изгелек кылырга иренә. Җиргә тирен түкми ул, түкерә генә. Кулындагы ипиен бисмилла әйтеп каба белми, — өйрәтмәгәннәр. Теле — юк! Телен әллә йоткан, әллә чәйнәп түкергән. Ул бит матур итеп өздереп «әткәй», «әнкәй» дип тә әйтә белми, заманча: «па», «ма!» — дип эндәшә үзенә якты дөнья бүләк иткән ата-анасына. Әйе, монда ата-ана үзе

гаепле, кадерлеләрен заман кулына тапшырганнар.

«Динең, телең белән кеше син!» — Сөембикә, синең тавышың бу. Ишетәбез һәм күрәбез, манараңда алтын ай балкый. Мәңге шулай айлы бул, Сөембикә! Аебыз, Кояшыбыз алдында иманлы йөзебезгә тап төшермичә яшәүгә әйдә безне. Урлатма, кабат урлатма аеңны, Сөембикә, аең яктысы юлларга төшсен. Юлларында адашмасын кешелек!

## *Саумы, басу!*

— Саумы, басу, саумы, хезмәт мәйданы!

Бу сүзләрне кычкырып әйтмим мин, күңелемнән генә йөз кабат, мең кабат ярατып кабатлыйм. Юлларыңнан үткәндә җанымда чиксез рәхәтлек тоям. Кырларда эшләп йөрүчеләргә хәтта көнләшеп тә карыйм. Алар бит иртә таңнан кара төнгә чаклы синдә булалар, җаннары гел рәхәтлеккә генә тулыдыр аларның. Мин дә сиңа килəм, елына өч тапкыр. Килгән саен «Саумы» димен.

Беренче килүемдә киң кочагыңда язгы кояшка үреләүреләямь-яшел уҗым тирбәлә иде. Күк зәп-зәңгәр иде, тургайлар җырлап каршылады мине. Баш очымда тирбәлеп-тирбәлделәр. Матурлыгың күзләремне иркәләсә, кошлар моңы күңелемне назлады. Озак булдым синдә, күңелем булганчы. «Әле мин тагы да матуррак булачакмын, кил», — дип дәшеп калдың кебек. «Килмичә мөмкинме соң?! Килермен», — дидем мин һәм килдем. Диңгездәй дулкынланып каршы алдың. Алтын дулкыннарың йөгерешкәнен озак

карап тордым. «Диңгез күрергә еракка китә кеше. Менә ич ул диңгез, якында гына, авылым кырында гына, нигә аны әллә каян эзләргә», — дип уйладым мин. Арыш серкә очыра, бодай бөртеге шундый эре! Бәхет бит бу, кеше бәхете. Кеше бәхетле булса гына тормыш ямьле була. Мин ул көнне тормыш яме күрдем синдә. Юл буенда үскән чәчәкләрне кочагыма алып җырлый-җырлый кайтып киттем.

Бу килүем — өченче кабат һәм быелга соңгысы. Көн матур, кояш нурлары әлегә кызу. Тирә-ягымны күзәтәм. Йөгерек дулкыннар юк монда, әллә кая булганнар. Кошлар да дәртләнеп сайрамый. Монда бары зур-зур салам эскертләре күзгә ташлана. Бераз гына көз төсе, моңсулык бар синең кочагыңда. Юк ла, бу вакытлыча гына. Бушап калгансың — калсаң соң, күңел тулган ич: шатлык белән тулы күңел. Быелгы ел уңышы, игенченең түккән тире җыеп алынган. Киң бит син, чиксез кебексең. Бу җирең бушап калган булса да, уңыш җыю әле тәмамланмаган, комбайннар гөрләве ишетелә, соңгы бөртекләрне җыялар. Хезмәт мәйданында ярыш бара, бәхет өчен көрәш бара. Юк, синдә хезмәт шавы тынып тормый. Киләчәк өчен җиңнәр сызганулы, игенче кырдан кайтмый. Бер үк вакытта җыялар һәм чәчәләр. «Бушап калгансың», — диюем дөрес түгел, син беркайчан да буш булмыйсың. Куеныңда һәрчак орлык тамыр җәя. Беренче кар ямь-яшел уҗым өстенә төшәчәк. Ап-ак кар юрган ябынып озак йокларсың, басу. Язгы кояш көлүеннән уянып китәрсең дә тагын дулкыннар тирбәлер синдә. Мин килермен, тагын-тагын килермен. Саумы, басу, диярмен.

Кинәнеп әйтермен мин бу сүзне.

## *Уян, Җирем!*

Кар-юрганыңны ябынып кыш буена йокладың да, инде уянасың, Җирем! Сабый йокыдан уянганда кулларын сузып киерелә, өстендәге япмасын тибеп ача, аннары тавыш бирә. Синең дә уянуың бала уянуына охшаган, Җирем-Җиргенәм! Күңелләр генә ишетерлек итеп уянуыңны хәбәр итәсең. Юк, син ярсып кычкырмыйсың, Җир сабыр була шул. Сабыр гына, тын гына синең тавыш.

Җирем, язның көмеш тамчылары тыпылдап тамган тавышка уянасыңмы син, әллә гөрләвекләр җыры, ташкыннар шавы уятамы? Ерак илләрдән кайтып тирәкләргә кунган кошларның сайрап җибәрүе йокыңны бүлдерәме? Әллә тәүге күкрәүләр ачамы йокыңны? Беләм, Җирем, игенченең йөрәк тибешен ишетеп уянасың син! Игенченең Җиргә булган мәхәббәтеннән кайнарлана кояш. Кояш нуры Җиргә түгелә, кар эри, дөньяга яз исе тула. Яз һавасын сулый-сулый, кара туфраклы басуга чыга игенче. Туфрактан пар күтәрелүен күзәтә ул, үзе җиңнәрен сызгана, уйлары язгы көн кебек якты. Туфракка орлык күмелә. Орлык белән бергә маңгай тире дә күмелсә генә көткән уңыш булачагын яхшы аңлый игенче, шуңа да көчен кызганмый. Яңгырлар вакытында яумаса, төннәр кыраулы булса, игенче татлы йокысын йоклый алмый. Аның йөрәге туфракка яңа күмелгән орлык өчен сызлана.

Җирем, синең зәңгәр күлләрең, елга-диңгезләрең, урманнарың, горур тауларың, шаулап иген үскән киң кырларың, җиләк-алма бакчаларың тормышның иң асыл бизәкләре ләбаса!

Янма, көймә, тетрәп авыл-калаларны җимермә. Җирем! Матурлык бирер өчен уян. Мин — кеше, мин сине йокыңнан уятам!

## *Чын бәхет*

Зур бәхетнең ни икәнен беләсеңме син, очратканың бармы аны? Әллә дөньяда андый бәхетнең барлыгына ышанмыйсыңдамы? Ышан, бәхет бар, дөньяның үзе кадәр зур, чиксез ул бәхет. Кешегә гомер, тормышка ямь бирүче бәхет турында сүз кузгаттым, синең әле аны күргәнең булмаса, күрергә ашык. Әйдә, мин сине үзем белән алам.

Тасма юл сузылган, уңда да, сулда да дулкыннар чайкала. Иген кыры! Алтын басу! Башаклар тулышкан, учларыңа тамарга торган бәхет тамчылары! Менә шушында инде ул бәхет, шушында ул хөрмәтләп табын түренә куеласы, кулларыңа тотып ашыйсы ипикәй! Алтын-көмешләрең белән байлыгың ташып торсын, тәнең сызлау белмәсен, яныңда сөйгәнең булсын; юк, син, өстәлеңдә ипикәең булмаса, бәхетле булалмыйсың, бәхетең тулы булмый. Кояш та түп-түгәрәк булган өчен генә дөньяны шулай балкыта ала, бәхет тә шулай, тулы булса гына зур. Алай гына түгел әле, әзер икмәк ашау белән генә бәхетле булып булмый. Тир түгеп хезмәт күрсәткәннән соң ипикәй — тәмле, бәхетең зур була! Менә син хәзер бәхетнең иң-иң зурына ия булган кеше белән очрашасың. Әнә ул, басу корабында иген җыя, ил келәтләренә бөртекләп җыеп, бәхет тутыра игенче. Игенче — иң бәхетле кеше бүген. Син аның күзләренә кара, бәхете күзлә-

рендә балкый. Шуңа да ул бүген җырлый-җырлый уңыш җыя:

*Мин кырларда иген үстерәм,*
*Бәхет бирәм газиз халкыма.*
*Уңышларым артса ел саен,*
*Очар кошлар булып талпынам.*

Чын бәхетнең ни икәнен белдеңме инде, күрдеңме?

## Сөенеч хисе

Басу корабы дулкын ярып бара. Дулкыны дулкын гынамы, диңгез ярларына каккан гади дулкын түгел, йөрәккә сөенеч булып, җыр булып кага ул дулкын. Кырларымда иген дулкынлана. Мин бу гүзәл, күзләрне иркәләгән тере картинада алтын да, көмеш тә төсен күрмим, мин анда бәхет төсе, хезмәт төсе күрәм. Бу төсләр — тормышны бизи торган төсләр. Иген кырларының төсе, һавасы да үзгә. Монда булган һәркем бәхет белән очраша. Башакларның һәр тирбәлеше бәхеткә, бары бәхеткә. Кырлар кочагында чакта күңелнең көйсезләнүе, борчулы уйларга талу мөмкин түгел, безнең моңа хакыбыз да юк. Синең алда иге-чиге күренмәгән бәхетле тормыш, иртәгәсе көнең; бер адым да артка чигенмә, алга бар, колачыңны җәеп бар, куанычыңнан көлеп бар, елап бар.

Кырлар буйлап барган саен мин игенченең якты йөзе белән очрашам, аның эшчән кулларын күрәм. Минем аңа мең рәхмәтемне ишеттерәсем килә. Рәхмәтем туып үскән җирендә хезмәт күрсәткәне өчен, иртәгә табыннарга куелачак

ипикәй өчен. Күп еллар туган кырларында иген үстергән абыйлар минем чиксез горурлыгым булса, бүген беренче тапкыр басу корабына утырып уңыш җыярга чыккан яшь егетләр — минем чиксез шатлыгым. Әле ул яшь кенә. Хезмәт мәйданына тәүге адымын ясый. Үзе авыр, үзе изге хезмәт юлын үтәчәк ул. Юк, ул сынатмаячак, өлкәннәрдән үрнәк алып ул үзен хезмәттә чыныктырачак. Шушы җирдә туып, шушы кырларда игелгән ипине ашап үскән. Ул шушы җирне яратып, аңа тирен түгеп яшәр. Үз жиреннән дә кадерле, изге, ямьле җирне ул башка җирдә тапмаячак. Ул бит шушы җирнең газиз баласы. Ул — җиргә, җир — аңа газизләрдән газиз. Моннан китсә дә ул, вакытлыча гына китәр. Әле аның Туган ил сагында буласы бар. Бәлки, әле ул моряк булып хезмәт итәр. Диңгез дулкыннарын ярып барган корабта егет туган басуын сагынып хәтерләр, ул үзен басу корабында итеп тояр. Чыркылдаша-чыркылдаша очышкан акчарлаклар аңа туган кырлары күгендә сайрашкан сабан тургайларын онытырга ирек бирмәс. Диңгездән кырларга ашкынып кайтыр егет. Бүгенге кебек, ул янә күңелләргә шатлык өләшеп, кырларына уңыш җыярга чыгар. Әлегә ул тәҗрибәсез, хезмәт көнен башлады гына. Әле аңа өлкәннәрнең ярдәме кирәк. Хезмәтне сөяргә, иген үстерергә өйрәтү — өлкәннәрнең изге бурычы.

Кыр корабы дулкын ярып бара. Яшь комбайнчы якты киләчәгенә юл яра. Быелга ул «кыр батыры» исемен алалмаса да, аның киләчәге өметле. Ул булачак игенче. Күңелемә тулган сөенечле хисләрнең иге-чиге юк.

## *Тупылым-тирәккәем*

Агачларның ямьсез чагын күргәнем юк. Тупылым-тирәккәем, ямь-яшел яфраклы чагында да, көзнең сары ялкынына чорналгач та матур син. Бүген син бигрәк тә матур, ап-ак бәс сарган ботакларың талгын җилдә тибрәлеп-тибрәлеп куя, сайрар кошлар кунып тибрәләмени! Тибрәлгән ботакларыңнан энҗе-мәрҗәннәрен җемелдәтеп, ефәктәй булып кар сибелә. Җылы эзләп еракларга китми калган кошларның бишеге син, тирәккәй. Сиңа карап торып күзләрем иркәләнә, рәхәт тойгы кичерәм. Юк, рәхәт тойгы бигрәк кыска вакытлы: авыр, тирән уйларга чумам. Мин синең тәнеңдә яралар күрәм. Канлы яра түгел, иске яра синдә. Күп еллар элек авырткандыр, сызлагандыр яраларың, бәлки, әле бүген дә сызланасыңдыр. Зур-зур ботакларың сынган, җил-давыллар каергандыр. Елагансыңдыр бит син дә, күрүчеләр булды микән, хәлләреңнең ничеклеген аңлый белделәр микән?! Тирәккәй, сине кем утырткандыр, олы яшьтә инде син, димәк, күпне күргәнсең, күпне кичергәнсең. Көчле җилләр килеп кагылуга чайкалып китәсең, тик аумыйсың гына. Кыш салкыны әрнетәдер кебек сине: җылы тынымны өрсәм, әрнүләреңә дәва булыр шикелле. Мин сине гомер буе иңнәреңдә авыр язмыш йөген күтәреп тә ыңгыраша, зарлана белмәгән, кайгы-хәсрәтләреннән бөгелеп төшмәгән, сулышы киселгәнче нык, сабыр булып яшәгән әнкәемә охшатам.

Тирәккәй, тирәңдә тирәкләр булса да, синдә югалту газаплары да бар кебек. Шуңа да кайчакта мин сине тормыш кыенлыкларын күп та-

тышган, инде әнкәемне юксынып моңсуланып калган әткәемә тиң күрәм.

Мин синдә үземне дә күрәм кебек. Яз килгән саен яфрак ярып яшәргән агачлар кебек, инде беттем дигәч, янә терелеп, өметләнеп яшәп китәм бит мин дә.

Тупылым-тирәккәем, язмышлар охшаш безнең. Тән яраңны күреп торам, тик белмим, күңел ярасы да бармы сездә — агачларда? Кешенең бит күбрәк күңеле яралана. Синдә дә шундый әрнегән яра бармы? Әгәр булса, беләсеңдер, вакытлар үтү белән төзәләме ул? Җилләрдә шаулавың күңел яраларыңа түзәлмичә үксүең түгелме? «Тупыл мамык очыра, кисеп ташларга кирәк!» дип сөйләшкәнне ишетәсеңдер. Юк, сине кисәргә бирмәячәкмен мин. Күпме яшәсәң дә яшә. Мамык очыр. Син яшәү бирәсең, орлыкларың туфракка күмелеп шытып чыга, агач булып күтәрелә. Тирә-ягыңда әнә күпме яшь тирәкләр чайкала. Килер җәйне бергәләп көтик. Мин синдә ямьсезлек күрмим, хәтта сиңа көнләшеп тә карыйм әле, очырасы мамыгың кебек күренә миңа ботакларыңа яткан ап-ак карлар.

## *Агачларда — кеше язмышлары*

Авылым яшеллеккә бик бай, бигрәк тә мин яшәгән урам. Үсмер имәннәргә, яшел бөдрә ак каеннарга карап: «И ямьле урамыгыз, шушыннан үтеп китүе дә әллә ни тора», — диләр үтеп китүчеләр.

Агачлар, агачлар. Яратам мин агачларны. Язлар җитеп, бөреләре ачылган чакта мин алардан күзләремне алалмыйм. Җәй буе ямь-яшел

булып утыра агачлар. Күзен сары яфраклар күңелне бераз сагышландырса да: «Бу сары төс мәңгелек түгел, алда килер язлар бар, дөнья тагын яшәрәчәк», — дип уйлыйсың да, күңелне өмет юата. Кышын ап-ак бәс күлмәк киеп алгач, дөньяда шушы агачлардан да матур нәрсә юк диярсең.

Кешеләр төрле агачлар утырта: каен, имән, юкә, карагай. Тик нигәдер соңгы елларда күпләр тупыл агачларын кистеләр. «Матурлыгы да юк, җәй җитсә — мамык очыра, тәрәзә дә ачып булмый, өйгә мамык тула. Әрсез агач, тамырыннан янә үсеп чыгар әле», — диләр. Мин бәләкәй чакта авыл урамнарында бик күп иде тупыллар, хәзер алар санаулы гына.

Мин тупылларны яратам. Каеннарны яраткан кебек үк яратам. Бездән ерак түгел, күпергә төшә торган олы юл борылмасында алты тупыл бар. Күп яшәгәннәр, колач җитмәс юаннар. Күп җил-давыллар күргәннәр, әллә ничә тапкыр саргаеп, әллә ничә тапкыр янә яшәргәннәр алар. Кем утырткан аларны, хәзерге көндә белүче юк. Элек монда гыйбадәт кылу урыны — мәчет булган, дип сөйлиләр. Шуңадыр, бу урынга беркем дә йорт салмаган. Матур урын бит, югыйсә. Суы да ерак түгел, тирә-юнь ямь-яшел, тупыллары гына да ни тора.

Мин монда еш булам: көндез дә, кич тә. «Тупылларым янына барыйм әле», — дим дә, китәм. Без үсмер чакта кичке уеннар гел шушында үтә иде. И ямьле иде ул чаклар. Әллә шушында яшьлегем эзләре калганга, килми булдыралмыйм. Монда килсәм, миңа рәхәт була. Кайсы гына мизгелдә дә якын бу җир миңа. Июнь аенда бигрәк тә.

*Талгын гына исә җәйге җил,*
*Тупыллардан оча ак мамык,*
*Якты көнгә өстәп ак төсен,*
*Дөнья кала гүя сафланып,*
*Тупылларга багам шатланып.*
*Мамык оча, алар артыннан*
*Хыялларым кага канатын.*
*Ак мамыкка төреп орлыгын,*
*Җиргә сибә тупыл таратып.*
*Мин аларны шуңа яраттым.*

Тупыл мамыгы кар бөртекләре кебек, керфекләргә, чәчләргә килеп куна. Ак күбәләк кебек оча ак мамык. Ак төс — яктылык, ак төс — сафлык. Әмма тупылларга кунып сайрамый сандугачлар, тупылларга кара каргалар гына оя кора. Юк, каргаларны кимсетергә теләмим, алар да — кошлар, ә тупыллар — алар кунар гөлләр.

Алты тупыл минем күңел түрендә. Озак күрми торсам, сагынам үзләрен. Алты тупыл — минем алты дустым, алты яшьтәшем кебек. Тупылларга карыйм да, кешеләрне күрәм кебек. Агачлар язмышын кеше язмышына тиңлим мин. Әйе, язмышлар охшаш.

Күптән инде мин ике тупылны күзәтәм. Үсмер чакларында аралары ерак булса да, үсә-үсә киң ябалдашлары якынайган. Берсенә берсе тартылып үскәннәр. Бер карауга, берсеннән икенчесенә сузылган шау яфраклы ботаклар — күрешергә сузылган куллар кебек. Ныгытыбрак карасаң, бу инде күрешү белән генә бетми, кочаклашып үбешәләр кебек тупыллар. Ботаклар бер-берсеннән еракта чактан ук —айлар, еллар буе кавышу, бер-берсенә барып җитү сәгатьләрен көтеп яшәде алар. Кешеләр кебек бит, нәкъ кешеләр кебек. Җитәкләшеп тормыш юлы

үтәр өчен кавыша кешеләр, агачлар да шулайдыр, күрәсең, алар да бергә. Башларын башка терәп серләшәләр, искән җил көенә чайкалып, берсен-берсе иркәлиләр.

Шушы ике тупыл өчен мин борчыла идем. Катырак җил иссә дә, бигрәк тә давыл купса, җаным тынычлыгын җуя иде. «Сузылган ботаклар сынмаса гына ярар иде, исән-имин генә яшәп кавышсыннар иде», — дип борчыла идем. Коточкыч уйлар килде, агачларның берсен яшен уты көйдереп үтәр кебек булды. Агачларга караган саен, күз алдымда кешеләр язмышы сурәтләнде. Кешеләр берсен-берсе эзләп юллар үтәләр. Табышалар, якынаялар. Кавышу минутларын көткәндә бәла килә: тормыш җилләре кавышырга ирек куймый, юлларын аера, күңел канатларын каера. Икесен ике җирдә агачлар кебек чайкалдыра, бөгә-сыга, сындырып ук ташларга ниятли. Һаман-һаман көчен арттыра бара. Кешеләр бу чакта йә җиңә, йә җиңелә. Җиңелү — коточкыч язмыш. Тупылларымның да бер көчле җилдә ботагы каерылган иде. Ярый әле сынып төшмәде ботак, ул янә үз юнәлешен алды, иптәшенә табан сузылып үсә башлады. Былтыр җәй ике тупылның иң югаргы ботаклары килеп кушылды. Инде аларны, мөгаен, җил-давыллар куркытмас, берсен-берсе саклар алар, гомер буе сакларлар. Алар хәзер җилләрдә бергә шаулыйлар, бергә яңгырларда чыланалар, кочаклашкан килеш матур таңнарны каршылыйлар. Калган дүрт тупыл бу икәүгә карап сокланалар, хәтта бераз гына көнләшеп тә куялар кебек. Бар да ямь-яшел, бар да шат. Тупылларыма карап мин дә шатланам. Дөнья матур! Тупылларга карап кешеләргә дәшәм. Ишетәсезме, кешеләр! Тор-

мыш матур да, шул ук вакыт усал да ул. Тормыш җилләре искәнгә сүнмәсен мәхәббәт ялкыны! Сүнмәсен, сүрелмәсен якты өмет. Хыяллар тупыллардан очкан ак мамыктай ап-ак булсын! Якты хыял якты киләчәккә илтә. Җил-давыллар каршында кеше көчлерәк булырга тиеш. Тупылларны кисмәгез, кешеләр, матур агач алар, мин аларны яратам.

Тупылларыма карыйм да, кешеләргә алар язмышын телим.

## *Без — кешеләр*

Очрашканыбыз булмаса да, мин сине күрәм, нишетеп торам. Каршымда — ботаклары җил-давылда каерылган имән. Тормыш кыерсыткан шушы имәнгә карыйм да, мин сине күрәм. Имәннән бераз читтәрәк шундый ук зәгыйфьләнеп үскән каен да бар. Синең каршыңда да бардыр зәгыйфь каен. Шуңа карыйсыңдыр да, мине күрәсеңдер. Кешеләр язмышы төрлечә булган кебек, агачларда да язмышлар төрлечә була шул. Үсеп кенә килгән сабый чакларында давыл каты куллары белән тотынган бу агачларга. Агачлар бөгелгән, сыгылган. Юк, сынмаганнар алар. Әллә яшь булганга бирешмәгәннәр, имгәнсәләр дә, яшәүдән туктамаганнар. Бу тәннәре яралы агачларның кайгы-сагышлары белән бергә шатлыклары да бар. Якты язлар килгәч бөреләнеп ямь-яшел яфрак яруларын, җилләрдә талгын көйгә генә чайкалып утыруларын шатлыклары итеп саныйм мин аларның. Алай гына түгел әле, зәгыйфь агач дип тормыйлар, кошлар да килеп

куна аларга. Сайрап, чутылдап та алалар кошкайлар. Рәхмәт аларга, кимсетеп карамыйлар.

Каен имәннең, имән каенның әрнеп-сызланып ыңгырашуын ишетә. Бер-берсенә ярдәм генә итә алмыйлар шул, берсен-берсе җил-давыллардан саклап яши алмыйлар. Яшь белән мөлдерәп торган күзләр генә әледән-әле очраша. «Бирешмик әле, бирешмик. Яңа сынауларга әзер булыйк. Безнең яшел язларыбыз әле күп булсын!» — дип пышылдаша кебек алар. Әйе, нәкъ кешеләр кебек алар да. Очрашканыбыз булмаса да, мин сине күреп, йөрәк тибешеңне ишетеп торам. Син дә шулаймы, минем йөрәгемнең: «Без тормыш давылларыннан көчлерәк булып яшәргә тиешбез. Зәгыйфь агачлар авып калганда да, без егылмыйк, без бит кешеләр!» — дип әйтүен ишетәсеңме?

## *Якты өмет*

Авылымның бер йортында бүген ут кабынмады. Бу йортта яшәү уты сүнде, ялгыз карчык дөнья куйды. Туфрагы җиңел булсын! Тормыш әйбәт, илдә иминлек, яшәсен иде әле. Гомерне чиксез итеп булмый шул, хәер, үкенерлек яшәмәде ул. Шушында туып-үскән, кияүгә чыккан, итәк тулы бала үстергән. Чәчүен чәчкән, урагын урган, киндерен суккан. Дөньяның ачысын-төчесен өлешенә тигәнчә авыз иткән. Тормыш бер бал каптырса, мең тапкыр ут йоттыра бит ул, «Бәхетсез башкаем!» — дип әрнеп елаган чаклары да булгандыр, әлләниләр кичергәндер. Кеше күрәчәген күреп бетергәч кенә гүргә керәдер. Тик ул бәхетле җан булган. Бәхетле булуы — аның туган җирендә гомер кичерүе! Чит-ят жир-

ләргә китеп, туган җирен сагынып өзгәләнмәде ул. Олыгайгач та балаларына күченмәде, гомер иткән йортыннан ничек китсен инде?! «Өең туз-ган, авылны ямьсезләп тора, сүтеп алырбыз, үзең безгә күч», — дип әйткәндер аңа балалары, карчык бу сүзләрне ишетмәмешкә салышкандыр. Рәхмәт аңа, авылдагы йортлар санын киметмәде. Төн җитсә, балкытып ут кабызды, миченә ягып һавага төтен чыгарды. Бүген дә әле карчык яшә-гән йорт — ташландык йортлар кебек түгел, күңелгә якын булып тора. Ямьсез түгел ул, ху-җалары читкә күчеп киткән ялгыз, ташландык йортлар кебек ямьсез түгел. Дөньядан китү белән читкә китү бер түгел.

Туган җирен сөеп яшәгән кеше бәхет эзләп, нигезеннән кубып китәлми. Бер җирдә тамыр җәйгән гөлне икенче җиргә күчергәндә аның та-мырлары шытырдап өзелә. Ул яңа җирдә бик авырлык белән генә үсеп китә ала, кайвакыт сулып калулар да була. Авылын, йорт-нигезен ташлап китүчеләрне әнә шул тамырлары өзелеп зәгыйфьләнгән гөлгә охшатам. Барыбер туган җирен сагынып яши бит ул, нигә китә, нигә үз җирендә тоймый ул бәхетне? Нигә ул үз авылы-на ямь биреп, хезмәт итеп яшәми? Нигә балкып торган йорт төземи, гөлбакча үстерми? Каз, үрдәкләрен су буена куып баруы да, көянтәләп чишмә суын алып кайтуы да, авылдашлары бе-лән шау-гөр килеп эшкә барган-кайткан чакла-ры да, өй артында шаулап утырган ак каены, бөдрә тирәкләре дә төшләренә керәчәк, җанына сагыну уты булып, гомерлек газап уты булып кабачак бит! Нигә китүче шуны аңламый, әллә ул бөтенләй үк ваемсызмы, юкмы аның күңе-лендә моң чиртүче нечкә кыллар?

Авылда ялгыз йортларның саны арта. Хужасыз өйләр янынннан үткән чакта үксеп елаган тавыш ишетәм кебек. Әйе, бу саташу түгел, ташландык нигез елый. Гөлләр үсәсе урынны чүп-чар, кычыткан каплап алган. Коточкыч уйлардан арыналмый интегәм: авылым язмышы һәлакәткә дучар булмасмы? Күпләрме без, авылыбыз өчен җан атып яшәүчеләр? Бу авыр уйлардан арындырып, бер йорттан бишектәге бала тавышы ишетелә.

Бала елый, ә миңа рәхәт. Авылым әле яши, китүчеләре урынына яңа кеше туа. Күңелдә өмет яктырып китә. Бәлки әле бу бала — авылымның киләчәгедер. Үсәр, туган җиренә мәхәббәте уяныр. Китү турында уйламас ул, бар көчен, белемен хезмәткә, туган җирен хөрмәт итүгә бирер. Гөлләр арасында яшәр, бәхетле булыр. Әле мин бертапкыр да күрмәгән бишектәге сабый якты өмет булып күңелемә иңә. Авыл язмышын билгеләүдәге бала хәл итәчәк! Бүген генә гүр иясе булган карчыкның йорт урынында яшәү дәвам итәр кебек.

Төн. Тәрәзәләрдә утлар кабына. Киләчәктә дә авылым йортларында кабыначак утларның яктысын күрәм сыман.

## *Көзге моң*

*Һаваларда торна тавышлары,*
*Ишетелә канат кагышлары.*
*Кошларда да — кеше язмышлары,*
*Чит җирләргә китеп барышлары.*

Шушы җырны тыңлаган саен Шәмсекамәр әби авыр сулап куя, күзләренә яшь килә. Көзләр

җитсә, туган ояларын калдырып кошлар китә. Кошлар кебек, туган-үскән җирен калдырып, ялгыз карчыклар калаларда яшәүче кыз-улларына китәләр. Кыш чыгарга гына, кар-буранлы кыш үткәнче генә. «Кошлар кебек булдым инде, көз җитсә — китәм, яз җитсә — кайтам. И алла, язмыш шулай кушкан инде, хәлләр юк, сабырлыклар бир, ходаем!» — дип инде ничәнче тапкыр әйтәдер Шәмсекамәр әби. Тузган йорт-курасын ташлап бер генә дә китмәс иде. Тузса соң, бергә картайганнар, күп еллар яшәлгән бит! Ялт итеп балкып торган кала йортында һич кенә дә ямь, шатлык тапмый шул авылдан киткән карчыклар. Зур тәрәзәләргә карап, биек-биек йортларын күрмиләр алар, яртылаш карга күмелгән авыл йортлары, көртле юллар килә аларның күз алдына. Чиләкләрен тутырып, берәү әнә чишмә суы алып кайта. Их, нинди тәмле инде ул чишмә суы! Иңнәрендә көянтәсе бар кебек, рәхәт тойгы кичерә Шәмсекамәр әби. Гомер иткән ишегалдындагы мал-туар, кош-корт тавышлары ишетелгәндәй була. Ничек онытмак кирәк, шул йортка килен булып төш, балалар үстер... Кайгы-шатлыклары белән хәтердә яши анда үткән еллар. Хәзер күпләр кырын күз белән генә карап үткән йортның идәнен ком белән ышкып юса, өй эче — яп-якты, һавасы сулап туймаслык була иде өйнең. Мич тутырып ипи салган көннәр, ул каз өмәләре!... Еракта калган шул, бик еракта калган.Тезгә чаклы батып, тирес баскан чаклар да сагындыра бүген. Тормыш әйбәт бит, авылда да әйбәт хәзер. Авылдан язга кадәр генә китсә дә, беренче китүендә үк туган җиреннән аның тамырлары шытырдаплар өзелде. Авылына кайтып җәйләмәсә, күптән тыны киселгән булыр

иде. Тамчылар тама башлау белән Шәмсекамәр әби кайтырга җыена башлый. Их, ул шатлыклы көннәр тизрәк җитсен иде! Көз — китәр чагы гына җитте әле, ә ул инде кайтыр көннәрен көтә. Агач яфраклары саргаеп коелды, алар авыр сагыш-моң булып Шәмсекамәр әбинең күңеленә кереп тулган бугай. Әнә һава иңләп кошлар шаулашып оча. Китәргә җыеналар. Хушлашалар, кошлар да хушлаша белә икән ләбаса! Басып тибрәлгән тал-тирәкләре белән саубуллашалар. Тәүге тапкыр канат җилпеп оядан күтәрелүләрен сагынып кайтачаклар бит алар. Шәмсекамәр әби дә күтәрмәсеннән бер менә, бер төшә, өе тирәсендә үскән ялангач агачларга карый. «Исән булсам, ямь-яшел булып бөре ачкан чагыгызда кайтырмын!» — ди ул. Үзе кайтмаса, шомырт, балан куаклары ап-ак булып чәчәк атмас кебек тоела аңа. «Кайтырмын гүзәлкәйләрем, кайтырмын!» — ди, күңеленнән агач-куакларын иркәләп, үзен-үзе юатып. Өмет шәмнәре сүнмәсен берүк, кеше өмет белән яшәсә генә көчле була ала, сагынуларга да түзәр хәле була аның. Көзге яңгыр түгелдер ул. Шәмсекамәр әби шулай уйлый. Күз яшьләредер ул көзге яңгыр, әйе, шулайдыр. Күпләр елый бит көз җитсә. Кошлар да, кешеләр дә елый, китәселәре килми елыйлар.

Чың-чың итеп һавада торналар тавышы ишетелә. Әнә алар, чылбыр булып тезелгәннәр. Шәмсекамәр, Әминә, Фатыйма, Йөзлекамал, Бибинур әбиләр дә чылбырдай тезелгән торналар артыннан юлга чыгарлар. Яшәсеннәр әле, исән-сау әйләнеп кайтсыннар әбиләр, кошлар белән бергә кайтсыннар. Кошлар тавышы язларны ямьле итсә, әбиләрнең кайтуы авылларны

сөендерәдер, мөгаен. Күзләр моңсу булса да, язлар шатлыклы булсын, әбиләр!

Һаваларда торна тавышлары...

## *Тамырлар — туган якта*

Китүченең күзләрендә яшь булу — бу гаеп түгел. Бу китүеңдә дә еладың син. Ничәнче кабат китүеңдер инде?! Еш кайтасың, киткән саен елыйсың. Кыллардан тора бу күңел. Киткәндә әнә шул кыллар өзелә. Әйе, өзелә. Туып-үскән йортың, якыннарың белән саубуллашканда кылларның берсе өзелсә, бала чагың шау-шулары калган урамың белән хушлашканда тагын берсе өзелә. Һәр тирәк, һәр агач болгап, талгын җилдә яфракларын шыбырдатып, моңсуланып кына: «Хәерле юл», — диләр сыман. Тәрәзә төбендә үскән гөлләр дә бөрешеп калган төсләләр, озатып, карап калалар гөлләр, син киткәнгә боегалар. Әнә шуларны күреп ничек өзгәләнмәссең? Басу капкасына җитеп, авылга борылып карагач, белмим, ничәсе берьюлы өзеләдер ул кылларның...

Бары берсе, берсе генә өзелми кала кылларның. Шул кылны өзгәләп-өзгәләп вакыт сагыну көе уйнаячак бит. Ул кылны чиртүгә, сагышлы моң гына сибеләчәк. Юк, сагыну сабырсыз ул, китеп тә җитмисең, сагына башлыйсың. Туган нигезең, әткәң-әнкәң йорты бит ул шуның өчен дә. Иң кадерле, иң изге җир. Китәр юлларыңа әле беренче адымнарыңны гына ясыйсың, сагыну керфек очларыңа килеп куна. Күз яшьләре әнә шулар бит ул. Ничәнче кабат озатадыр бу йорт сине?! Озаткан саен ак юл тели ул сиңа,

бәхет теле. Иң беренче шушы йорттан син мәк-
тәпкә чыгып киттең. Шатлык нуры балкы
йөзеңдә, кулыңда алсу чәчәкләр. Шуннан канат-
ларың ныгыды да очып киттең син бу йорттан
Сине, пединститут студентын, ничә кабат сагы-
нып көтеп алды да ничә кабат озатып калд
шушы йорт. Язгы ташкынмыни гомер агышы —
еллар үткән дә киткән. Туй күлмәге киеп тор-
мыш юлына аяк бастың. Инде син туган йортк
кадерле кунак кына булып кайтыр булдың. Кай-
тасың, талпынып кайтасың. «Кайда да бер үк ко
яш, бер үк ай», — диләр дә ул, туган якта кояш
кайнаррак, ай яктырак бугай?! Юллар сине ера
алып китте, тик син китеп бетмәдең, синең яшә
тамырларың туган җиреӊ туфрагында җәелеп
калды. Туган җирдән тамырларны суырып алу
мөмкин түгел. Суырып кара, тамырлар шытыр-
дап өзеләчәк. Тамырсыз гөл яши аламыни?
Сула, мәңгелеккә сулып кала.

Тагы да ныграк сагынып кайтыр өчендер
яшәү өчен ерактагы бер яшь каланы сайладың
Син язмышыңнан канәгать. Заманы нинди бит
Яшәгән саен яшисе килә. Кайтасың да, киткәндә
елыйсың. Сине анда бәхетле гаиләң, шаулы шә-
һәр тормышы, яраткан эшең көтә. «Әллә ниләр
булса да, авыл сагындыра, кайтасы килә», — ди-
сең син, киткәндә елыйсың. «Ник елыйсың?» —
дип сорамыйм, чөнки үземнең дә киткәнем бар
Китүчеләр хәлен аңлар өчен көзен кыр казлары,
торналар тавышына колак салу да җитә бит. Та-
вышлары нинди моңсу. Моңсу каңгылдашулары
«Сау бул, туган як», — дип өзгәләнеп әйтүләре-
дер бит аларның. Көзге яңгырлар киткән кош-
ларның күз яшьләредер ул. Елыйлардыр, ке-
шеләр кебек кошкайлар да елыйдыр.

## *Җыр*

— Үзең өзелеп төштеңме, җил өздеме сине, каен яфрагы? Үзең сап-сары!

— Үзем өзелдем, үзем. Тик мин каен яфрагы түгел.

— Юкны сөйлисең, син каен яфрагы, яраткан каенымнан өзелгәнсең. Күз җиткәнгә шундый сары син.

— Юк, мин яфрак түгел, каеннан өзелмәдем, мин синең моң-сагышың, яфракка әвereлдем дә күңелеңнең иң нечкә кылыннан өзелеп алларыңа төштем.

— Әйе, әле генә күңел кылларым тартылып киткән иде шул, син өзелгәнсең икән. Нигә өзелдең соң әле син, нигә каен яфрагы булып өзелдең, сагышым?

— Каеннарны яратасың бит, ак каен синең сердәшең, сердәш каеныңның яфрагы итеп мине кулларыңа ал, серләшик.

— Ә мин сине җыр дәфтәрем арасына салып куйсам, яфрак булып шунда гына калырсыңмы?

— Юк, мин дәфтәрнең ап-ак битенә язылган матур җыр булыр идем.

— Нинди җыр, сагышлы җырмы? Сагышлы җырлар бик күп бит! Шатлыклы җыр булсын иде ул!

— Ә нигә, шатлыклы сагышлар да була бит, бүгенге кичерешләрең кайгылы түгел, син бит бала чагыңны сагынасың. Бала чагың күге аяз, анда яфрак кадәр дә болыт юк.

— Кайгы-хәсрәтләрнең ни икәнен дә белмәгән чакларым бар иде шул. Миләш агачларында янып торган тәлгәшләр күрсәм бала чагым белән

очрашмый калмыйм. Менә әле дә каршымдагы миләш агачына карап торам һәм...

— Һәм, син анда, агач янында, кара чәчле коңгырт күзле бер кызчыкны күрәсең. Өстенә әнкәсе теккән чәчәкле күлмәген кигән, күлмәк кесәләрен тутырып миләш җыйган. Кызчыкның кулында энә белән җеп, ул миләштән төймә тезә. Муенында да миләш муенса, тагын кемгә тезә микән?

— Анысы сеңелемә иде. Озын җепкә тезә идем мин кып-кызыл миләшләрне. Юк, миләш ашамый идем, бигрәк ачы булып тоела иде. Тормыш җимешләре миләштән күпкә ачырак булды булуын. Юк, минем хәтеремдә миләш ачысы калмады, минем хәтеремдә матур булып, бала чагымны сагындырып кып-кызыл булып миләшсәйләннәр яши. Көз килгән саен хәтерләрем яңара, күңелем сафлана. Бу хакта, әлбәттә, җыр кирәк. Күңелдә моң-сагыш барда, җыр нишләп булмасын ди?!

*И миләшем, миләшем,*
*Янып торган тәлгәшем!*
*Юатмагыз, сабый чакны*
*Сагынып түгелә яшем!*

## *Яну*

Әллә ничә төрле утта яна кеше, дөрләп яна. Ул коткарырга дәшеп кычкырмый, ярдәм сорамый. Янып яши. Янып яши белгәне өчен дә — ул көчле, ул барсын да үзе җиңә ала. Кайгыхәсрәт утларында янганда да яшәү уты белән балкый ала ул. Янып эшли кеше. Янып эшләгән

кешенең беләге дә, йөрәге дә талу белми. Ут чәчрәтеп эшләве көннәрен якты, тормышын бар итә. Ашы тәмле, йокысы татлы була аның. Кеше янып эшләгәнгә кырларда шаулап иген үсә, бакчалар чәчәк ата, тормыш яңача төзелә, көннән-көн матурлана бара. Илемне алга илтүче ул — янып эшләгән кеше!

Янып сөя кеше. Туган җирен, халкын сөя Дөнья яктысын ул шул сөю аша күрә. Сөюе аны шагыйрь, җырчы, батыр итә, үрләргә дәшә, гүзәллеккә әйди. Мәхәббәт утында яна кеше. Янып бетәрмен дә көл булырмын дип уйламый, курыкмый ул. Бу изге утта яна-яна гөл булачагын, чәчәкләргә күмелеп яшәячәген белә шул ул. Хыялларын канат итеп оча ул, якты киләчәгенә омтылып бара. Кыенлыклар очраганда да туктап калмый, кыенлык киртәләрен ялкыннары белән ялмап үтә. Алар икәү — янында сөйгән яры. Сүнә, сүрелә торган түгел аларның уты. Мәңге балкыр ут капкан аларга.

Гомер юлын ялгызы гына үтсә дә курыкмый кеше янудан: ул бит сөя, ялкыны бар аның, якты өмете бар. Яшәү уты сүнгәндә дә, сөю уты сүнеп калмаячак. Ярата белгән кеше матурлык эшләмичә китми бу дөньядан. Сөю уты булып әнә шул матурлык яшәячәк.

Сагыну утларында яна кеше. Сагына, йөрәккәе телгәләнә. Йөзкәенә сагыш сарылары чыга, күз карашлары моңсулана. Их, бирсәче карлыгач канаткаен: җанына сагыну уты булып капкан җирләрен, кадерле кешесен барып кына күрер иде бит. Кайсы гына коштан канат сораса да, канатын бирми кош. Болай да моңлы күңелгә үз моңын өстәп, сайравында була. Ул үзе дә сагынадыр, мөгаен, миндә дә бар ул сагыну, дип

әйтә кебек бит. Әллә сабырлыклар теләвеме? Кош сайравына җавап итеп, кеше йөрәге менә нәрсә дип тибә:

*Сагынудан сабырым юк,*
*Таллар булып бөгеләм.*
*Моңнар булып түгеләм дә*
*Кыллар булып өзеләм!*

Кеше гомер буе яна: янып яши, янып эшли, янып сөя. Бу утларның берсен дә сүндерергә ярамый. Кеше барсына да хаклы. Кеше йөрәге кайнар булырга тиеш.



## *Әнкәйләр еламасын*

Әнкәңнең елаганын күргәнең бармы? Юк, дисәң, әлбәттә, ышанмам: аналар елый ул һәм еш елыйлар. Аны күрми калу мөмкин түгел, син дә күрәсең аны. Әнкәң күзләрендә яшь күреп тетрәнәме җаның? «Әнкәй, бәгърем, күзләреңдә нинди яшь, нинди кайгы-хәсрәтең бар, кем рәнҗетте?» — әнкәңнең яшьле күзләренә карап, аңа ишеттереп яки күңелеңнән генә сулкылдап, син бу сорауларны бирәсеңме? Юктан гына еламый бит беркем дә, бигрәк тә аналар. Аналар сабырлыкның чигенә җиткәч кенә, түзәр хәлләре калмагач елый. Күз яшьләренә сәбәп күп. Кинофильмнар караганда, китап укыганда, моңлы җырлар тыңлаганда үзе кичергән авырлыклар исенә төшеп тә әрнеп куя аның җаны, күзләренә яшь килә. Тик син уйлар диңгезенең төбенәрәк төш: үзең кайгы-хәсрәтле итмәдеңме, рәнҗетмә-

деңме әнкәңне? Күзләрендәге яшь — син түгелме?

Син дә елагансың. Туу белән син дөньяга елап аваз салгансың. Бу елавың әнкәңә шатлык авазы булып ишетелгән, чөнки бу елау: «Мин тудым, мин яшим!» — дигәнне аңлаткан. Кеше елап туса да, елап яшәргә тиеш түгел, аналар моны яхшы аңлый. Син елый башлагач та, әнкәң сине кулларына алып, җылы күкрәк сөтен биргән. Яшәвең әнә шулай әнкәңнең күкрәк сөтен имүдән, анаң назыннан, анаң мәхәббәтеннән башланган. Ул сине елатмаска тырышкан, күзләреңнең саф яшь тамчыларын үбә-үбә, сине юатырга ашыккан, кулларына алып уйнаткан. Үзе еласа елаган, синең көлә-көлә уйнап үсүеңне, гүзәл кеше булып яшәвеңне теләгән. Әнкәйләр шундый изгелекле шул, аларның җаннары керсез. Баласы өчен барсына да түзә: газиз җанын тормыш пычакларыннан телгәләтә ул, тормышның бозлы суларына төшеп туңа, утларына кереп яна. Ә син әнкәң өчен ниләр эшли аласың? Күзләрендә яшь күрсәң, әйе, син аны кулларыңа алып юата алмыйсың. Әнкәң елаганда юату сүзләре дә эзләп табалмыйсың. Аналарны юата алырдай сүзләр дә юк бугай ул. Әгәр бу күз яшьләрен син китергән булсаң, нишләргә соң сиңа? Синең өчен шулай газапланган ана йөрәгенә синең гафу үтенүләрең генә дәва була алмый. Йөрәк ярасы, күз яшьләре каршында гафу үтенү — көчсез! Әлбәттә, хатаңны төзәтергә ашык. Ялгыш юлга әйдәүчеләрдән ераккарак кит, яманлыктан аерыл тизрәк. Чит-ятлардан да рәнҗү, каргыш алып яшәмә, бу синең өчен генә түгел, атаң-анаң өчен зур фаҗига. Ашык, атаң-

анаң күрергә теләгән гүзәл кеше булырга ашык. Әнкәң күзләрендә яшь кипсен.

Аналар бәхет-шатлыктан да елыйлар. Гел генә шатлыктан еласалар иде алар! Матур эшләреңне күреп, уңышларыңа шатланып, түбәсе күккә тиеп елый бит ул. Шатлыктан елаганда әнкәңне бүлдермә, аналар болай да шатлыктан сирәк елыйлар. Шатлыклы күз яшьләре нур булып тама, тормышка ямь, дөньяга яктылык өсти бу нур.

## *Хатын-кыз матурлыгы*

Сау-сәламәт, төскә-биткә чибәр, чама белеп кенә буянган, өс киеме бик күркәм бу хатын игътибарымны үзенә җәлеп итте. Шушы авылда туып-үскән кыз иде ул, ерак шәһәрдән тормыш иптәше белән кунакка гына кайткан. Инде күптән күргәнем юк иде, үзгәрмәгән, авылдашым һаман да кыр чәчәгенең берсе ләбаса!

Кояшлы көнгә, чәчәкле гөлгә тиңлим мин чибәр хатын-кызны. Дөньяны якты итүче хатын-кыз йөзе, тормышны ямьле итүче хатын-кыз матурлыгы! Төсе матур хатынның теле дә, уйхыяллары да, эшләгән эше дә матур булырга тиеш һәм бу шулайдыр да, дип уйлый идем мин. Әмма ялгышканмын. Читтәрәк торган хатыннарның сөйләшүен ишетәм:

— Кияүгә күптән чыккан идең, бәбиегез кем, кызмы, малаймы?

— Беркем дә юк, мин бала яратмыйм!

«Мин бала яратмыйм!» Кунакка кайткан авылдашымның бу сүзе минем җанны гына түгел, зур дөньяны тетрәтте кебек. Чибәр хатын-

ның йөзенә карыйм. Йә, ходай, шул арада чә-чәкләргә тиң булган матурлык кая булды, бе[illegible] генә тамчысы да калмады — әллә су булып ак-ты, әллә җил булып исте, юкка чыкты. Әйтерсе[illegible] лә ул матурлык булмаган, хатын кара көеп [illegible] шиңгән чәчәккә охшап калды. Кояшны болы[illegible] каплады, дөнья караңгыланды, коточкыч давы[illegible] купты, бу давыл агач ботакларын түгел, күңе[illegible] тирәкләрен сындырып, тамырыннан куптары[illegible] ташлый торган давыл, исән нәрсә калмас кебек.

Мин ялган матурлык белән очрашканмы[illegible] икән, ялган матурлык тормышны ямьле ит[illegible] алмый. Ярата белмәүдә нинди ямь булсын да ба-ла яратмаган кеше кемне һәм нәрсәне ярата алсын?! Бала ул — якты, матур киләчәк! Бала яратмагач, киләчәге юк ич ул хатынның. «Балам юк!» — дип өзгәләнгән хатыннарны беләм мин, бала яратмаганнарны очратканым юк иде. Кө-ләрсең дә, еларсың да, акылсызлыктан арынып бетәлмисең шул әле әй, дөнья!

Сабыен кулларына күтәреп елмая, тезләренә утыртып сөя, иркәли, беләгенә куеп күкрәк сөтен имезә, бишек җыры көйләп йоклата — ха-тын-кызның гүзәллеге менә кайда! Ул — ана, ул — бәхетле, ул — кеше! Дөньяны ана шатлы-гы кояшлы-айлы итә, бала көлүе тормышка был-быллы яз китерә!

Котырынган давыл тынычлана төште, кояш нурлары да сибелде, чөнки хатыннарның берсе: «Балам йокыдан уяныр инде», — дип кайтыр юлына чыкты, ана йөрәгенең «Балам!» — дип типкәнен мин дә, дөнья да ишетеп тордык. Бала яраткан хатын-кызлар дөньяның исәнлеген сак-лап мәңге яшәр!

## *Ана мәхәббәте*

Кем мине ныграк ярата, шул турыда сүз алып баралар туганнарым, дусларым, сөйгән ярым. «Мин», — диясе килә һәркемнең. Бәхәс кызып бара. Мин берсенә дә сиздермичә генә тыңлыйм, күзәтәм. Кем җиңеп чыгар, туганнармы, дуслармы, сөйгән ярмы? Мин ярыш барган мәйданны күзәтәм кебек, тик фәлән команда җиңсен иде, дигән уй юк. Минем өчен һәркайсының яратуы кирәк, алар миңа бар да кадерле, берсен дә читкә тибәсе килми, барысы өчен дә сызланам. «Кызышмагыз, өзегез бу сөйләшүне. Яратасыз, барыгыз да бертигез яратасыз», — диясем килсә дә әйтмим, түзәм. Үземнең дә беләсем килә: чынлап та, кем ничегрәк ярата икән мине?

Туганнар бар да бертавыштан:

— Бездән аңа һәрчак җылы, якты караш, — диләр. Дуслар да калышырга теләми:

— Бездән аңа чын йөрәктән булган елмаю. Без — аның кайгысын да, шатлыгын да бүлешүчеләр. Боек чагында күңеле күгендә кояш була алабыз, — диләр. Сөйгән яр, берүзе генә булса да, бирешмәскә тырыша, тавышы барысыныкыннан да көчлерәк:

— Сезнең ярату белән минем ярату бер буламы соң?! Аермасы — җир белән күк арасы. Мин аның өчен утта янам, дәрья кичәм, кош булып сайрыйм. Җир йөзендә үскән назлы гөлләрне аның өчен генә өзәм. Күкнең иң якты йолдызларын аның өчен генә чүплим. Ай нурлары булып түгелеп керфекләренә кунам, кояш нуры булып кайнарланып иреннәрен үбәм. Мин аңа

йөрәгемне бирдем. Ул көчле, җил-давыллар каршында — без икәү.

Яныма анам килә. Шулчак безне күреп, бар да тынып кала. Анам алдында бәхәс үз көчен җуя.

Якын туганың ераклашмас, димә; җан дустың, сөйгәнең ташлап китмәс, димә. Ана — һәрчак янда. Җаны барда ана ташлап китми. Ана мәхәббәте мәңгелек, ана мәхәббәте — яшәү үзе.

## *Әнкәем гөлләре*

Безнең өебездә һәрчак — җәй. Көзнең дә, кышның да беркайчан да булганы юк. Әнкәем үстергән гөлләр җәйге матурлыкны саклап тора. Тышта агачларны тамырлары белән йолкып алырдай булып, җил исә, буран котыра — мин җәйге көннәрне күреп яшим. Тәрәзә төбе саен өчәр савыт гөл, барысы унсигез төрле алар. Һәрберсе үзенчә матур, һәрберсе күңелгә якын. Шул гөлләргә кунып сандугач булып сайрыйсы килә, күбәләк булып чәчәкләрне коча-коча очып уйныйсы килә. Ап-ак, ал, кызыл, зәңгәр чәчәкләре бар гөлләрнең. Ак чәчәкләрне әнкәемнең күңеленә, зәңгәрләрен күзләренә охшатам мин. Иң нәфис, иң гүзәл гөлләр бездә үсәдер кебек. Әнкәй үстергәнгә күрә иң гүзәлләре булып күренәдер алар миңа. Туфраклы чүлмәккә утыртасың да, көн дә бер су сибәсең генә түгел, җаныңтәнең белән яратырга кирәк. Минем гөл-чәчәкләрне яратуымны белә әнкәй, гөлләрне яратуы, бәлки, шуңадыр да әле. Ул аларны җылы карашы белән иркәләп, сабый баланы назлагандай назлап үстерә. Әнкәй гөлләргә су бөрккәндә язгы

яңгыр-ләйсән сибәмени — гөлләр көләчләнеп, тагы да матурланып китәләр. Бөрккәннән соң яфраклардан тамган һәр тамчы су гөлләрнең әнкәйгә әйткән рәхмәт сүзләре кебек.

Яз җитүгә безгә гөл ботагы сорап киләләр, гөлләрегез матур, диләр.

— Алыгыз, — ди әнкәй. — Нindие кирәк, яшь ботагын сындырып алыгыз.

— Син үзең сындырып бир, синең кулың сындырган гөл ботагы тиз тамыр җәя, — дигәннәрен күптапкырлар ишеткәнем бар.

— Үзең үстергән гөлләрне сындырырга кызганмыйсыңмыни? — дип сорадым бер әнкәйдән.

— Кызганмыйм, — диде ул. — Мин бит аларны сулдырыр өчен түгел, тамыр җәйсеннәр өчен, гөлләремнең дәвамы булып үссеннәр, кешеләр күңеленә шатлык, ямь бирсеннәр өчен сындырам.

Әнкәй сүзләрендә хаклык бар. Әнкәем күңелендә борчулы уйлар булса — гөлләр боега, ә авырып китсә, бөгелеп үк төшәләр. Өебез һәрчак ямьле булсын, борчулы уй, кайгы-хәсрәт килмәсен иде әнкәйгә. Әнкәйләр белән генә матур бит бу тормыш. Иң изге теләк тели белүче, иң саф йөрәкле кеше — әнкәй бу дөньяда. Гөлләр: «Көн яктысына үрелеп үссәк тә, әнкәбез син безнең, — диләр кебек әнкәйгә. — Безне дә үз балаларыңны яраткан кебек яратасың бит». Әнкәй үстергән гөлләргә карап мин болай димен:

*Дөньядагы барлык шифалардан*
*Көчле, әнкәй, назлы карашың.*
*Син булганда янда, мин — сулмас гөл,*
*Син яңгырым минем, кояшым.*

## *Сулар сибәмен*

Туган көннәребезне туган-тумача, дусишләрне җыеп үткәргәнебез булмады, гаилә бәйрәме итеп үткәрә идек ул көннәрне. Туган көннәребез җитәрәк: «Ниләр ашыйсыгыз килә? — дия башлый идең, әнкәем. Бәйрәм табыны син әзерләгән тәмле ризыклар белән тулы була иде. Яз аенда туганнар өчен өстәл уртасына яшел бөреләре бүртеп кенә килгән агач ботакларыннан букет куела иде, җәй туганнар өчен, әлбәттә, түтәлдән яки кырлардан өзелгән чәчәкләр. Көз, кыш айларында туучылар да табигать матурлыгыннан мәхрүм калмады. Һәр мизгелнең үз яме бар, очкан яфракларын, яуган яңгырларын, ап-ак карларын бүләк итеп кабул итәргә мөмкин. Туган көннәребездә изге теләкләр ишетеп күңелебез дулкынланды, истәлекле матур бүләкләр белән кочагыбыз тулды. Көлдек тә, җырладык та. Көнебез дә, төнебез дә кояшлы булды. Син идең ул кояш, әнкәй! Бүген синең туган көнең. Бу көн җитсә: «Әнкәйгә нәрсә бүләк итәргә соң, матур күлмәкләре дә, яулыклары да күп, нинди бүләк сайларга?» — дип уйлаша идек. Уйларыбызны белеп калсаң: «Миңа бернәрсә дә кирәкми, янымда булсагыз, шул җиткән, минем өчен иң зур шатлык шул!» — ди идең. Бүләк табыла иде, бәләкәч кенә булса да, син аны зур итеп кабул итә идең. Бүләкне кулларыңа алгач безгә бәхет, озын гомер тели-тели шатлана идең. Киң күңелле идең, әнкәем, синдәге җылылыкның, яктылыкның чикләре юк иде. «Рәхмәт, әнкәй, бу дөньяга туганың өчен!» — дип әйтә алдым микән? Дөньяга гүзәллек өстәдең син, синең яшәү — тормыш авырлыклары белән көрәш бул-

ды — син җиңдең! Зар елаганың булмады, үзеңне бәхетсез ана дип санап минем күңелемне төшермәдең. «Бар яшәвем синең өчен!» — дип канатлы иттең син мине. Давылларга каршы очар канатларыңны гомер буе иңнәремдә тойсам иде!

Бүген синең туган көнең, әнкәй. Күңелемдә бәйрәм түгел, чөнки син юк! Кабереңә килдем, үзең утыртып үстергән гөлләреңнең чәчәкле ботакларын алып килдем. Тиз генә шиңмәсеннәр әле дип, гөлләрне сулы савытка утырттым. «Тәрәзә төбе тулып шау чәчәктә утырган гөлләрне өзмәсәң дә булыр иде, рәшәткәм эче тулы чәчәк бит!» — диясеңдер кебек, әнкәй. Әйе, чәчәккә күмелгәнсең син, тик шулай да сиңа бу көнне бүләксез киләсем килмәде. Гөлләреңне өзгән өчен гафу ит! Гомерең буена гөлләр үстердең, минем өчен үстердең син аларны. «Чыгып кырларда, болыннарда йөри алмыйсың, тирә-ягың чәчәк кенә булсын әле», — дидең, әнкәй. Гөлләр кебек яшәгәндә син авырып киттең. Хастаханәгә китәсе көнне иртә белән гөлләргә су сибеп йөрүең бүгенгедәй күз алдымда. «Терелеп кайтуымны теләгез!» — дип гөлләреңә әйтүең колагымнан китмәячәк. Чәчләрең кебек ак, яулыгың кебек кызыл, күлмәгең кебек көрән чәчәкле гөлләр белде микән, ә мин синең терелмәячәгеңне белә идем. Йөрәгем үксеп елады, күзләрем белән синең һәр хәрәкәтеңне күзәттем, хәтеремдә калдырырга тырыштым. Син минем җанымда яшисең, әнкәй.

*Гөлләргә су сибим әле,*
*Гөлләрем шиңмәсеннәр.*
*Гөле шиңгән, үзе дә ул*
*Шиңәчәк, димәсеннәр.*

Бу җырны әйтеп гөлләргә су сибеп йөрүләрең гомерем буе бәгыремне телеп агылыр бер моңга әйләнде. Юк, әнкәй, гөлләрең шиңмәячәк, синең гомереңне дәвам итеп, шау чәчәктә утырачак алар. Сине сагынып өзгәләнгән чакларымда, син булып, гөлләр мине юатачак. «Елап түгел, җырлап яшәргә кирәк», — диячәкләр. Бу бит синең сүзләрең.

Әнкәй, бүген синең туган көнең. Күңелемдә бәйрәм түгел, күзләремдә сагыш, яшь. Елама, дигән сүзләрең исемдә булса да, еламый булдыралмыйм, бигрәк тә бүген. Җыр, чәчәкләр, күз яшьләре — аларсыз яшәп булмый икән. Җырлап яшәрмен, синең кабереңә күз яшьләрем белән, тәрәз төбендә үскән гөл чәчәкләре белән килермен, әнкәй.

## *Зәңгәр чәчәкләр*

Юл буенда оя-оя зәңгәр чәчәкләр! Талгын җилдә тибрәлгән бу чәчәкләр миңа бик кадерле, төсләре хәтеремнән гомер буе җуелмас чәчәкләргә сөеп багам, өзгәләнеп багам. Кочагымны чәчәк белән тутырырга җыенмыйм, ике бөртек зәңгәр чәчәк өзәчәкмен. Зәңгәр чәчәкләр аллыгөлле чәчәкләргә күмелгән әнкәемнең кабернә куяр өчен өзеләчәк. Әнкәй күзләренә караган саен, җәен дә, кышын да зәңгәр гөлләр күрә идем. Зәп-зәңгәр иде шул күзләре, аяз күк йөзе, дөнья яктысы иде ул күзләрдә! Кояш булып балкый иде, язлар булып көлә иде, чәчәк булып яши иде ул күзләр! Чәчәк гомере бигрәк кыска шул, әнкәемнең күзләре иртә йомылды. «Күзләрең кырда үскән зәңгәр чәчәкләр кебек ма-

тур», — дип нигә генә әйттем икән! Әнкәй күзләренә баксам, авыртуларым басылды, күзләремнең яше кипте, иңнәремә төшкән авырлык җиңеләйде. Ә бит ул күзләрдә гел шатлык кына түгел иде, әрнүле яшьләрне да күп күрдем. Карашлары сөю белән тулы иде, димәк, сөю барыннан да көчле. Тормышның рәхимсезлегенә дә сөю белән җавап бирде, айга да, кояшка да, куерган болытларга да тутырып карады. Оятлы булырлык бер нәрсә дә кылмады ул, шуңа да туры карады, башын түбән имәде. Минем өчен күп елады әнкәй. «Бер гөнаһсыз сабыемны йөгереп йөрүеннән нигә мәхрүм иттең, ходаем!» — дип елый иде 5 — 6 яшьлек чагымда күтәреп иптәшләрем янына урамга уйнарга чыгарганда. Нинди язмышка дучар булганымны шулай ук иртә, әнкәй күзләренә карап аңладым мин. Шатланып та елады ул, минем тормышка гашыйк булып, матур эшләр эшләп яши алганыма сөенде. Шигырьләремне укып, җырларымны тыңлап, шатланып елады. Үзе миңа еламаска кушты, сабыр булырга өйрәтте. Киләчәкне бүген үк күрә белергә өйрәтте ул мине, хыялның чынбарлыкта кабатланачагына ышандырды. Зәңгәр күзләрен мәңгелеккә йомганда да: «Син елама, шатлыклардан еласаң да, кайгылардан елама!» — диде. Күп елады әнкәй, күзләренең зәңгәрлеге шатлыктан елаган яшьләрендә булган икән, әнә алар юл буенда зәңгәр чәчәк булып үскәннәр. Әнкәем күзләре булып карый алар, кояшка да, миңа да карыйлар. Әнкәйгә дип ике генә бөртек чәчәк өзәм!

## *Кабер ташы*

Кабер ташын бигрәк авыр итеп ясыйлар икән. Әнкәемнең исеме-фамилиясе, әткәсенең исеме, дөньяга килгән һәм дөньядан киткән көне, ае, елы язылган, берничә кисәктән торган кабер ташын 3 — 4 ирнең авырлык белән күтәреп машинадан бушатканын карап торам. Күзләремне яшь пәрдәсе каплаган. Әнкәем матур, аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләрен мәңгелеккә йомгач, миңа ничек авыр булса, ташларны күргәч тә шулай авыр булды — чайкалып киттем. Бигрәк авыр икән лә, кабер туфрагын бастырып, әллә бу ташларны куймаска гынамы соң?! Куймыйча да булмый шул: әнкәем үзе югалды, каберен югалтырга ярамый. Балалары гына түгел, оныклары да, аларның балалары да ерак әбиләренең каберен генә булса да белергә тиеш бит. Шуның өчен каберләргә язылган ташлар куела. «Вакытында белмәсәк тә кадерләрен, якыннарның белеп яшик каберләрен». Кабер ташына карап йөрәгемнең хәлсез генә тибүен тоеп торам. Йөрәк елый-елый шигырь юлларын кабатлый. «Кадерләрен, каберләрен!..» Кадеркәен белмәдекме, нигә шулай иртә югалттык соң? Әнкәй ризалыгын бирде, димәк, ул бездән канәгать булып яшәгән. Кайгылы булды, менә шул кайгысын гына җиңеләйтер чара булмады. Минем авыр язмышымны кайгысы итеп яшәде ул. Кайгымны да, үземне дә күтәрде. Минем авыртуларым аны сызландырды, уфтандырды, елатты. Хәлем әйбәт чакларда әнкәемнең шатлануыннан дөнья балкый кебек иде. Иңнәренә никадәр авырлык өйсә дә, тормышны каргамады әнкәй. Үзе белән бергә мине дә түзәргә өйрәтте. Кабер

ташын күргәч, әнкәйнең яшәгән еллары берәм-берәм хәтеремдә яңарып үтте. Авырлыклар күтәреп яшәде, инде кабере өстенә шундый авыр таш та куела! Йөрәгем кысыла, тешләрем шыгырдый.

— Йә, борчылма, балам, авыр була дип борчылма, күтәреп өйрәнгән бит инде мин. Миңа төшкән бөтен авырлыктан да авыррак бит сиңа мине югалтуы, түз берүк, сабыр ит! — дип әйтерсең лә, әнкәй.

Ташны кабер өстенә куялар, туфракны йомшартып, чәчәк үсентеләре утырталар. Кабер өсте аллы-гөлле чәчәкләргә күмеләчәк. Әнкәемнең аяк очына утыртылган каен — мин инде ул. Талгын гына җилдә тибрәлеп, ямь-яшел яфраклы кечкенә ботаклары белән әнкәемнең рәшәткәсенә тия каен. «Ике каен кирәк, ике кыз баласы булып, пар каен үссен», — дип пышылдап кына әйтә алдым. Әнкәй күтәргән бөтен авырлык минем җаныма күчте. Инде миңа тагы да көчлерәк булу кирәк. Сулышым киселгәнче, әнкәй кебек сабыр була белергә кирәк. Әнкәйнең җаны күкнең иң биек катындадыр, ә миңа кабер ташының салкынлыгын, авырлыгын тоеп җирдә яшәргә дә, яшәргә әле.

## *Кайгы*

Күзләр яшьле, карашлар — табуттагы гәүдәдә. Кызылга төрелгән, кара тасмалар белән уратып алынган табуттагы гәүдәгә кояш та соңгы тапкыр карый. Кояшны ярата иде бит ул, кояшка үрелеп үскән чәчәкләрне ярата иде! Чәчәк кебек кызны сөйгәндер ул, чәчәк бүләк итә алды микән? Үзе дә көнгә карап ачылган чәчәк кенә

иде бит! Кыядагы оясыннан күтәрелеп кенә киткән яшь бөркет-егет табутта ята. Кояш җылысы да кирәкми инде аңа, табутын әйләндереп алган чәчәкләрне дә күрми. Кайгыдан җаны кара көйгән эти-энисен, туганнарын, дусларын, күршеләрен юатырга теләп талгын гына җил исә. Юатыр көче юклыгын белә җил, шулай да читтә каласы килми. Җил егетнең ничек ауганын күрде, ул туган яктан сәлам алып барган иде егеткә. Ә анда — атышалар! Яраланып ыңгырашканнарны, җан биреп мәңгелеккә тынып калганнарны күрде җил. Бар да яшьләр, матурлар, нигә кирәк соң бу үлем китергән ут? Сугышка дип түгел, хезмәт итәргә дип озаттылар ич егетләрне, нигә атарга кушалар, нигә үтерәләр? Сәламен әйтергә дә өлгермәде җил, егет күкрәген тотып җиргә ауды. Җил егетнең ефәктәй йомшак чәчләрен сыйпап исте, әрнүләре бераз басылмасмы дип сак кына ургылып кан аккан ярасына өрде. Ничек кенә итмәсен җил, егетнең тыны киселде, чит туфракта җан бирде. «Көтегез, кайтырга күп калмады!» — дип яза иде бит. Кайтты, җансыз, утлы ярчыктан тишкәләнгән гәүдәсе кайтты! Егетне соңгы юлга озатырга яшь егетләр, кызлар бик күп килгән, бар да кайгылы. Кызлар арасында мәрхүм егетнең сөйгәне дә бардыр кебек. Әнә бит кызларның берсе бигрәк үксеп елый. Мөгаен, вәгъдә биреп калгандыр, матур хыяллар белән көткәндер. Әкияттәге кебек, егет кыз үбүдән терелә торган булса, юк, оялмас иде кыз, халыкны ерып табуттагы егет янына барыр иде дә, чәчләреннән сыйпар иде, иелеп иреннәреннән үбәр иде. Мәхәббәт нинди көчле булса да, үлгәнне терелтә алмый! Монда Ана мәхәббәте дә көчсез!

Егетне кабергә төшереп, өстенә туфрак өйделәр. Исеме язылган мәрмәр таш утырттылар, чәчәкләр куйдылар. Егермесе генә тулып килгән егет туган җир куенына керде. Ана куены буш калды. Хезмәтен тутырып исән-сау кайткан булса, улын кочаклап сөяр иде ул, шатланыр иде. Бүген ана кайгысыннан да авыррак кайгы юк.

## *Югалту*

*Лүзәнең якты истәлегенә*

Югалту — әллә ничә төрле була. Сөйгән ярмы ул, якын дусмы, әллә газизләрдән газиз баланңмы, яки ата-ананңмы, югалту газабы — иң авыр газап. Якын кешеңне үлем тартып алса, бу — бертөрле үлчәүләргә дә салынмый торган авырлык! Мин якын дустымны югалттым.

Хисләргә бирелеп, күңел бүлмәләрен шар ачып сөйләшә белгәне өчен, хыял канатларын җилпендереп ай-йолдызларга кадәр күтәрелә алуы, тормышны яныш сөюе, киләчәккә булган якты уйлар белән яшәгәне өчен ярата идем мин аны. Җирдәге гөлләргә, күктәге йолдызларга карап, шулар белән шатланып яши белү — һәркемгә бирелмәгән. Шатлыкларыбыз да, борчыларыбыз да уртак була торган иде. Канат чыгу белән оясыннан чыгып очкан кош кебек, дустым Лүзә дә авылдан яшьли чыгып китте. Ижевскига китеп, завод эшчесе булгач та, тормышка чыккач та арабызда хатлар йөрде. Кайткан чакларында яныма килми китмәде. Без аның белән бик сирәк кул кысышып исәнләштек, ул мине кочып ала иде. Тәүдә хәлемне сораша, аннары

иҗат эшем белән кызыксына, яңалыкларым белән танышырга тели. Дәфтәремдәге яңа шигырьләремне хисләргә бирелеп укый. Укып чыга да: «Минем күңелемдәгеләрне күчергәнсең бит, шагыйрә булсам, мин нәкъ шушылай язган булыр идем», — дип, дәфтәремне күкрәгенә кыса иде. Язганнарыма тәнкыйть күзлегеннән дә каравы бик ошый иде миңа. «Нигә алай, нигә болай түгел? — дип фикер йөртә иде. Әдәбият-сәнгать кешеләре турында сөйләшеп сүзләр бетми иде.

Бай табигатьле иде дустым. Мәрхүмнәрнең җаны күбәләк булып дөньяга кабат ярала дигәннәре дөрес булса, минем дустымның җаны сандугач булып яралыр. Авылыбызның чишмә буе талларына кунып сайраган сандугачларның берсе булыр ул. Гүзәллек турында җыр бар иде аның җанында. Шат чырае, каршымда бөтереләп биеп алулары хәтеремнән җуелыр төсле түгел. Беркөнне кызчыгы Әлфияне күтәреп, ана булу бәхетеннән балкып килеп керүе, гүзәлләрдән гүзәл картина сыман, күз алдымда һаман тора. Бәхет теләп баккан идем сабыена: «Атааналы, алтын канатлы булып үс», — дигән идем. Җиде яшьлек Әлфиянең күзләрендә моңсулык күреп үзәк өзелә. Әнисен юксына кызчык. Әй, шул зур машина, нигә Әлфиянең әнисен таптап китте микән, Әлфияне нигә әнисез калдырды икән?!..

Аннан алда дустымның гаилә бәхете челпәрәмә килгән иде. Ераткан тормыш иптәшеннән аерылып, кызы белән Себер якларына китеп барды. Аракы колына әйләнгән ире белән яшәргә теләмәде дустым. Аннан миңа сәлам хатлары килмәде, бер ел үтүгә, дустымны авылга табутта алып кайттылар. Мин аны соңгы юлга озатырга

баралмадым: сентябрьнең яңгырлы көннәре иде шул, коляска белән урамнан үтәрлек түгел иде. Җәй җиткәч, зиратка барып, дустымның каберенә чәчәкләр салдым.

Лүзәне җирләп, берничә көн үткәч, әнисе Сәлимә апага минем магнитофон тасмасында мәрхүмә кызының җырлаган тавышы язылып калуын хәбәр иттем. Гүр иясе булган газиз баласының тавышын ишетү ана йөрәге өчен яңа яра гына булачагын белсәм дә, түзмәдем шул, бәлки әле юатуым булыр дип тә уйладым. Җыр агылган арада гына булса да ана кызын тере итеп үз янында тояр, азрак йөрәгенә ял булыр кебек тоелды.

Сәлимә апа Әлфияне ияртеп килде. Магнитофон тасмасындагы җыр яңгырады:

*Туган яктан ерак китеп,*
*Диңгезләр кичтем.*
*Сагыш дигән тирән күлнең*
*Суларын эчтем...*

Сәлимә апа әрнеп-әрнеп кайгы яшьләрен түгә, Әлфия елмаеп миңа карап-карап куя. Балага җырның моңы да, сүзләре дә әллә ни тәэсир итми, билгеле, ә менә әнисенең тавышын танып алды ул — шуңа елмая. Мөгаен, ул үзен әнисе кочагында итеп тоядыр, рәхәттер сабыйга. Җырлап уйната иде бит аның әнисе — Әлфия моны бервакытта да онытмаячак.

Фаҗигагә бер ел үтеп китте. Янымда утырган Сәлимә апа күз яшьләрен түгә-түгә, кызының үлеменә багышлап үзе чыгарган сагышлы бәетен укый. Бәет тыңлыйм, үзем тәрәзәдән тышка карыйм. Агачлар яфрак коя. Каеннардан өзелгән сары яфраклар кайгылы ананың күз

яшьләре булып күренә. Агачтан өзеләсе яфрак өзелеп бетәр, ана күзләрендә яшь кипмәс.

*Кабер ишекләре булса,*
*Йөзеңә карар идем, —*

дип өзгәләнә ана йөрәге.

*Син яратып жырлаган җыр*
*Агыла һәркөн саен.*
*Гомереңнең бер моң булып*
*Калуыдыр, мөгаен.*

Һәм ул:

*Өстеңдәге күлмәгеңне*
*Нигә мандың алларга?*
*Әлдә Әлфиякәең бар,*
*Күңелемне алдарга, —*

дип, кызы Лүзәнең дәвамы булып үсеп килгән оныгы Әлфия барлыгына сөенечен белдерә. Сәлимә апаның яшьле күзләрен, йөрәк сүзләре язылган дәфтәр тоткан кулларының калтыравын күрү авыр, бик авыр. Бу авырлыкны җиңеләйтер бер генә чара да юк бугай!

## *Саубуллашу җыры*

Саубуллашу көеннән моңлырак көй юктыр бу дөньяда. Моң күңел кылларын өзгәли, йөрәкне меңгә телә.

Көз — моңлы җыр ул, диясем килә минем. Көзнең һәр көне, сәгате, минуты саен ул моңлы җырны ишетергә мөмкин бит. Көзге җилләр усаллашып иссәләр дә, үзләренә генә хас моңлы көйләрен көйләп исәләр, көйли-көйли агачлар-

дан яфрак чүплиләр. Яфраклар өзелеп, җиргә төшеп җиткәнне җырлыйлар. Сагышлы аларның җырлары, ямь-яшел бөре генә чакларын сагынып сап-сары булган алар. Яфраклар оча, сары күбәләкләр сыман алдыма килеп куналар. Бу минутларда чәчәк-гөлләр дөнья белән хушлаша. Хәлсезләнеп бөгелгәннәр гөлләр, юк, үләселәре килми, гүзәл булып тагын бераз яшиселәре килә дә соң, мөмкин түгел шул; болыт-пәрдә артыннан сирәк кенә карап алган кояш нурларында өмет юк, гөлләрне яшәтерлек көче юк нурларның. Әле ачылырга да өлгермәгән чәчәк бөреләре яшәү белән хушлаша.

Көзнең һәр авазы — саубуллашу авазы. Кошлар китә. Саубуллашып китә алар. «Сау бул, туган оя, сау бул, туган як», — диләр. Кошлар тавышыннан тирәкләр бөгелә, хушлашып, кошларга хәерле юл теләп сары чуклы яулыкларын болгый алар. Елга, күл буйларында да шул ук хәл, озату, кайда да озату. Аккошлар, казлар китәргә җыена. Моңсу каңгылдашкан тавышлары һаваны яра. Яр буе тулы — каурый. Камышлар баш иеп боекканнар. Ямансу, күңел тула. Җырлап китә кошлар, елап китә. Моңнары үзәкне өзә, күз яшьләре чулт-чулт су өстенә тама. Юк, яңгыр түгел бу, көне-төне сибәләп кенә торган яңгыр гына буламы соң?! Сәфәр чыккан кошкайларның күз яшьләре дә бу тамчылар. Китәләр. Әле генә баш очыннан бер оя кыр казы очып үтте. «Кыйгак-кыйгак», — диләр алар, «Сау бул», — диләр. Саубуллашу көе йөрәкне көйдереп ала. «Сау бул, сау бул», — кошлар тавышына синең дә тавышың килеп кушыла. «Сау бул!» Китәсең, син дә китәсең, туган авылың белән хушлашасың. Керфек очларыңа сагыш

кунган. Аерылышу минутлары ай-һай авыр, сиңа да авыр, миңа да. Китмә, дия алмыйм шул; сине ерак юлларың көтә. Кунак булып кына кайткан идең туган якка, инде китәсең дә, хуш, кадерлем, сау бул. Тиздән ак бураннары белән кыш килер, кыш артында яз бар. Язын кошлар кайта. Кошлар белән китәсең, кошлар белән бергә кайт, тагын кайт. Ләйсән яуган чакта көтәм сине. Әле көз, яфрак ява — китәсең. Саубуллашу көе йөрәкне үксетә.

## *Сагыну*

— Килдең дә, күңелемнең иң нечкә кылларында бер моң чиртә башладың. Үзәкне өзә бу моң, түзәр хәл юк, күзләрем яшьләнә. Нигә килдең, нигә елатасың син мине? Нигә газапларың шулкадәр авыр? Ни күреп әрнетәсең, яндырасың, көйдерәсең? Айлы төннәрдә дә, кояшлы көннәрдә дә гел янымда буласың. Янда гына буламы соң, җанда син! Йокларга дип мендәремә ятам, күзләремне йомарга өлгермим, синең моң йокымны очыра. Бераз вакыттан арып-талып йоклап китәм, таңда үксетеп уятасың. Бүген дә килдең, күзләремә мөлдерәмә кайнар яшь булып тулдың. Йөрәгем әллә ничәгә ярылырдай булып тибә-тибә дә, бөтенләй хәлсезләнеп кала. Иреннәрем кибә, тын алуы авыр, һава җитми. Нигә килдең соң, нигә мине шулай җәфалыйсың? Ах, килер юлларыңда адашсаң иде. Мин сине көтмим, көтмим, ишетәсеңме? Синсез генә яшим әле, килмә, яме!

— Киләм! Син минсез яши алмыйсың. Мин сиңа киләм, килми калалмыйм. Гомер буе килә-

чәкмен. Газапларың бик авыр булса да, сиңа минсез яшәү юк!

— Нишләп синсез яши алмыйм?

— Мин булмасам, син бәхетсез булыр идең. Мин сине моңлы иттем, тын гына, беркемгә дә күз яшьләреңне күрсәтмичә еларга өйрәттем. Мин сиңа килмәсәм, минем барлыгымны да белмәсәң, син утсыз-ялкынсыз, хыялсыз булыр идең. Киләм, сине кеше итеп яшәтер өчен дөньяда мин бар. Минем белән очрашу сиңа җиңел түгел, тик авыр газапларың сиңа рәхәтлек тә бирә. Шулаймы?

— Әйе, үксеп-үксеп бер елап алгач, җиңелрәк булып кала, күңел сафланып китә. Яралы кош кебек бәргәләнә-бәргәләнә дә, җан дигәнең бер тынычланып кала.

Син килгәч әллә нишлим, сыгылыплар төшәм шул, уйларым әллә кайларга китә. Син мине әллә кайларга әйдисең, сандугачлы бакчаларда да, ак буранлы кышларда да булабыз без. Син бүген дә килдең, иңнәремнән кочып алдың, күкрәгемә авыр моң булып тулдың, сагыну! Әйе, синсез яшәгәнемне белмим мин, гомер буе сагынулар белән яшәдем. Син мине хатлар язарга да өйрәттең, кулыма каләм алып шигырьләр язарлык илһам бирдең. Чынлап та, син булмасаң кеше кеше булалмас иде. Синдә бәгырь ташларын эретерлек көч бар бит! Нинди генә көчле кеше булмасын — бөгеп саласың. Син барыннан да көчлерәк, сагыну. Кил, сагыну, тере кеше сагышсыз булырга тиеш түгел. Син елатсаң да, яшь аралаш көлеп яши беләм мин. Әйдә, телгәлә йөрәкне, үткәннәргә кире кайтып булмаса да, туып-үскән авылыма алып кайтасың, мәрхүм әнкәм каберенә алып барасың, сагыну! Якын ке-

шеләрем белән очрашырга да синең белән барам. Сагыну, син шулай гомер буе миңа таныш яктылык, таныш карашлар, тавышлар булып килерсең.

## *Йөрәк тавышы*

Мең төрле чәчәк үсә яланда. Мин аның ал төстәгесенә эндәштем:

— Сине назлы җилләр иркәлиме, җылы кояшка үрелеп яшисеңме, ал чәчәк?

— Ал чәчәккә әверелгән синең йөрәгең мин, — ди чәчәк. — Мине тибрәтеп төрле җилләр исә, назлысы да, усалы да исә җилнең. Иртә бөгелгән чакларым була — терелэм, миңа мәхәббәт яшәү бирә. Лэйсән тамчылары кебек саф, шифалы бит ул сөю яшьләре!

— Әрнеткәч, газаплагач, гел генә бәхетле итмәгәч, кирәкми ул мәхәббәт. Ышанма мәхәббәткә, аның барлыгын оныт, оныт! — дигән идем, ал чәчәгем канлы яшен түгә-түгә сабагыннан сынып төште. Чәчәк шиңде, инде аны бернинди көч тә терелтә алмый.

Җаным өзгәләнгән шушы минутта: «Мин синең йөрәгең!» — дип яшел куакта тирбәлгән сандугач тавыш бирде. Сайрады да сайрады йөрәк-сандугач, елады да, җырлады да шикелле.

— Җитте, сайрама, түкмә моңнарыңны, — дидем сандугачка. — Түгеп кенә бетерерлек түгел бит синдәге моң да, сагыш та. Өзгәләнмә шулкадәр. «Яратам! Яратам!» димә, исемен кабатлама. Ул барыбер сине ишетми, ул үзенә сине тиң итми!

Сандугач кунып сайраган ботагыннан җиргә килеп төште дә, канатларын соңгы тапкыр җил-

шеп, жан бирде. Кулларымны күкрәгемә куеп, күзләремне йомдым. Янам, ялкында куырылам. Күзләремне ачтым: дөнья балкып тора.

— Мин синең йөрәгең!

Йөрәгем ялкынга әверелгән.

— Син шулай яктырттыңмы, җылыттыңмы дөньяны?

— Мин! — ди ялкын — йөрәгем. — Түз генә, ничек кенә янмам-көймәм әле мин! Яраткач, янып яратырга кирәк.

Мин — мәңгелек ялкын, мине сүндерерлек көчле җил дә, давыл да юк бу дөньяда!

— Бар шул, бар, — димен мин. — Син — ялкынны сүндерергә әллә ни дә кирәкми бит, сөйгәнеңнең салкын карашы, бер авыр сүзе боз булып яудымы — син сүнеп калачаксың. «Ярат-ма! Сагынма! Көтмә!» Боздан да салкынрак сүз-ләр болар. Ялкын — йөрәккәем, сиңа бу өч сүзне әйтеп китте бит ул!

Күкрәгемдә мең яралы йөрәк тибә: үзе әрнеп-әрнеп елый, үзе яна, үзе туңа. Йөрәгем белән беренче тапкыр шулай каты итеп сөйләшәм:

— Әрнеп елауларың, янып-туңуларың авыр-лардан авыр газап бит. Тибүеңнән тукта, йөрә-гем!

Йөрәгем тавышын ишетәм:

*Яшәүдән туктау юк әле,*
*Утларым алсын өтеп,*
*Йөрәк булгач, йөрәк булам,*
*Тибәм дигәч, тибәм әле*
*Сөеп, сагынып, көтеп!*

Йөрәк белән килешми булмый шул, ул бит минем күкрәгемдә!

## *Мин сиңа ышанам*

Талчыбыкны ат итеп атланып урам буйла■ чапкан малай түгел инде син: мыегың чыгы■ килә, егет булгансың. Көннән-көн көчең арта. Кара әле, беләкләрең нинди көчле! Егет кен= түгел, кыядан күтәрелгән бөркет итеп күрәм си- не. Күктә бөркет, җир шарын кочып алырда■ булып, як-якка канатларын җәя. Талгын гына бер көйгә әйләнә дә әйләнә. Бөркет тамагын туй- дырыр өчен җан ияләренә ташлана, ул — ерт- кыч. Син ерткыч булма, егетнең ерткычлыгы бәхетсезлек белән чикләнә.

Әле син шундый матур, батыр булырыңа да шигем юк. Мыегыңны әйтәм, шундый килешеп тора, берьюлы әллә ничә кыз гашыйк булыр, валлаһи! Син әле җитеп кенә киләсең, ныгый гына башлагансың. Харап итмә үзеңне: авы- зыңны сасытып тәмәке суырма, аракы эчмә. Кимерчәкләрең әле сөяккә әйләнмәгән, башта ныгып җит, акыл тупла. Вакытлар үтү белән: «Эчәргәме, тартыргамы, кирәкме бу нәрсә- ләр?» — дип үзеңә-үзең сорау бирерсең. «Юк, кирәкми!» — диярсең кебек, син бит сау-сәламәт булып яшәргә тиеш.

Мин күзләреңә карап барын да аңладым: син гашыйк! Читтән генә күз атасың әлегә, озатып барырга ояласың. «Озата барганда ничек сүз башлап,ниләр сөйләргә микән?» — дип уйлана- сың син. Кыз йөгерә, син куасың, барып җитеп беләгеннән тотып аласың да капкасыннан керт- ми җәфалыйсың. Кочакларга иткән буласың, калку күкрәкләргә үреләсең. Юк, бу син түгел, бу тәртипсез егетләр эше. Чын гашыйк үзенең күз карашлары белән кызны үзенә әсир итә

Йөрәгеннән чыккан сүзләрне сөйли ул, юк-бар белән дөнья бизәргә маташмый, ялган бизәкләрдә матурлык күрми. Чын, саф мәхәббәткә омтылган егет җанында бозыклык булмый. Син чәчләре дулкын-дулкын, кашлары кыйгач кызга карап дөрләп янасың. «Ул мине күрә микән, ул да яратыр микән?» — дип тибә синең йөрәгең. Күрер, барын да аңлар. Бәлки, әле ул да сиңа әллә кайчан гашыйктыр, башлап үзе әйтмәс инде. Кояшлы яңгырдан соң күктә калыккан аллы-гөлле салават күпереннән килүеңне көтәдер ул синең. Айлы төннәрдә әллә ул йоклап ятамы, син дә йокламыйсың бит! Сез егетләрнең бер ялгыш фикере бар: «Хәзер сафлык юк!» — дисез. Нишләп булмасын?! Син бу ямьсез уй белән якын барма кыз балага, гомерлек рәнҗү алырсың, күз яшеннән курык. Бәхетен югалткан кыз белән чәчәктәй саф кыз баланы бутама берүк. Мәхәббәт акылдан да яздыра, сак бул, үзеңне дә, сөйгәнеңне дә үкенү газаплары белән җәзалама. Сөясең икән — син аны елатма, дәртең ташып торсын, хисләрең чайпалып түгелсен, кызга кагылма. Үзең өчен, бәхетле гаиләң өчен чәчәк килеш сакла аны. Ул сине бәхетле итәр.

Сөйгән кызың белән очрашыр кичегезне күз алдыма китерәм. Зәңгәр нурлар бөркеп торган гашыйклар төне. Гашыйклар төне караңгы булмый, син моны үзең дә беләсең инде. Әллә ничек, кыюлыгың җитеп сөйгәнеңне кочагыңа аласың. Бар дөньяны кочасың кебек син. Синең кочагыңа җирдәге, күктәге, хыялдагы матурлык бергә сыйган. Син бәхетле. Син генә түгел, ул да бәхетле. Сездәге бәхетнең чиге юк! Син кызның утлы иреннәренә үреләсең, әлбәттә, ул каршы килми.

Беренче үбешүдән соң кызлар татлы яшьләрен түгә, ә менә егетләр нишлидер, анысын белмим. Син әлегә бәхетсез мәхәббәт турында ишетеп кенә беләсең, ходай үзеңне шундый язмышка дучар итсә, бөгелеп төшәрсеңме, күкрәп үскән агачка барып, муеныңа бау киярсеңме? Коточкыч! Мондый хәлләр булып тора, мин синнән бу акылсызлыкны көтмим. Егетлек булсын синдә, авырлыкларны җиңәр көч булсын! Син көчле, көчеңне белемгә һәм хезмәткә бир. Синең әле ышанычлы солдат, сөекле ир, акыллы ата буласың бар. Мин сиңа ышанам, егет!

## *Яшә, сабый!*

Сабыем, әле син кечкенә. Дөньяга килүеңә дә бит бары ярты гына ел. Әле син берни дә белмисең. Юк, юк, белмисең түгел, беләсең. Ашыйсың килгәнне белдереп, үз яныңа әниеңне чакырып китерә беләсең; кулларга алып уйнатканда, күңелләрне шатландырып, бар дөньяны балкытып көлә беләсең; уенчыкларыңны тотып алмакчы булып, кулларыңны суза беләсең. Исемең белән эндәшкәндә, башыңны боргалап, тавыш килгән якны эзлисең. Менә син шушыларны беләсең. Дөнья сиңа хәзергә тоташ бер сер. Шушы сер әкренләп сиңа ачыла барачак. Син әле барын да белерсең, барын да күрерсең. Дөньяның яктылыгын, гүзәллеген күреп сокланырсың әле син. Тормыш — нәрсә ул? Син әле шушы сорауга җавап бирерсең. Тормыш — бик катлаулы, бормалы-бормалы юллардан тора ул. Ягымлы да, шул ук вакыт усал да ул. Менә синең кебек матур итеп елмая да белә, назлап иркәли

дә кайчак. Усал чаклары күбрәк. Тормыш сынарга ярата. Авырлыкларны җиңә белгән, көчле рухлылар күбрәк кирәк тормышта. Тормыш — матур, асыл бизәкләр белән тулы. Менә шушыларны аңларга, күрергә, тормыш матурлыгына хуҗа була белергә кирәк. Бер сүз белән әйткәндә, тормышны яратырга кирәк. Менә шул чакта инде син үзең дә тормышның бер бизәге булып, син аны тагы да матурлатырсың. Шушы матурлыкны күрмичә, тоймыйча яшәүчеләр дә бар бит. Сиңа шулар белән дә очрашырга туры килер әле. Гомер бер генә бирелгәнен әллә инде алар белмиләр. Син аларга шуны аңлатырсың әле.

Моны аңлавы әллә ни авыр да кебек түгел.

Сабыем, бу дөньяда язмыш дигән нәрсә дә бар. Һәркемнең язмышы үзенчә, һәркемгә төрлечә бирелә ул. Кайсыларын гомер буе иркәли, кайсыларын йодрык белән тукмый. Иңнәренә салып гомер буе авыр йөк тарттыра, газаплардан башын чыгармый. Мондый язмыштан бөгелеп калган, зар елап, тормышны каргаганнар юк түгел. Миңа боега белмәгән күңелләр, көрәшләрдә җиңеп чыкканнар, яшәүнең никадәр матур икәнлеген аңлап, һаман да яхшыракка омтылып яшәүчеләр күбрәк ошый.

Бу дөньяда ялган һәм дөреслек бар. Син аларны аера белерсең әле. Ялган — кап-кара, ә дөреслек — ап-ак кигән булыр, син аларны бутамассың, күрә генә бел.

Тормыш җиле сине сөеп, назлап иссен, язмыш сине кочагында иркәләсен. Син дөньяга яшәр өчен тудың, яши бир, сабыем!

## *Кар чәчәкләре*

Күбәләкләп кар яуганда рәхәт тойгыларга бирелеп, мәшәкатьләремне онытa язып, тынып кала идем. Шундый тынлык: йөрәгемнең леп-леп тибүе, күңел кылларымның сызылып кына әле бер композитор да ишетмәгән шатлыклы көй чыңлатуы бар дөньяга ишетелеп торадыр кебек иде. Шундый сихри минутлар кире әйләнеп килсен иде тизрәк. Сагынам мин ул минутларны, сагынам. Минутлар гына булса да, алар җан өчен бер озын гомер кадәр булып тоела иде.

Кар ява! Ак бураннар арасында адашып каласым килми. Күңел адашмасын, тулпарымның җилләрдә җилфердәгән ефәк ялына нык ябышам, берүк читкә тайпылмасын, юлын дәвам итсен, барыр җиремә илтеп җиткерсен. Ап-ак карларга төренеп тынычланып калалмыйм, тәрәзәм каршында күпме кар бөртекләре очса — уйларым шулкадәр. Кар ява! Быел да кар күп. Кырларда иген уңар. Алмагачлар алмалы, аланнар җиләкле, болыннар чәчәкле булыр. Яз җырын җырлап агачак гөрләвекләр, шарлавыклар бит бу кар бөртекләре! Менә шушы матурлык хакында гына уйлыйсы килә дә бит... Кар аклыгы, кар яктысы белән генә тулышмаган күңел, бүген мин һава тулып яуган карны күз яшьләренә охшатам. Кар өстендә кан күрәм, атышкан, ыңгырашкан тавышлар ишетәм. Җир йөзе фаҗигаләр белән тулы. Җанны тетрәткән хәбәрләр күңелгә борчу салды, төн йокысыз калдырды. Тәрәзә пыяласына сыланган карлардан күңел гөлләренә салкынлык бәрелә. Җир шарын әйләнеп, уч төбедәй җирне дә калдырмыйча явадыр кебек бу карлар. Чынлап та шулай булсын

иде, әйе, мин аның шулай икәненә ышанам да. Һава дулкынында тирбәлгән ак карларга: «Явыгыз, карлар, явыгыз, аклык, сафлык кирәк, бик кирәк дөньяга. Тормышны явызлык түгел, изге эшләр генә бизи ала. Кеше күңелен кердән чистартып явыгыз, карлар!» — дип кычкырасым килә. Мәңгелеккә кар таулары астында күмеп калдырасы килгән нәрсәләр күп, алар бүгенге ата-ана назыннан мәхрүм калган сабыйларның елау тавышы, үз күршесе, хезмәттәше гайбәтеннән яраланганнарның сызлануы, авыр югалту газапларына дучар булганнарның ыңгырашуы, хыянәт телгәләгән йөрәктән тамган кан, төзәтеп булмаган ялгышлар, үкенүләр!..

Юк, тыныч кына күзәтеп булмый яуган карларны. Дөнья хәлләре төрлесен уйлата. Кар бөртекләре уйларымны белми, алар үзләренең аллы-гөлле чәчәкләр булып җилләрдә тибрәләчәген генә белә бугай.

## *Аклык*

Кар ява. Кышның нәкъ шушындый көнен ярата да инде Сәрия. Иге-чиге булмаган зур дөнья тик аклык, сафлык белән генә тулган. Бу минутта дөньяда кайгы-хәсрәт, авыр газапларның эзе дә юк. Әйтерсең лә алар беркайчан булмаганнар да. Ә бит бу шулай тоела гына. Юк, юк, Сәрия хәзер ул хакта уйларга теләми. Кешеләрнекен дә, үз язмышы авырлыкларын да онытып торасы килә аның. Азга гына булса да онытасы килә. Кар бөртекләре саен бәхет, шатлык күрәсе килә. Ап-ак кар бөртекләре сыман саф хисләр кереп тулды Сәриянең күңеленә. Кар

яуганда бигрәк тә матур күренә бу дөнья. Тәрәзәдән тышка карый Сәрия, урам тулып очкан кар-күбәләкләрне бармак очларына кундырасы килә аның. Ләкин бу мөмкин түгел; тирә-як матурлыгын тәрәзәдән генә күзәтеп яши Сәрия. Шуңа да канәгать. Тәрәзәдән кергән матурлыкка күңел тәрәзәләрен ачып куя ул. Дөнья матурлыгына ияреп илһам керә Сәриянең күңеленә. Менә әле дә иреннәре шигырь пышылдый түгелме соң:

*Кар ява, тула дөньяга*
*Өр-яңа аклык, сафлык.*
*Әйтерсең кыш күңелләргә*
*Өләшеп йөри шатлык.*

Суык булса да, кышның үз матурлыгы бар шул. Ап-ак карлары белән матур ул. Шул ак карны шыгыр-шыгыр китереп йөгерер дә йөгерер иде Сәрия, хәле бетеп егылганчы йөгерер иде. Яңа гына яуган мамык кар өстендә бала-чага кебек тәгәрәп уйнар иде, шаркылдап көлә-көлә тагын торып йөгерер иде. Кар бөртекләре керфекләренә кунып, шатлыклы күз яшьләре белән бергә эреп, яңаклары буйлап агар иде. Их, нинди рәхәт булыр иде.

Бу — Сәриянең егерме тугызынчы кышы. Карлы юлда бер генә адым да ясаганы юк аның. Җиде яшенә кадәр тотынып йөргәнен яхшы хәтерли. Ата белән ана дәва эзләп, кызларын кая гына алып бармадылар. Өметләнделәр. Кызларын, беренче балаларын коточкыч язмыш кулында күрәселәре килмәде. Ләкин зур бәхетсезлек тормышларына килде: Сәрия аягына басалмады. Кеше ярдәменнән башка яткан урыныннан да торып утырырга көче булмаган Сәри-

яне авыл укытучылары өйгә килеп укырга-язарга өйрәттеләр. Якыннары, дус-ишләре боегырга ирек бирмәделәр кызга. Азга гына да ялгызын калдырмадылар аның. Бергә уйнадылар, бергә көлделәр. Сәрия үзе дә бала гына чагыннан ук кешеләрне яратты.

Еллар су булып акты, җил булып исте. Яшәлгән еллар арткан саен уйлар куера, борчылулар чиксезләнә барды. Сәрия күбрәк сызлана, ешрак елый хәзер. Еласа да, күз яшьләрен аның беркемнең дә күргәне юк. Әнкәсенә дә күрсәтми ул күз яшьләрен. Әрнемәсен җаны, болай да газаплы бит ул, ди.

Кар ява. Юк, Сәрия бу минутта язмышы хакында уйламый, аның җанын шигъри илһам газаплый. Газаплый да, назлый да аны бу илһам.

Күңел дәфтәренең ак битләренә шигъри юллар тезә Сәрия. Кәгазьгә күчереп алыр да ул аларны, дусларына укытып карар. Язганнарына беренче консультантлар аның дуслары. Тик дөресен әйтеп бетермиләр кебек: һәр шигырьне әйбәт, матур дип табалар. Матур әсәрләр иҗат итәрлек көче, белеме юклыгын Сәрия белеп тора бит. Шулай да, сирәк булса да шигырьләре дөнья күрә аның. Уңышлары чиксез шатландыра Сәрияне. Тагын да канатланып китә ул, яшәгән саен яшисе килә, елар урында күбрәк елмая.

Җәйге көннәрдә, дулкынланып шаулаган иген кырлары кочагында Сәрия үзен бик бәхетле тоя. Авылдашлары хезмәтен үз иҗатында яктыртасы килә аның. Шулчагында гына тулы бәхетле булачакмын, ди ул. Сәрия бер нәрсәгә кызыгып яши. Кошларга кызыга ул, аларга соклана.

*Кайгысыздыр канатлы кош,*
*Ул бит — күкләр киңлегендә, —*

ди ул, очып барган кошларга карап. Кош булып очасы килә аның. Бу тормышка ашмас хыялыннан үзе көлеп тә куя. Син көчле, диләр аңа. Әллә юри генә, күңелен табар өчен генә әйтәләр инде. Әгәр бу шулай булса, Сәрия моны гафу итми. Ялганны җене сөйми аның. Бер балкып, бер сүрелгәнне дә килештерми. Йә балкы гына, йә бөтенләй булма — кирәгең юк. Үз кайгың да җитәрлек, кешеләр өчен борчылма, дисәң, ул сине яратмаячак. Кешеләр өчен көя, кешеләр өчен шатлана. Тормыш матурлыгына хуҗа булып, матурлык өстенә матурлык өстәп яши белмәгәннәр азмыни дөньяда?! Сәриянең аларны өзгәләп ташлыйсы килә. «Ах, минем коляскама утыртып торырга шуларны бер генә көн, — ди ул эчке бер әрнү белән. — Сәламәтләр, көчлеләр, ә яши белмиләр».

Нинди генә ялкыннар юк Сәриянең йөрәгендә?! Яшәү ялкыннары, сөю ялкыннары бар анда.

*Яна белмәгән йөрәк*
*Күкрәккә нигә кирәк?!*
*Мәхәббәтсез йөрәкнең*
*Типмәве хәерлерәк, —*

ди Сәрия. Мәхәббәт дигән олы хис Сәриянең күңел дөньясында да яши бит.

Күпне кичергән йөрәк килер авырлыкларны да җиңәр кебек. Җиңәлмәсә? Күпме көрәшергә була?! Бирешеп калса? Соңгы вакытта кулына каләм дә тоталмау куркынычы борчый башлады Сәрияне. Бердәнбер эшли алган эше, язышa да алмаса, бик авыр булачак.

Күңелендәге шатлыкларын, сагыш-моңнарын кәгазьгә ничек күчерер? Бу коточкыч уйдан Сәриянең күз аллары караңгылана, йөрәге кысылудан иреннәрен тешли. Куллар көннән-көн хәлсезләнә, Сәрия моны сизеп яши. Бирешмәскә, авырлык килә калса да бирешмәскә, ди ул, язмышка буйсыныр хәлем юк. Кеше — көчле булырга тиеш. Кеше көчле җилләргә каршы яшьнәү-күкрәү булып барырга тиеш.

Кар ява. Сәрия тыштан күзләрен алалмый. Нәни генә кар бөртекләре шулкадәр рәхәтлек бирә Сәриягә, кар аклыгы күңел бүлмәләрен балкыта. Менә бит, нәни кар бөртеге нинди зур көчкә ия.

Кар яуганын беренче генә күрәмени?! Матурлык эченә кереп чумган да, онытылган, тын да алмый кебек, иреннәре генә һаман шигырь пышылдый:

*Өр-яңа кеше булып мин,*
*Тудым күк әле генә.*
*Күңелгә тулган мөлдерәп*
*Тормышның яме генә.*

— Әнкәй, кил әле, — диде Сәрия. — Тәрәзә төбендәге гөлләрне бер читкәрәк күчереп куйчы, тыш яхшылап күренми.

Кызының бу минутларда ни белән яшәвен ана йөрәге сизеп тора.

— Бүген көн матур шул, — диде ул. Кызы көн яктылыгы белән елмайды. «Күрче, әнкәй, бүгенге көн кебек, минем күңелем дә матурлык белән туп-тулы», — ди иде аның бу елмаюы.

Әнкәе шау чәчәккә төренгән гөлләрне тәрәзә төбеннән өстәлгә алып куйды, тәрәзәгә яртылаш төшеп торган челтәрне күтәрде. Рәхәтләнеп,

туйганчы карасын, дигәндер, Сәрияне коляскасы белән тәрәзәгә якынрак китерде. Их, менә хәзер Сәриягә бер уч кар кертеп бирсеннәр иде.

Дуслары күп — Сәрия янына килеп кенә торалар. Язын умырзаялар алып киләләр алар. Җәен Сәриянең үзен табигать кочагына алып чыгып, андагы бар булган гүзәллекне бүләк итәләр. Көз җитсә, сары яфраклар җыеп, Сәриянең алдына китереп салалар. Тик Сәриянең күңелендә дусларына карата чак кына үпкә бар. Кышның бүләк итәрдәй бернәрсәсе дә юк, диләр микәнни? Ә кары, ап-ак кары?

Сәриянең бу турыда беркемгә дә сөйләгәне юк. Белерләр әле, ди ул, бүләкне сорап алаларлармыни?!

Күк йөзеннән кар болытлары таралды. Сүрән кояш нурларында кар бөртекләре җемелдәп китте. Сәрия карашларын еракка төбәгән килеш тик матурлык турында гына уйлады бу минутларда.

## *Хатлар язам*

Хат алмаган көнем сирәк минем. Бүген дә хат ташучы апа кулыма ике хат бирде. Мин аңа рәхмәтне әйттем дә, иртәгә дә хат алып кил, дидем. Әйе, иртәгә дә хатлар булыр.

Ә бүгенге хатның берсе синнән, дустым. Кич утырып, сиңа җавабымны язам. Өй җылы, якты. Килгән хатлардагы ялкынлы сәламнәрдән күңелемдә дә җылы, якты. Күңел дөньям чиксез ямь белән тулы. Яңа көнемне сәламләү белән хатлар көтә башлыйм. Һәм ул килә. Ап-ак күгәрчен итеп күрәм мин кулымдагы хатны. Хатлардан

имин хәбәр көтәм. Өчәр-дүртәр хат алган көннәрем бар. Хатларны күкрәгемә кысып шатланам, кат-кат укыйм үзләрен. Гөлләргә яуган җылы яңгыр кебек шифалы да, аллы-гөлле салават күпере калыккан күк йөзедәй матур да була ул хатлар. Хатларны язучылар арасында туганнарым, дус-ишләрем һәм бөтенләй таныш булмаганнар да бар. Хатларның кайсыберләре уйланырга, борчылырга мәҗбүр итә, күз яшьләремне түгә-түгә укыганым бар. Юк, мин бүген андый хатлар турында сөйләшергә теләмим. Җанга рәхәтлек биргән, иңнәргә канат куйган хатлар күбрәк килә бит! Шундый хатлар күпләп килгәндә мин: «Бу хатларның берсе генә миңа килсен иде дә, ә калганнары хат көтеп тилмерүчеләргә булсын иде, дип куям. Бар бит ул хат көтеп яшәүчеләр. Туганыннан, якын күргән кешесеннән хатлар көтеп күпме күңелләр өзгәләнә! Айлар буе, еллар буе газиз баласыннан бер генә сәлам хаты да алалмаган ата-аналар да юк түгел. Исән-сау яшәүләрен белдереп, язсалар соң! Боек күңелләрен балкытып, аларның да баш өстенә кояш күтәрелер иде бит. Гаиләсеннән аерылып киткән атадан хат көткән балалар да бар.

Гомере буе бер генә сәлам хаты да алмаганнар да очрый. Хатның ни икәнен дә белмидер алар. Кызганыч. Беркеме дә булмаганлыктан түгел, кемнәредер бар аларның, язмыйлар, хат кына язмыйлар.

Хатлар алам һәм хатлар язам. Бик күпләргә язам мин, үзем өчен дә язам, язмаганнар һәм язалмаганнар өчен дә, яза белмәгәннәр өчен дә язам. Өлкән яшьтәге әби-бабайлар үтенечен кире какканым юк: кадерле кешеләренә хатлар язам. Рәхмәт хатлары язуы бигрәк күңелле. Күр-

ше әби читтәге кызына хатны еш-еш яздыра. Әледән-әле күчтәнәчләр җибәрә кызы белән кияве. Рәхмәтләр укый-укый и язабыз хатны, күрше әбинең шатлыклары — минем дә шатлыкларым! Ак бабай яздырган хатлар үзгәрәк. Армия сафларында хезмәт итүче оныгына яздыра ул: «Без — сугышта җиңүчеләр, сез — оныклар, гүзәл тормышыбызның тынычлыгын уяу саклаучылар, йөзгә кызыллык китермәгез!» Мондый сүзләрне көн дә язарга булыр иде.

Хат язмаган көнем сирәк була. Язган хатыма җавап килгәнне көтеп тә тормыйм кайчак, янә язып салам, бара торсын якын кешемнең, күңелкәен күрә торсын, димен. Кайгылы булса юатырмын, шатлыклары булса бергәләп кичерербез дип, хатларым булып якыннарым янына ашыгам. Кеше күңеле — тирән күл, төптә әллә ниләр ята. Әнә шул әллә ниләреңне кемеңәдер хат телендә сөйләп бирәсең килә, юк, язмыйсың, сабыр итәсең, газапларың авыр булса да, түзәсең. Күп вакыт сөйләр сүзләрең күңел кәгазьләренә генә языла. Адресы язылган конвертка салынмый ул хатлар, алар күңелләрдә сагыш-моң булып яши. Мәхәббәт хатлары болары, яшерен һәм җавапсыз мәхәббәт хатлары. Айлы төндә, ай нурлары яктысында языла ул хатлар, энҗеләр итеп тезелгән йөрәк сүзләре, саф хисле тойгылар, сагынулар анда.

Дустым, хатлар язган чакта ниләр кичерүемне син белдең инде. Чылбыр-чылбыр хат юллары аралардан бер генә дә өзелмәсен иде! Өзелмәслек итеп ныгытыйк без аларны, дустым. Язышмаганнар өчен дә язышыйк, мәңгелеккә тумаганбыз, үтмәсен гомер заяга, үкенерлек булмасын!

## *Елның иң гүзәл чоры*

Яз башлаучы тамчылар! Тамчылар тавышына колак салу белән, дөньяңны онытасың.

*Җырлый-җырлый тамчы тама*
*Тып-тып, тып-тып.*
*Тыңладым да бу яз моңын*
*Алдым отып.*

Тамчы тамган көйгә күңел шулай җырлый башлый.

*Хисләремне ярсу иткән*
*И шаулы яз.*
*Күңелемне иркәләгән —*
*Ул синең наз.*

Җырлап кына да бетерерлек түгел бу язның матурлыгы, мең төрле бит, мең төрле матурлык. Рәхәтләнеп көләсең, шатланасың, сагынулардан сабырсызланып үксеп-үксеп елыйсың да язларда. Үзәкләрне өзәр моңнары азмыни язның? Тамчылар тамуына күңел күнегә башлауга, канатларын җилпи-җилпи кошлар кайта. Кара каргалар карылдавы да, сыерчыклар сызгыруы да моңлы итә мине. Гөрләвекләргә кушылып, көлә-көлә йөгерәсе килә. Елгаларда боз кузгалгач, ярга басып, ташкыннар ярсуы белән йөрәк хисләре ярсуын чагыштырып карыйсы килә — кайсысы көчлерәк микән? Шаулап-гөрләп ага да китә кар сулары, кабынган хисләрне тиз генә сүндерермен, димә — хисләр ярсуы көчлерәк.

Язның һәр көне, һәр сәгате, һәр минуты матурлык белән тулы. Андагы һәр аваз, һәр тавыш — матурлык. Кырлардан ишетелгән трак-

торлар тавышы, җир кешеләренең хезмәт шавы күңелдә җыр тудыра.

*Кар юрганын ачып ташлады җир,*
*Ярсып акты язгы ташкыннар.*
*Хезмәт шавы белән гөрләп торган*
*Кырларыма күңел ашкына.*
*Колачларын җәеп, киң басулар*
*Каршы ала шулай һәр таңны.*
*Кырга килә кеше, данлар өчен*
*Чын хезмәте белән Ватанны.*
*Күңелләрне чиксез шатландырып*
*Дулкынланыр бодай-арышы.*
*Кулларында бүген игенченең,*
*Килер уңышларның язмышы.*

Мин бу мәлдә үземне киң кырлар кочагында итеп хис итәм. Җаныма тулган рәхәт тойгының чиге юк. Кырлар буйлап сызылган буразналар арасында йөрим кебек.

*Бураздалар, тәүге бураздалар,*
*Тәүге адым — яңа бәхеткә.*
*Икмәк исе килгән кыр һавасын*
*Сулап йөрү — үзе бәхет лә.*

Яз — кешелек тормышына бәйрәм китерүче, хәлсез канатларга көч бирүче дә, сүнеп барган өметләрне балкытып җибәрүче дә. Яз ул елның иң гүзәл, шул ук вакыт иң көчле чоры. Яз күңелләрдән китми, яз җырлардан китми.

*Җырлыйм язгы матурлыкны,*
*Ярсу чагы хисләрнең.*
*Алсу чагы иртәләрнең,*
*Зәңгәр чагы кичләрнең.*

## *Май ае*

Мин бүген кулыма каләм алмый булдыра алмадым. Күңелемдәге ташып торган шатлыклы тойгыларымны кемнәр белән булса да бүлешәсем килә. Шатлыклы минутларымның һәрберсе кешеләр белән уртак булсын иде. Бергә күрү, бергә ишетү, бергә тою нинди күңелле.

Май кояшы дөнья балкытып елмайганда, ничек итеп боекмак кирәк?! Ләйсән яңгыр явып үтте, бөре исе килгән яз һавасын сулап туярлык түгел.

*Һәр агачта миллион бөре*
*Ачылды бүген.*
*Күзгә күренеп яшәреп*
*Килә тирә-юнь.*
*Үтсә үтәр берничә көн,*
*Һәм күз алдында,*
*Ачылып китәр ямь-яшел*
*Чиксез зур дөнья.*

Бу шигыремне өч-дүрт көн элек язган идем. Бүген инде чынлап та тирә-ягым ямь-яшел. Хәтта искән назлы җилләренә кадәр яшел кебек.

Март — беренче тамчылары, апрель ярсу ташкыннары белән матур булса, май чәчәкләре белән җирне бизи. Бакчаларда, болыннарда — гөлләр, кырларда иген шыткан чак бит бу.

Көн матур, килере тагы да матуррак. Шомырт, чия агачларының, алмагачларның ап-ак чәчәккә төренәсе бар әле. Сандугач та килер инде тирәгенә. Тәрәзәләрне ачып куеп, рәхәтләнеп яшәр чак җитте. Май аенда матурлык җитәрлек. Җиргә генә түгел, һәрбер кеше күңеленә кочак-кочак матурлык алып килә май ае, һәр күңелгә шатлык өләшә.

## *Иңнәрдә — канат*

Бүген күңел төшенкелегенә бирелү мөмкин түгел. Әгәр боегып калсаң, шатлыкларыңны кире кагу булыр иде бу. Шатлыкны кире какмыйлар, шатлыкны күтәп алалар. Һәркемнең өмете яктыдыр бу көннәрдә, бу һичшиксез шулай булырга да тиеш. Авырулар да бүген үз хәлен яхшырак сизәдер. Мин беләм, иң авыр хәлдәгесе дә үлем хакында түгел, яшәү хакында уйлый, өмет итә. Ул шуңа да яши, ул үлемне җиңәчәк. Шушы көнне ничек үлемгә бирешмәк кирәк?! Йөздән дә артык яшәгән әби-бабай белән сөйләш син, янә йөз ел яшәргә теләвен аңларсың. Яше йөздә булса да, күңеле белән унсигездә генә әле ул, шушындый көнне картаюын кем тойсын?!

Кайгы-хәсрәтләре барлар да башын түбән имәс бүген, үзе елар, үзе көләр, ничек тә көчлерәк булырга тырышыр. Иңнәренә төшкән таудай кайгысын күтәреп барса барыр, егылып каласы килмәс. Тал булып бөгелер, барыбер сынмас. Көне шундый бит, көне! Гашыйклар турында сөйләп тә торасы юк, алар ярсу, алар кайнар, алар шагыйрь бүген. Өлкәннәр эштә, балалар уенда арыганлык сизми бу көннәрдә. Һәркем үз иңендә канат тоя, шушы тойгы аны бик нык үзгәртә, ул тирә-ягын елмаеп күзәтә, үзен бик бәхетле саный. Шулай булмыйча, яз җитте бит, яңа яз тантана итә. Яз тәүдә тамчылар телендә эндәшә: «Яшьлек алып килдем, сөю, җыр алып килдем», — ди ул, кешеләргә шулай шатлык, наз өләшә. Агачтагы бөренең бөртеге саен бәхет ярала сыман. Бәхеттә һәркемнең үз өлеше бар. Яз юмарт, аның яме барыбыз өчен дә. Илдә иминлек булса, яз матурлыгын җуймас, ул безне шатландырыр, ул безне мәңге яшь итәр.

## *Умырзая*

Язның умырзаялары булмаса, белмим, ул бу кадәр булыр иде микән?! Юк, әлбәттә. Матурлык өстенә матурлык — беркөн умырзая үсеп чыккач яз тулы матурлык белән балкып китә. Чәчәкләрнең иң-иң гүзәледер умырзая. Шуңа да, ул калкып чыгу белән җырлый башлыйсың, җырлап туймыйсың.

*Бер чәчәк калкып чыга да*
*Сәламли язны.*
*Умырзая бу, ул үзе —*
*Ягымлы, назлы.*
*Сафлыгыннан бу чәчәкнең*
*Дөнья сафлана.*
*Аның гүзәллеген күреп*
*Күңел шатлана.*
*Тәүге чәчәк булган өчен*
*Назлы микәнни?!*
*Кояш аны нурларына*
*Төреп иркәли.*
*Күңел җырлый. Җырла, күңел,*
*Җырла син тагы.*
*Язны балкытып чәчәкнең*
*Елмайган чагы.*

Язгы моңнар күңелгә тулып таша. Дөнья зур, күк зәп-зәңгәр, чиксез матурлык, матурлык, матурлык. Кар сулары эчеп үсә умырзая, таҗларына кояш нуры кунып җемелди. Бу чак җилләр йомшак исә, алар умырзаяны иркәлиләр, назлыйлар. Бу чәчәкнең гүзәллеген мәңге сакларга ант итеп кояш көннән-көн кызулана, яктыра бара.

Язның кошлары гына түгел, чәчәкләре дә җырлый. Умырзаяның җырлаган җырлары — сафлык турында, җырларын тыңлаганым бар. «Отып алыгыз җырларымны, сафлыгымны күңелләрегезгә салып калдырасым килә», — ди умырзая. Умырзая сафлыгында биләүдә яткан сабый сафлыгы да, беренче хисләр, беренче мәхәббәт сафлыгы да, чын дуслык сафлыгы да бар. Аз гомерле умырзая, тик бу гомер — җырларда кабатлана торган гомер.

Өстәлемдә — ап-ак умырзаялар. Аларны миңа дустым китерде. Умырзаяларны сулы вазага утыртып:

— Кичерә күр мине, — диде дустым, — чәчәкләрне өздерәсең килми синең, өзмә, дип әллә ничә әйткәнең бар. Ләкин минем сиңа язгы чәчәкләр бүләк итәсем килде, син бит чәчәкләр яратасың.

— Рәхмәт, — дидем мин дустыма, — бүлмәмә яз яме китерүең өчен мең рәхмәт.

Өзелгән чәчәкләрне кызгандым. Моң тулы күңелемнең нечкә кыллары өзелеп төште. Бүлмәмдә чәчәкләр белән генә торып калгач, моңсу карашымны аларга төбәдем дә: «Дустыма рәнҗемәгез, миңа ачуланыгыз. Мин сезнең дөньяга елмаеп үсеп утырган җирегезгә бара алсам, сезгә сокланып карап тора алсам, ул сезне өзмәс иде. Мин гаепле, бер мин гаепле, минем өчен өзгән бит ул сезне, миңа карата киң күңелле булган дустымны кичерегез, умырзаялар», — дидем мин. Иртәгәсе көнгә сулып калачак чәчәкләрне кулларыма алдым. Әйе, сулып калачаклар, ләкин алар минем күңелем түрендә сулмыйча озак яшәячәкләр, дустымның күңел яктысына үрелеп үсәчәкләр.

## *Шатлык бәләкәй булмый*

Минем бүген бары тик шатлык турында гына уйлыйсым, шатлык турында гына сөйлисем килә. Уйлап карасаң, тормышта шатлык күбрәк кебек. Иксез-чиксез шатлыклары бар тормышның. Шатлыгы булмаса, бу кадәр үк матур булыр идемени?! Шатлык килсә, көче, дәрте таша кешенең, ул яшәрә, көлә, җырлый. Дөнья шундый яктыра, әйтерсең лә бер түгел, мең кояш берьюлы балкый. Шатлык — мең кояшлы бит ул. Шатлык сине аллы-гөлле нурларына төреп ала да, кочагында и тирбәтә, мәңге шулай булыр кебек.

Шатлык әллә ничә төрле. Беләсе иде, кайсы шатлык иң зур шатлык була микән? Күгендә сабан тургайлары сайрашкан, рәхәт итеп дулкыннарын йөрәккә китереп каккан, ипикәй исе килгән шаулы иген кырымы ул? Берәү, икәү өчен генә түгел, бөтен ил халкы өчен кадерле булган хәвеф-хәтәрсез, имин көннәрме? Бар көчеңне, гомереңне биргән гүзәл хезмәтең өчен иптәшләреңнән, туган илеңнән рәхмәт сүзен ишетүме? Әллә ул яңа гына дөньяга килгән баланың: «Рәхмәт, әнием, яшәү биргәнең өчен», — дигән кебек кычкырып елап җибәргән тәүге авазымы? Түтәл-түтәл гөлләр, яфрак-үләннәр кибеп хәлсезләнгәндә килеп яуган җылы яңгырмы ул? Өмет белән балкып, яңа көн тугач авыруның: «Яшим икән әле», — дип урыныннан күтәрелүеме? Әллә инде, ялгыз ананың ерактагы җаннарны өзгәләп сагындырган балакаеның: «Тиздән кайтып җитәрмен», — дип язган хатымы? Очрашу минутлары җитеп, күзләргә тулган яшьме ул иң зур шатлык? Йокысыз төннәрең, ямансу, борчулы көннәрең белән ялгызлыкта өшеп-

туңып яшәгәндә берәүнең килеп кулын сиңа сузуы микән? Әллә яраткан уенчыкларын калдырып, көлә-көлә ишектән килеп кергән әнисенә каршы йөгерүче бала күңеленә мөлдерәп тулган хисме ул шатлык? Кайда ул шатлык? Иске яралары һаман сызласа да, ел саен 9 нчы Май көнне, кошлар гына очкан, ак болытлар гына йөзгән тыныч, зәңгәр нурлар белән балкыган күккә карап елмайган, күкрәгенә рәхәт, иркен сулыш алган сугышчы йөрәгендәме? Ил каршында бурычын үтәп, исән-сау чыныккан ир булып кайтып килгән солдатның туган җире кырлары-киңлекләренә сагынып баккан күзләрендәме? Әллә инде зәңгәр кичләрнең берсендә икәү өчен генә сихри булган минутларда, ике йөрәкнең дә мәхәббәтнең бәхетле булырына ышанып тибүеме? Мәхәббәтнең шулай яшьлектәге кебек гомер буена пар булып, саф, кайнар булып калуындамы?

Һәркемгә үз шатлыгы килә. Килә генә күрсен, бүген дә килсен, иртәгә дә. Юк, бәләкәй шатлык булмыйдыр ул, шатлык һәрчак зур буладыр. Зур булмаса, аның елмайта алырлык көче булмас иде. Йөзләрне елмаю матурлый. Кеше матур булырга тиеш. Кеше шатланып яшәсен. Еласа да, шатлыктан еласын, җырласа да, шатлыктан җырласын.

## *Болын чәчәкләре*

Өстәлемдә — чәчәкләр. Яратам мин чәчәкләрне. Күрше кызы Гөлнара болыннан җыеп кайтты аларны. Үзем кушкан идем. Бүлмәмне ямьләп утырган чәчәкләрдән күзләремне алалмыйм, күңелдәге рәхәтлекнең чиге юк.

Чү! Йөрәгем чәнчеп куйды. Чәчәкләр күзләремә багып: «Яратмыйсың, яраткан булсаң, өздермәс идең., Кояш нурларында иркәләнеп, талгын җилдә тирбәлеп яшәр дә яшәр идек әле. Савыттагы су белән озак яшәве мөмкин түгел. Озакка түгел безнең матурлык, сулып калачакбыз, һәлак иттең син безне», — диләр кебек. Әйе, чәчәкләр хаклы. Белдем, сулып калачакларын белә торып өздердем. Язын шомырт, сирень чәчәкләренә куллар сузылганын күрсәм, ачуланмый калалмыйм. Үсентеләрне рәнҗетүчеләргә нәфрәтем туа. Өзелгән, инде матурлыгын җуя барган чәчәкләрне күрүгә күзләремә яшь тула, бәгырем телгәләнә. Җылы тынымны өреп җан биреп яшәтер идем үзләрен, үлгәннәрне терелтүе мөмкин генә түгел. Явызлык белән өздерүем түгел иде, кичерсеннәр мине чәчәкләр. Дусларым мине сәхрәгә алып чыгалар, миңа җәйнең бар ямен бүләк итәләр иде. Быел җәй яңгырлы булды. Табигать кочагында рәхәтләнә алмадым мин. Болын чәчәкләрен шулкадәр сагындым, кулларыма алып озак итеп, туйганчы карап торасым, нәфис таҗларына иреннәрем белән кагыласым килде. Яратам мин чәчәкләрне, яратам. Ах, нигә соң бу ярату җанны болай газаплы итә?!

## *Кочагыма нурлар җыям*

Июль кояшының кызу нурларыннан үлән көя. Гөлчәчәкләр, хәлсезләнеп, яшәү өметләрен өзгәннәр. Болыт сыман күтәрелгән юл тузаныннан агач яфраклары төсен җуйган. Су өсте кошкорт белән тулы. Оя-оя казлар, кая ул, басуга

таба борылып та карамыйлар, авызларын ачып сулый-сулый, су юлыннан йөгерәләр. Кошлар өнсез калган. Яңгыр кирәк, яңгыр кирәк җир өстенә, бар нәрсә яңгыр көтә. Без бәләкәй чакта, яңгырлар яумый торса, су буена барып чиләкләп су сибешә торган идек. Манма су булып кайтсак та әниләр бер сүз әйтми иде. «Яңгыр теләгез, су сибешеп уйнагыз», — дип үзләре куша иде. Безгә шул гына кирәк. «Яңгыркаем, яу-яу», — дип көйли-көйли, күрше балалары белән җыйнаулашып, кем нинди савыт әләктереп, су буена йөгерә идек.

Һич кенә дә онытылмый: беренчене бетергән генә җәй иде. Яңгыр яумый, су сибешәбез, Галиянең капкаларыннан күренүе булды — су белән коендырдык үзен, елап кереп китте. «Шаярып кына, яңгыр теләп кенә», — дип карасак та, Галиянең әнисе безне кычыткан тотып куды. Нәзиргә эләкте кычытканның иң усалы — өч көн өеннән чыкмады. Галиянең яңа күлмәген күрсәтеп мактанырга чыгып килүе булган икән. Без яңа күлмәкне су сибеп котлаганбыз — менә ни өчен елаган ул. Еларсың да шул, хәзерге кебек магазиннарда тегелгән матур-матур күлмәкләр юк иде ул елларда. Елына бер күлмәк кул белән тегеп кидерә иде әнкәләребез.

Су сибешкәннән соң чынлап та яңгыр яуганын беләм. «Теләкләребез кабул булды», — дип шатланышып, пычрак чәчрәтеп йөгерешә идек. Олылар шатлана: «Җир бигрәк көйгән иде, Аллаһы тәгаләнең рәхмәте киң, бирде бит яңгыркайны», — диләр. «Көйгән» сүзе безне бераз аптырата. «Утта берәр нәрсә көйсә, исе чыга бит, җирнең дә исе чыга микәнни?» — дип уйлый идек. Безгә ул чакта серле булып тоелган

күп нәрсәләр инде сер түгел. Чынлап та, җир көя бит: озак яңгыр яумаганлыктан бар үсемлек көя, тагын 2 — 3 көн яумаса, җирдә чәчкә-үләннәрнең бер бөртеге дә калмас кебек, кояш кызулыгыннан җиргә ут кабар төсле. Әле дә шулай. Бала-чагалар да су сибешми ичмаса, су йөзә белгәннәре көне буе судан чыкмый, белмәгәннәре йөри шунда әрле-бирле. Әниләре дә әйтми икән, заманы башка шул, заманы башка, теләп кенә яңгыр яудырып булмаганын барыбыз да аңлыйбыз, ә яңгыр кирәк.

Чү! Зәңгәр киңлектә бөдрә болытлар күренә түгелме? Әйе, болытлар, яңгыр болытлары, көньякны иңләп болыт агыла. Кара каргалар үзләре болыт кебек булып, «кар да кар» килеп, баш очында әйләнә. Җил чыга, күкне болыт катламы каплап ала. Көн караңгылана. Җил көчәя бара, тузан өермәсе күтәрелә. Тәрәзәләр ябыла, кипкән керләр җыеп алына, аркандагы бозау ышык урынга ябып куела, көртләгән тавык чебешләрен канат астына җыя. Бар да ашыга, бар да кабалана. Дөньяны ут алыр төсле, яшен камчысы күкне яра, җир тетрәтеп күк күкри. Җилнең көче имәннәрне егар төсле. Яңгыр килә, менә-менә коеп ява башлар. Яңгырның беренче тамчылары җиргә төшеп борчак булып тәгәри. Тамчылар, тагын тамчылар. Яңгыр чиләкләп коя. Яфрак-үләннәргә беренче тамчылар төшү белән, аларда өмет кабына, «Яшибез икән», — дип шатланыша алар, яфрак-кулларын чәбәкәйлиләр. Яңгырның һәр тамчысы үсемлекләрнең хәлсез сабагына дәва шул. Яңгыр ява, бу мәлдә күңелнең шатлык хисләреннән тулган чагы. Һәр үлән, һәр яфрак, һәр чәчәк һәм киң кырларда тирбәлгән игеннәрне күз алдыма китереп куа-

нам: аларга яңгырда рәхәт бит, көтеп алган шатлык бит бу. Яңгыр ява, матурлык исән кала, менә шулчакта инде матурлыкның мәңгелек икәненә ышанасың. Үсемлекләр өчен генә түгел яңгырның шифасы, кеше җаны өчен дә шифа бит ул. Яңгырдан соң дөнья тагы да зураеп, матурланып китә. Кешенең ничек яшисе килмәсен бу дөньяда, бер бөртек үләннең дә үләсе килми бит. Яңгыр тамчылары аңа көч бирә, ул яши, көлә-көлә кояш нурларына үрелә. Шуны күреп, кеше бар дөньясын оныта. Әрнүләр басылгандай була, авыр газапларыңнан арынасың кебек. Азга гына булса да үзеңне дөньяда әнә шул яшел үлән итеп тоясың. Яңгыр бераздан туктап кала, җил дә тынган. Шундый тыныч, шундый рәхәт. Салават күпере нурларыннан күк йөзе балкып китә. Сихри тынлыкны бозып, тәрәзә башыннан күгәрчен очып төшә, башка кошлар телгә килә. Бакча гөлләрендә күктәге җиде төснең нуры уйный. Яңгыр бар дөньяны яшәрткән, сафландырган. Кояшның алтын нурлары сибелүгә «без дә без» килеп бал кортлары очыша башлый. Алар чәчкәдән-чәчкәгә кунып бал җыярга керешәләр. Күрше балалары урамга йөгерешеп чыгалар. Гөрләвекләр буйлап алар да йөгерәләр, алар шатланалар, алар да безнең кебек үк икән. Балачак эзләремә баса-баса минем дә йөгерәсем килә, тик йөгермим, йөгереп кенә барып җитеп булмый ул елларга, ерак калган ул еллар. Үсәргә ашыктык бит, тизрәк үсәсебез килеп яңгырларда чыландык. «Чәчәкләрне яңгыр үстерә, безне дә үстерсен», — ди идек. Үсеп җиткәч балачак сагындырасын кем белсен ул чакта.

Авыл капкасыннан чыгып, басу юлыннан барам. Яңгыр явып үткәннән соң иген кырында

Һава сулавы күкрәккә мең дәва икән. Әйтерсең лә салават күпереннән барам, җирдә үскән чәчәкләрне түгел, кочагыма күктән нурлар җыям.

## *Тамырдашлар*

Гөлләрем җәй буе чәчәк атты. Өй эчен генә балкытып калмагандыр алар, урамнан үтеп китүчеләрне дә шатландыра алганнардыр. Күзләрнең матурлыкны күреп кенә калуы да җанны чиксез рәхәтлек белән тутыра бит. Җилсез көннәрдә тәрәзәләр ачык торды. Күрсеннәр, гөлләремә соклансыннар, дидем. «Соклансыннар» имеш, күзләре тимәде микән? Гөлләрем боеккан. Югыйсә, тамырлары да дымлы туфракта, эссе дә, суык та тими үзләренә. Ни булган гөлләргә, ни сәбәптән бөгелгәннәр? Чәчәкләренең керфекләре йомылган, көнгә карыйсылары килми аларның. Яшелләре белән бермә-бер сары көйгән яфраклар. Юк, юк, күз тимәгән гөлләргә. Алар тышта сентябрь икәнен белгәннәр. Әйе, белгәннәр, тәрәзәдән күреп белгәннәр. Көннән-көн усаллаша барып искән җилләрнең урам буйлап яфраклар куып йөргәнен күргәннәрдер. Матурлыкларын мәңгелеккә җуеп, салкын яңгыр астында калтырана-калтырана бакча гөлләре сула. Күк йөзен каплаган болытлар арасыннан әллә нигә бер кояш карап куя. Чәчәкләрне терелтер көч юк аның нурларында. Соңгы сулышларынача өметләре сүнмәсен дип кенә сүрән нурлары белән гөл-чәчәкләргә үрелә сыман кояш. Тәрәзә төбендә үссә ни?! Җаннары бер үк төсле ич гөлләрнең. Бакчадамы, сахрадамы, савыттамы, бер үк һава сулап, бер үк яктылыкка

үрелеп үскәннәр, яшәгәннәр. Кешеләр сыман гөлләр дә, кешеләр җаны бар икән гөлләрдә дә. Бар бит кешеләрнең шундыйлары, кеше кайгысын үз кайгысыдай авыр кичерә, кеше газабын йөрәгендә йөртә, кеше күңелендәге яралардан гомер буе сызланып яши. Кешеләр сыман дип ничек әйтмисең гөлләрне, әнә бит, тамырдашларның бүгенге коточкыч авыр хәлләрен күреп, ничек боекканнар.



## *Күз яшьләрең — көмеш тамчы*

Янам-көям дигән сүзләреңне уфтану белән әйтмә син. Янмау-көймәү мөмкин түгел — сөясең! Сөйгәннәр янмый, кем янсын?! Сөю ялкыныннан яралган, синең йөрәк тоташ ялкында. Синең йөрәк кайнар, синең йөрәк җырлы. Син сөймәсәң, сөю мәңгелек була алмас иде. Мәңгелек сөю белән шундый матур, зур, чиксез бу дөнья. Синең сөю язлар алып килә, синең матурлыгың язларда кабатлана. Әйе, синең матурлыгың! Синең сөюең сафлыгы яз яктысы булып бар дөньяга тарала, назлы җилләр булып исә. Язларда — синең хисләрең җылысы, кайнарлыгы. Кар-бозларны эретеп, көчле ташкыннар ясаучы — ул синең хисләр! Синең көлү тавышың кошларны дәшеп ала, бөреләрне уята. Чишмәләр чылтыравында синең тавыш. Күз яшьләрең көмеш тамчы булып тама, ләйсән булып сибелә. Хыялларың

төнге күкнең зәңгәр йолдызлары булып кабына, кояш булып балкый. Түгәрәк ай — синең сагынуларың, йокысыз төннәрең ул. Син табигать гүзәллегеннән яралгансың. Синдә таллар нечкәлеге, таулар горурлыгы, таңнар алсулыгы. Күктә нур син, җирдә гөл син, кыз бала!

Җилләргә дә җиңелгәнең, давылларны да җиңгәнең бар синең, и кыз бала! Кылларның иңиң нечкәсе — синең күңелдә, яраның иң әрнегәне — синең йөрәктә, кыз бала. Кайгыларың җир-күкләрне тетрәтә. Шатлыкларың гөлләр керфегенә чык булып куна. Синең рәнҗү яшен сугу белән бер, синең елмаю иң олы бәхет! Син бәхетле булырга һәм бәхетле итәргә тугансың. Синең җаның — изге җан, анда бар да матур, бар да саф, бар да бәхет өчен. Кардай ап-ак туй күлмәге киясең бар әле синең, ап-ак биләүдәге нәниеңне күкрәгеңә кысып-кысып сөясең бар. Син әле яңа гына ачылган гөл чәчәге кебек, кояшка, бары тик кояшка карыйсың. Сине салкын җил-яңгырлардан мәхәббәтең саклый. Сөя беләсең син, кыз бала, син бер генә төрле сөясең, янып сөясең.

Яз килә — бу синең янып сөюең, гөл үсә — бу синең янып сөюең, җыр туа — бу синең янып сөюең, кыз бала!

## *Мин елак түгел*

Кызларны «елак» диләр. Бар, елак түгелләре дә бар кызларның. Тик алар да өч кабат елыйлар, барыбер елыйлар.

Кыз елый. Балачагы белән саубуллашып, гомеренең иң гүзәл, иң көчле, иң кайнар, иң чая

чагы — яшьлек белән очрашкан мәлендә, гаҗәеп шыйк булгач елый ул. Беренче хисләре шулай йомшарта аның күңелен.

Тулган ай шаһит: иреннәрен кызның егет үпкән. Менә ни өчен елый икән кыз, бу аның икенче елавы. Ни өчен? Кыз үзе дә белми.

Өченче кабат елый кыз: сөйгәне аны түгел, башканы сөя икән бит. Кыз беренче мәхәббәте белән хушлаша. Күңел бүлмәләрен моң-сагыш белән тутырып, йөрәккә әрнеп торган яралар салып калдыра да, китә мәхәббәт. Кыз аңа күзләре талганчы карап кала. Керфегендәге яшьләрне җилләр киптерә, тик керфекләр кабат чылана. Үксеп-үксеп кыз елаган чакта, чык тамчыларын күз яшьләре итеп гөлләр елый; сайравыннан туктап калып, сандугач елый; төнге күктә калтыранып йолдызлар елый кебек. Мин елак түгел, тик еладым — өч кабат еладым.

## *Яратканга күрә*

— Нигә яратам дип әйттең?

Йөрәк бу көтелмәгән сораудан сискәнеп китте, ләкин курыкмады, ул җавап бирергә ашыкты:

— Яратканга күрә, — диде. Күкрәк сөяген ватып чыгардай булып типте, ташып торган саф сөю хисләре белән туп-тулы иде йөрәк. Сорау йөрәккә тирән яра салды. Яра вакыт үткәнен дә көтмәде, шунда ук сызлый башлады. Йөрәктә яралар юк түгел иде, тик болай ук әрнеп сызлаганы юк иде әле. Йөрәк бирешергә теләмәде. «Бирешмәскә, бирешмәскә», — дип типте дә типте ул. Учка сыеп бетәр йөрәк шушы минутта

дөньяга чак-чак сыйды, аңардан да зур, аңардан да көчле берни дә юк иде кебек. Яратуы белән көчле иде ул.

Сорау җавaптан канәгать түгел иде күрәсең:

— Нигә яратам дип әйттең? — ул янә кабатланды. Нинди җавап көтте микән? Йөрәк башка төрле җавап бирә белмәде:

— Яратканга күрә, — диде ул бу юлы да. Бер генә төрле иде аның җавабы, башканы белми иде ул, ярата гына белә иде.

Бу ни хәл: йөрәк кечерәеп, суырылып калды. Сорау рәнҗеттеме аны? Сорау гына түгел иде шул бу, йөрәккә атылган ук иде. Гаепләнене җәзалар алдыннан соңгы сүзен көткән минутлар кебек бу минутлар, таштай каты бәгырьлелек бар иде сорауда. «Мин яратырга тиеш түгелмени? Яраткач, әйтергә дә хаклымындыр?!» Йөрәк шулай уйлады хәлсезләнеп. Яратам, дип кабат әйтмәс булды. Үзе бер генә булса да, газаплары мең иде аның. Ни гаебе бар? Йөрәк нигә җәза алды? Яратангамы? Әйе, ярaтканга, ярата белгәнгә. Менә-менә өзелеп төшәр дә, кабат беркайчан да типмәс кебек ул. Өзелүдән ниндидер көч саклап тора аны. Шушы минутка кадәр тормышны гөрләтеп тә, балкытып та торган мәхәббәтнең әлегә сүнеп-сүрелеп бетмәгән ялкыннары көчедер. Йөрәк телгәләнеп бетәр иде, «Юк, — диделәр язгы бөреләр, — сиңа болай килешми. Син зур булырга, ялкынлы булырга тиеш. Май кояшы нурларына күзләребезне чагылдыра-чагылдыра без ничек ачылсак, син дә сөеклең каршында ояла-ояла булса да ачыл. Яратам, дип әйт. Тик, кара аны, чын ярату булса гына!» Әйе, бөреләр хаклы иде. Менә бит, ничек акыллы итеп әйттеләр. Йөрәк яратыр өчен лә ул. Яратырга кирәк

булмаса, йөрәкнең дә кирәге булмас иде кебек. Дөньяда ярату булмаса, язлар килер идемени? Сандугачлар сайрар идеме? Чишмәләр чылтырап җырлар идеме дә, чәчәкләреннән үбә-үбә гөлләрне талгын тибрәтеп җилләр исәр идеме? Шушы матурлыкны күреп шатланыр өчен кеше туа. Ярату булмаса, туар идемени? Ярату булган өчен, яратыр өчен туа ул.

Җил исте, сандугач сайрады, чишмә чылтырады. Йөрәк авыруыннан терелде, элеккечә ташып сөйде, элеккечә: «Яратам!» — дип пышылдады. «Сүнәм-сүнәм» дип торган яшәү ялкыннары балкып китте, дөнья тагын үз матурлыклары белән тулыланды. Тик йөрәктәге яра, сорау салып калдырган яра урыны әледән-әле чәнчеп-чәнчеп куйды, үзенең барлыгын сиздереп торды. Тәндә төзәлә, йөрәктә төзәлми икән яра. Йөрәккә кагылырга ни хакы бар иде бу сорауның?

## *Туй күлмәге*

Туй күлмәге, күзләр күреп туймаслык матурлыгың бар синең. Чәчәкле гөлләрнең, сандугачлы тирәкләрнең, кояшлы күк йөзенең матурлыгы синдә. Сине яшьлекнең бөтен асыл бизәкләреннән тукылган ефәктән теккәннәр шул. Кыз бала мәхәббәтенең сафлыгы, хыяллар аклыгы бар синдә, туй күлмәге! Кыз баланың хыяллары бигрәк якты була шул. Гомере буе сөеп-сөелеп яшисе килә аның. Тормышның әллә нинди көчле җил-давыллары да сүндерә алмас кебек аларның сөю ялкынын. Сөйгән яры аны коточкыч хәлләрдән саклап кала алыр кебек. Упкыннар йотмас кебек аларның мәхәббәтен. Еласалар да, шат-

лыктан гына еларлар, гомер буена шулай булыр кебек. Менә шушы уй-хыяллар кебек ап-ак син, туй күлмәге! Энә күзе кадәр генә тап төшсә дә, матурлыгыңны, аклыгыңны җуярсың кебек. Кыз бала күңелен рәнҗетер өчен бәләкәй генә сәбәп тә җитә бит. Ак хыяллары тормышка ашсын берүк, ап-ак бул, кер кунмасын сиңа, туй күлмәге. Туй күлмәге кигән кыз баланың үтәр юлы да ак булсын. Килен булып төшкәндә ул күлмәге аклыгын йөз яктысы, күңел яктысы итеп алсын.

Ак кына түгел син, бәхет төсе синдә, туй күлмәге! Яшь гаиләгә бәхетле тормыш теләп теккәннәр сине.

Туй күлмәге, син кызларның төшләренә керәсең. Уяна да ул, йә хыял күлендә аккош булып йөзә, йә хыял күгендә ак күгәрчен булып канат җилпеп әйләнеп-әйләнеп оча. Сөйгән ярын җуйган кыз күңелендә дә якты өмет булып яшисең син, ак күлмәк. Алданган кыз җанында син әрнеп торган яра булып, үкенечле хата булып яшисең. Ул туй күлмәге кисә дә, йөрәк әрнүләреннән котыла алмаячак. Сафлык кына шулай ак күлмәккә әверелеп, бәхетле көннәргә илтә бит. Таплы булма, туй күлмәге!

## *Көтәм*

Менә таң да сызылды, яңа көн туып килә. Мин янә көтә башладым. Һәркөнне шулай, көн башлану белән көтә башлыйм, көн буе көтәм. Минем көткәнем кайчан һәмниләр булып килер икән? Көткәнемнең нәрсә икәнен белмим: гомер буе көтсәм дә, белмәмдер, мөгаен. Көтә-көтә арыган чакларым бар, тик көтүдән туктап ка-

лалмыйм. Көтүдән туктасам, йөрәгем тибүдән туктар бит, яши алмам мин көтмичә. Көтү һәм өмет белән яшәүнең кадере арта сыман. Көткәннәрем алдыма килмичә, мин бу дөньядан китәргә тиеш түгелмен. Менә шул көтү белән, киләчәгемә омтылып, канатланып, янып яшимдер. Көткәнем якты көнем булып килерме, баш очыма җылы кояш булып күтәрелерме? Күңелемнең аяз күкләрендә ап-ак каурый болыт булып йөзәр, әллә кара болыт булып, кояшымны каплап алырмы? Җылы яңгыр тамчылары булып, шатландырып явып үтәрме, әллә салкын боз булып җанымны туңдырырмы? Нәрсә көтәм мин? Назлы, ягымлы җилнеме, күңелемнең сандугачлы бөдрә тирәккәен төбе-тамыры белән куптарып ташлар давылнымы? Таудай авырлыклар салырмы миңа көткәнем, әллә таудай шатлыкларым булып, мине күкләргә күтәрерме? Мине бәхет кочагында елатырмы, әллә кайгыларга төшеп үксерменме?

Кайчан киләсең, көткәнем?

Тиздән килеп житәрсеңме, тагын әллә язлар, җәйләр, көзләр, кышлар үтәрме? Янә шулкадәр көтәргә минем сабырлыгым җитәрме? Ниләр булачагын белми көтүе җанга мең газап бит. Моңсагышларыма әйләнерсеңме, тормышымда нурлар булып балкырсыңмы, көткәнем? Мин көтәм, сине көтәм, төшләремә кереп сагындырган кадерле кешем! Сине көтәм, бары сине генә, утларга, суларга салган кешем. Өмет утларым сүнә торган түгел, мин шул яктыда яшим, яшәячәкмен. Син килерсең, ниләр булып килерсең икән?

## *Ярата белгән кеше*

Син белдең бит, белдең аның кайгылы ут эчләрендә торып калганын. Коткарырга иде — утка якын бармадың, колачларың җәеп ярдәмгә ташланмадың. Яннарына тәүге тапкыр килүеңдә: «Утларда бергә янарбыз», — дип син әйткән идең лә. Йөрәгеңдә ут-ялкын булса, син читтә калалмас идең, янып көлләргә калудан курыкмас идең. Мәхәббәт ул ут-ялкыннардан яралган сихри, изге көч. «Яратам!» — дия идең бит, ялкынсыз йөрәктә ярату булмый лабаса?! Яна белмичә: «Янам-яратам!» — дип пышылдауларың гафу итмәслек ялганмы? Җаныңда жылың булмагач, нигә аны кочагыңа ала идең, ут кебек иреннәренә нигә үрелә идең?

Син аның давыллар кочагында бәргәләнүен күрдең, аның янына, давыллар кочагына ташланыр көч тапмадың син үзеңдә. «Җил-яңгырлар тидермәм!» — дигән сүзләреңне оныттың. Син барыннан да көчлерәк булырга, авырлыкларны, юлларыңда очраган киртәләрне ватып-җимереп, җиңүче булып калырга тиеш идең. Көчле булсаң, давылларга каршы күкрәк киереп барыр идең дә, авыр газапларга дучар булган кешеңне тормышның рәхәт бишегенә салыр идең, әрнегән яраларына дәва булыр идең. Юк, сызланып елаганын күрмәс идең, ул шатланып көләр иде, аның шатлыгы, аның көлүе язларны иртәрәк китерер иде. Язлар яктырак, җылырак, назлырак булыр иде. Аның күңел канатларын давыл каерды, каерылган канатыннан канлы каурый алды да ул, сиңа бер генә сүз язды: «Кил!» Килмәдең! Сине дәшүе көчсезлеге дә, горурлыгын җуюы да түгел, бу аның яратуы, бу аның мең

газапларга түзеп сине яратуы, сине сагынуы, сине көтүе! Ялкыннарда көя, салкыннарда туңа, давылларда чыныга ул ярата белгән кеше! Ул — ярата!

## *Айлы-Кояшлы дөньям*

Умырзаялы язларымнан мәхрүм итмә мине. Кояшым чыксын, кояшка үрелеп яшел үлән үссен, бөреләр ачылсын, сандугачлар килеп куаклыкта оя корсын. Җәйләремнән аерма мине. Җәй — минем хәтеремнән мәңге җуелмас гүзәл сурәт ул. Яуган җылы яңгырлар, күкрәүләр-яшеннәр, нур балкытып калыккан салават күпере — болар бар да шифа булып, җанда яши. Талгын искән җил дә, зәп-зәңгәр күктә йөзгән ак болыт та, болында тибрәлгән чәчәк тә, игеннәр шаулаган киң кырлар күгендә сайраган тургай да, атлар кешнәве дә, чалгы тавышы да җәйнеке, бары тик җәйнеке генә.

Су буенда казлар каңгылдаша, бу инде көзге моң. Сагышлы да, моңсу да, шул ук вакыт матур да булып ишетелгән тавышлар көзләрдә күбрәк була. Басудан килгән хезмәт шавы гына да ни тора?! Һәр аваз җыр булып яңгырый. Көз буяуларга бай. Яратам көз буяуларын, көз бизәкләрен! Моңланып таллар бөгелгән, яфракчуклары суга тигән. Бөдрә тал белән аккан су арасында ниләр генә булмас соң, пышылдашып серләшәләр шикелле. Күңел сагышы суга түгелгән диярсең, су өстендә сары яфраклар йөзә. Су белән ага яфраклар, күңел бушанып калыр төсле, юк, бу шулай тоела гына, сулардан тирән уйларың белән сары бураннарда адашып кала-

сың. Юл тапмаслык адашу түгел бу, кошлар китәр чак җитә бит, шуңа күңел кыллары өзгәләнә. Кешеләр кебек үк, киткән кошларның да барысы да кире кайталмыйдыр.

Көзге җилләр зәһәр иссә дә, өмет ялкыннарына кагылмый ул. Түтәлдә гөлләр сулса да, күңел чәчәкләре тере кала.

Күңел аклыгына тап төшмәсен, кер кунмасын өчен кышлар да кирәк. Илләргә тынычлык, тормышка иминлек теләүче ап-ак күгәрчен кебек ак бит ул кышкы көннәр.

Кояшлы-Айлы дөньям икән лә, син, Кояшым булып җылытасың, тулган Ай булып юлларыма якты сибәсең. Йолдызлар булып мөлдерәп караган күзләрең яшәү көчемне арттыра. Син — матур хыялларымның тормышка ашачагына ышандырып, бормалы, сикәлтәле, таулы юллардан киләчәгемә әйдәп торучы, каршыма йә назлы җилле җәй, йә давыллы кыш, сагышлы көз булып килүче чынбарлыгым икән. Син мине шуларның берсеннән генә дә мәхрүм итмә.

## *Мәңгелек буласым килә*

Син йолдызларга карарга яратасың. Зәңгәр төннәрең күгендә бер йолдыз булып кабыныр идем. Синең күзләреңә иң якты йолдыз булып күренер идем, күңелеңә иң якыны булыр идем. Йолдызлар атылганын күреп, борчылып: «Йолдызым, читкә атылма берүк, югалтасым килми сине», — дип типкән йөрәк тавышыңны ишетеп торыр идем мин.

Син чәчәкләр яратасың. Иң яраткан чәчкәң булып үсәр идем. Ничек тә вакыт табып, чәчәкле

тугайга мине күреп шатланыр өчен ашкынып килер идең. Көчле җилләр искәндә дә, бозлы яңгырлар яуганда да янымда булыр идең, мине бәла-казалардан саклар идең. Кояшлы гына итәр идең син минем көннәремне. Минем тирәдә очып уйнаган күбәләкләрдән әй көнләшер идең!

Күкрәп яуган яңгырларны яратасың. Син көткәндә генә явар идем мин. Ышык эзләмәс идең син, рәхәтләнеп чыланыр идең, күңел гөлләрең терелер иде. Көчле күкрәүләремә кушылып кычкырып көләр идең. Шулвакыт мин салават күпере булып калкыр идем дә, сине аллыгөлле нурларыма төреп алыр идем.

Син бервакыт күл буенда ап-ак каурый табып алып: «Әллә аккошныкымы?» — дип, шул каурыйны кулларыңда уйнаткан идең. Саф күңелең күлендә аккош булып йөзәр идем. Җылы яклар эзләп китмәс идем мин, көзләрең суык, кышларың буранлы булса да, синдә калыр идем. Күңел күлеңне туңудан йөрәк җылым саклый алыр иде. Көтмәгәндә явыз күңелләләр якынлашса, син бердәнбер аккошыңны ефәк камышлар арасына яшереп саклар идең.

Гомернең шау чәчәкле язгы мәле. Сандугачсыз яз — яз булмыйдыр ул, сандугачың булып килер идем, бер генә көнгә дә соңламас идем. Тал-тирәкләрне тибрәтеп сайрар да сайрар идем. Иртәләрең дә, кичләрең дә сандугачлы булыр иде. Гомер языңны мәңгелек яз итәр идем, син дөньяда көзләр барын белмәс тә идең.

Юк, сандугач та, аккош та буласым килми, аларның гомере кыска. Синең тормышыңны җимереп, ялгызыңны калдырасым килми. Күк йөзен дә болыт каплый, йолдызлар күренмәс була. Чәчәкләр гомерен саклап калу мөмкин

түгел, беренче кыраулардан ук алар дөнья белән бәхилләшә. Кояш та көн буе күктә йөзә дә, төнен югала. Битләреңнән сөеп искән йомшак җилләр дә буласым килми: җилләр бервакыт тынып кала. Син утсыз да, сусыз да яши алмыйсың, тик минем ут та, су да буласым килми, ут — сүнә, су — кибә.

Минем мәңгелек буласым килә бит. Матурлыгына да, чиксезлегенә дә бу дөньяда тиңе булмаган хыял, синең хыялың буласым килә. Хыял — мәңгелек, хыялга җил дә, яңгыр да тими. Хыялның сагышлы күзләре дә, суык кышлары да юк. Хыялның төне юк, аның үз кояшы, үз йолдызлары бар. Хыялың булсам, уйларың да, юлларың да һәрчак якты булыр иде. Кешене хыялыннан беркем дә, бернинди көч тә аера алмый, без мәңге бергә булыр идек. Кеше — мәңгелек түгел, аның хыялы — мәңгелек. Матур хыялы бар кеше матур эшләр эшли, тормышка ямь өсти, ул ялгыз да булмый. Хыялың буласым килә, бу дөньяга синнән, миннән бер матурлык калсын иде.

## *Зәңгәрлек*

Урам як бакча эчендә, чия куаклары арасына, баскычка менеп баскан ул. Кул хәрәкәтләре шундый җитез — кыз тәрәзә буйый. Буялган тәрәзәләр көлеп тора, әйтерсең лә үсмер кызның чибәр йөзендәге елмаюы тәрәзәләргә буяу булып ягыла. Пешә генә башлаган чияне хәтерләтеп, яшел яфраклар арасыннан кызның ал күлмәге күренә. Үтеп китүчеләр кызны искә-саңга алмыйлар бугай, сыный карамасаң, анда кемдер

бар шикелле дә түгел. Ә ул күрде. Бер йомышсыз шушы урамнан бүген өченчеме, дүртенчеме үтүе егетнең. Беренче үтеп баруында ук күрде ул аны. Кыз эш белән мавыккан иде, борылып карамады. Аннары, һәр үткән-барганга борылып карый башласаң, эш барамы? Әйдә, үтә бирсеннәр. Тәрәзәләре балкып торган йорт яныннан тагын үтеп бара егет — күзләре тәрәзәләрдә, күңеле кызда аның. Чия куаклары артында яшеренгән шушы кызда. Бүген генә түгел, күптән, былтыргы яздан башлап яши бу кыз егет күңелендә. Тик үзе генә белми. Әллә белергә генә теләмиме? Егетнең әлегә кыеп бер сүз дә әйтәлгәне юк шул, каян белсен кыз. Кызны күрү белән телсез кала бит. Югыйсә бер мәктәптә укып, бер сыйныфта унынчыны бетерделәр быел. Җәй үтүгә кем кая китеп барачак, шулай ук каламыни, әйтелмичә каламыни егетнең йөрәк сүзе? Хисләре язгы ташкыннардай ярсыр-ярсыр да тынармы? Юк, ул хисләр тынар өчен түгел, тулып ташар өчен ярсыйлар. Беренче татлы хисләр, яшьлек хисләре. Кызга дәшергә уйлап: «Матурлыйсыңмы?» — диясе килгән иде, тыелып калды, матурлаганын күреп торам бит, нигә шундый сорау бирергә дип уйлады ул. Кыз күреп калса — баскан да каткан, егеткә уңайсыз булып китте. Ни дип булса да эндәшергә кирәк, болай ярамый бит инде. Шулчак кыз да борылып карады, егетне күрде. «Зинфирә, шундый матур буяуны каян таптың, күзләрең зәңгәрен куштың мәллә бу буяуга?» — диясе килде егетнең. Юк, әйтәлмәде. Зинфирәнең күзләре дә, тәрәзәләр дә, күк йөзе дә зәп-зәңгәр иде. Бөтен дөнья зәп-зәңгәр булып күренде Фәнискә. «Зәңгәр, зәңгәр», — дип пышылдады аның иреннәре. Шушы

зәңгәрлектән башы әйләнде аның. Китте, бер генә сүз дә әйтәлмәде ул тагын. Әй, җебек егет, дип тәрәзәләр көлеп калды кебек.

Көлделәрме? Юк, көлмәделәр. Нишләп җебек булсын ул? Сыный бирсен әле егет үзен, йөрәге газаплар кичерсен. Әйтер ул, әйтер бер зәңгәр кичтә: «Яратам», — дияр Зинфирәгә. Бәлки әле, кыз да: «Мин дә», — дияр. Әйе, шулай дияр.

## *Җырлы кичләр*

Кич җиттеме, Дамир кулына баянын ала. Бүген дә урамга чыгып утырды да әнисе яратып җырлаган «Сарман»ны уйната башлады. Элекке көйләрне дә, хәзергеләрен дә бер ишетү белән отып алып, матур итеп уйната ул, әтисе кебек оста.

Дамир алты гына яшьтә иде. «Һөнәрең булсын, улым, бармакларыңда хәрәкәт бар, тавышың да бар кебек, тыпыр-тыпыр биеп тә китәсең, тот баянымны, өйрәнсәң, өр-яңасын алырбыз!» — диде аңа әтисе. Дамирның бармаклары яңа баян басмакларында бии, ул җырлата да, биетә дә, елата да хәтта. Дамир Уфада укый, каникул вакытларында гына авылда була ул. Кайтканына ай тулып узды, яшьтәшләре килде, егетләр дә, кызлар да. Үзләре белән кичке клубка әйдәп карадылар, бертапкыр да чыкмады егет. Егетләрнең эчүләре, аны эчәргә өндәүләре ошамый аңа. Кышкы каникулда күршесе Илшат әйдәләгәч чыккан иде ул, эчкән егетләргә тап булдылар. «Рәтләре» дә бар икән, «Очрашу хөрмәтенә бергәләп эчәбез инде!» — диде берсе.

Дамир кире каккач: «Ни рәхәте бар дөньяның, эчеп тә күңел күтәрмәгәч!» — димәсенме икенчесе. «Мин аек акыл белән яшәргә телим!» — дип кычкырып әйтмәде Дамир, бик авыр булса да, сиздермәде. Шуннан соң чыгасы да килми, юк, кимсенеп түгел, шул күзле сукырлар белән аралашасы килми.

Дамир кайткач баяны белән башта гел үзләренең җиләк-җимеш бакчаларында, гөлләр-чәчәкләр арасында утырды. Күрше кызы Ләйсән аңа: «Дамир, син урамга чык, анда сине күрше апалар, әбиләр көтә, биетеп, җырлатып та ал үзләрен!» — димәсә, егет һаман чыгарга уйламас та иде. «Мин монда сандугачларны җырлатам бит, Ләйсән, ташлап чыксам, дусларымны үпкәләтмәмме соң?» — дигән булды ул, үзе Ләйсән белән бергә урамга чыкты. Бүгенге кебек җиләс, җылы кич иде анда да. Бакчадагы яшел куакта сайрашкан сандугачлар Дамирга ияреп урамга чыктылар кебек, тавышлары якын гына ишетелә. Кичләрне көтеп ала Ләйсән, бүген дә, әнә каен артына качып баян моңнарын тыңлый, күзләре Дамирда. Егет кызны күрми, башын берьякка кырын салган да, уйнавын белә. Кабарып маңгаена төшкән коңгырт чәчләре белән кичке талгын җил уйный. Дамир бик сөйкемле, матур егет, буйчан, какча гәүдәсенә озын җиңле зәңгәр күлмәге шундый килешә. Дамирга карагач, кояшлы күк йөзенә баккандай буласың. Бөдрә каен артында күпме качып торып була соң, кыз егет янына килде дә колагына нидер әйтте. Алар тар тыкрык буйлап елга буена төшеп киттеләр. Беренче тапкыр гына төшүләре түгел, бала чакта уйнап йөргәндә дә шушы Бүә буена киләләр иде.

Бала-чагалар су коенып шушында үсә инде, Дамир да күп тапкырлар су коенды.

Бүә буе талларында әллә яфрак саен сандугач, Ләйсән белән Дамир беравык тын калып былбылларны тыңладылар. Егет бер кыяк үлән өзеп алды да шуны бармакларына уратып уйный, Ләйсән Дамирга караган да тирән уйларга чумган. Дамир күрми, ул Ләйсәннең дулкынланып иңнәренә таралып төшкән җитендәй чәчләрен дә, талдай нечкә билләрен дә, якты карашлы күзләрен дә күрми. Кызның тавышын ишетә егет һәм аның саф күңелле икәнен белә. Тумыштан күрми Дамир, дөньяга кеше булып туган, ә дөнья яктысын күрүдән мәхрүм. Уфада махсус мәктәптә укыды, инде баянчылар курсында белем ала. Ләйсән фельдшер булачак. «Әй, шул сукыр күршең булмады инде, ул дип клубка чыкмый ятасың!» — дип әйтте аңа кичә ахирәте булып йөргән Айгөл. Шулай диде дә Ләйсән яныннан кызу-кызу атлап китеп барды. Ләйсәнгә күзе төшеп йөргән Айратның да шундый әшәке сүзләр әйткәне бар. Алай гынамы: «Бәхетле булырсың, әнә шул сукырны ярат инде, мине яратмагач!» — диде. «Сез ул әнә сукырлар, Дамирны сукыр дип әйтергә ничек телегез бара? Сез аның белән сөйләшеп карагыз, ул күзлеләргә караганда да яхшырак күрә, яхшы белән яманны аера белә. Бер генә адымы да юлдан читтә түгел!» — дип тагын әлләниләр өстәп ярсып кычкырасы килә Ләйсәннең. Юк, кычкырмый, Дамир ишетәчәк бит. Дамирдан ояла Ләйсән, йөрәк тибешен ишеттермәс өчен дә читкәрәк баскандыр әле әнә. Күршесендә Дамир булмаса, сукырларның күңел дөньясын каян белер иде Ләйсән. Әйе, дөм сукыр да, аяксыз, кул-

сыз да, телсез, колаксыз да кеше булып дөньяга туалар, кеше булып эшләргә, сөяргә, яшәргә хаклы алар! Сау-сәламәт кеше кебек үк кайгыра, шатлана, уйлана, хыяллана гарип кеше. Сау-сәламәт кешеләрнең матуры да, ямьсезе дә булган кебек, гарипләрнең дә төрлесе бар. Кешенең күңел матурлыгы һәм ямьсезлеге бар итә бит бу тормышны. Дамир кебекләр күбрәк булсын иде әле! Күзләре күрмәсә дә, Дамир яктыга, матурлыкка омтыла, барын да күрә. Ләйсәнгә: «Син җирнең чәчәгедер!» — ди бит, күрә белмәсә шулай әйтә алмас иде! Ләйсәннең йөрәге жу итеп китте, куркыныч бер уй килде аңа: «Сукыр кеше ничек ярата икән, ул бит күреп яратмый?!» Юк әле, алар мәхәббәт турында сөйләшмиләр. Бу хакта Дамирдан ничек сораштырсын инде Ләйсән, егет барын да аңлап алачак бит. Юк-юк, белмәсен, Ләйсәннең әллә ниләр уйлап яшәвен, кайнар хисләрен ләйсән ямгыр тамчылары итеп сибүен белмәсен егет. Әйе, үксеп чыккан төннәре бар кызның, их, бер генә тапкыр күрсен иде Ләйсәнне Дамир. Егет кызга карап елмаер иде микән, яратыр идеме?

— Дамир, «Җаныма сарылгансың» дигән җырны ишеткәнең бармы?

— Әлләче! Кем җыры, сүзләре ничек?

— Мин бүген Яңавылга барып кайттым. Яңа җырлар язылган кассета алдым. Шул җырны бик яратып тыңладым, иртәгә сиңа да тыңлатырмын әле. Җырның сүзләрен язучы турында ишетеп беләм: Кәүсәрия апа Шафикова. Ул үз аякларына басып йөри алмый икән. Ә җырның сүзләре болай:

*Бөгелдем, сыгылып төштем,*
*Сагыну мине җиңде.*

*Сандугачым булып кайчан*
*Кайтырсың икән инде!*

Дамирның да бу җыр язылган кассетасы бар икән. Егет иелеп агач төбендә утырган баянын алды, уйнап акрын гына тавыш белән җырлый башлады:

*Бөдрә тирәккәең булып*
*Көтәм дә, көтәм сине.*
*Аерма кояшлы күктән,*
*Канатсыз итмә мине.*

Җырны Ләйсән белән Дамир бергә җырлап бетерделәр:

*Ашык кайтыр юлларыңа,*
*Үзең дә сагынгансың.*
*Сагынгансың, бер моң булып*
*Җаныма сарылгансың.*

Алар кайтыр юлга чыктылар.

— Дамир, укуыңны тәмамлагач, эшкә кая урнашырсың икән?

— Үзебезгә кайтам, ерак китәргә теләгем юк. Ә син кайда авырулар дәваларсың икән, Ләйсән?

— Мин дә үзебезгә кайтырмын дип уйлыйм. Бүә буеннан китәсем килми!

— Ләйсән, синең тавышың матур, сәхнәдә җырла, син бит Бүә буенда сайраган сандугачларның берсе!

— И, алай ук түгел инде, Дамир, арттырасың!

— Һич арттыру түгел, Ләйсән, синең җырлаган тавышыңны магнитофонга яздырып алыр идем, ризамы?

— Риза! Тулы бер концерт бирәчәкмен!

— Ләйсән, син миңа тагын менә шушындый җырлы кичләр бүләк итәрсеңме?

— Шатланып, Дамир!

Дамирның да, Ләйсәннең дә әле чәчәккә бөреләнеп кенә килгән күңел гөлләренә карлы бозлы яңгырлар яумасмы киләчәктә? Кояшлы көннәр, җырлы кичләр көтәме аларны?

Кыз курыкмасмы тормыш сынауларыннан, егетне ялгыз калдырмасмы?

## *Синең хатларың*

Синнән килгән хатларны кат-кат укыйм. Укып туймаслык хатлар язасың, шатландырасың мине. Рәхмәт! Синең хатлар һәрчак тере, синең тавышың бар анда, мин аны ишетәм, тавышың да, йөрәк тибешең дә шундый якын, кадерле миңа. Әйтерсең лә син еракта түгел, янымда гына. Синең ялкынлы хатларың якынайта безнең араны. Кышкы салкыннар да куркытмый мине: синең хатлар килеп тора, җылы хатлар! Тышта кар-буран, ә минем күңелдә язлар балкышы. Син миңа: «Карлыгачым!» — дип эндәшәсең, мине канатлы кошка әйләндереп кояшлы, зәпзәңгәр күк киңлегенә чөясең. «Чәчәгем син!» — дисең дә, сары яфрак очкан көзләрне салават күпере нурлары белән балкыган җәйгә әйләндерәсең. «Кояшым!» — дисең, күңел күгемне каплап алган куркшел болытлар шунда ук таралып бетә, дөньям нурга тула. «Мәхәббәтем!» — дигән саен күз яшьләрем ләйсән тамчылары булып гөлләргә тама.

Синең сүзләрең тере су булып иреннәремә тия, назлы җил булып чәчләремә кагыла. Сүзләрең күзләрең булып мөлдерәп күзләремә карый. Күзләреңдә моң бар: сагынасың! Сагыну белән бергә күзләреңдә яктылык та күрәм мин. Ут — өмет яктысы, өметең — исән, димәк, алдагы көннәр безне очраштырачак!

Хатлар барын да сөйли, хатларда — синең сулыш! Яз, кадерлем, барын да яз, борчылсаң да, шатлансаң да яз. Нинди төшләр күргәнеңне дә миңа хәбәр ит. Бакчалар чәчәккә күмелгәч төннәр салкын булганда, чапкан печән, урган ашлык яңгырларда калганда, кыр үрдәген аткан тавыш ишетелгәндә без бергә борчылабыз. Гаиләләрдә бәби туе үткәрелсә, яңа йортлар күтәрелсә, авырулар терелеп аягына басса, күп еллардан бирле күрешмәгән дуслар, туганнар очрашса, без чиксез шатланабыз. Менә шулай уртак безнең һәрнәрсә.

Иң кирәкле сүзләрне тезеп кенә языла синең хатлар, әйтерсең лә хат түгел, шигырь язасың! Яз! Синең барлыгыңа шатланам, хатларыңны куанып укыйм. Син яз, энҗеләр итеп тез, барсын да яз. Тик: «Бу сиңа соңгы хатым!» — дип яза күрмә, язма андый хатыңны, кошкаең канатын каерма!

## *Яшьлегем төсе*

Ишеткәнем бар иде: онытасың килеп тә онытамаган кешеңнең фоторәсемен утта яндырсаң — онытасың, имеш. Альбомымнан карточкаларыңны куптарып алдым да утка ташладым. Әйе, әйе, утка ташладым. Яшьлектән истәлек

булып калган синең фоторәсемнәрең утта яна. Күзләремә килгән яшьләр тамса, дөрләп янган ут һичшиксез сүнеп калыр иде. Шуңа да мин ут яныннан киттем.

Карточкаларың янды. Шунда бергә күз алдымнан бер дә китми йөдәткән буй-сының, керфекләремне көйдереп алган күз карашың, һәрчак ягымлы булып ишетелгән йомшак тавышың һәм әйткән назлы һәр сүзең янып бетәр кебек иде. Карточкаларыңнан көл генә торып калды да бит — күзләреңне күрәм, тавышыңны ишетәм һаман. Сине, синең белән бергә йөрәгемдә яшәгән гомеремнең гүзәл елларын нинди утта яндырмак кирәк?! Ул кадерле, матур кичләр көл була аламыни?! Үзе тоташ ут бит ул яшьлек, ут бит ул мәхәббәт. Аннан да көчлерәк ут-ялкынның булуы мөмкин түгел. Мәхәббәтне син түгел, сине мәхәббәт үзе яндыра. Утка-суга сала ул сине. Фоторәсемнәреңне утка ташлаганчы, нишләп мин бу турыда уйламаганмын соң? Шулай икәнен еллар үткәч кенә белдемме әллә?

Яшәлгән елларымны өч кисәккә бүләм мин. Сине белмәгән елларым. Белмим: ничек яшәгәнмендер. Синең елмаюың белән якты булган елларым: канатланып очтым, җәйгор нурлары белән кочагым тулы иде. Һәм, сине сагынган елларым. Сагынган елларым җырлы-моңлы. Сагынган елларым мине гомерем чикләренә кадәр озата барачак. Яшьлек төсен нинди яңгыр, бураннар җуя алсын күңелдән?! Юк ул андый көч. Язлар, көзләр белән алышынып торган елларның гына көче җитми монда. Син — яшьлегем төсе. Тиңе булмаган гүзәллек синдә. Ничек онытмак кирәк сине?! Язларда сулар ташу бар: син минем ташкын хисләрем. Көзләрдә яфрак-

лар оча: син минем үзе газаплы, үзе татлы сагышым, моңым. Мин синең белән яшим. Җиремдә дә, күгемдә дә син бар. Җиремә яз булып киләсең, күгемдә йолдызым булып балкыйсың. Тик син ерак, күктә генә түгел, җирдә дә еракта син миннән. Ерак бул, ерак булсын арабыз, синең өчен дә, минем өчен дә шулай яхшырак. Мин инде сагынып, төшләремдә генә күреп яшәүгә күнектем. Сине төшемдә күреп уянсам, кышларым язга әйләнә, якты да, җылы да була ул көнем. Ешрак кер төшләремә, зәңгәр нурлар булып балкы, күңелемне иркәлә. Чакыр мине, үзеңә чакыр, яшьлегем. Альбомымда фоторәсемнәрең күптән инде юк. Кирәкмәгәнгә түгел, әллә онытырмын дип, мин аларны утка яккан идем. Фотоларны түгел, йөрәгемне сагыш утына ташлаганмын икән. Янган утка карап торам. Ялкын телләре арасында фоторәсемнәрең күренеп калыр кебек. Әгәр бу чынлап шулай булса, янудан да курыкмыйча кулларым белән утка керер идем, мөгаен. Фоторәсемнәрең белән бергә хәтерем учакларында син үзең дә янып онытылсаң, мин ничек яшәр идем икән? Янып көл булыр идең, учак сүнәр иде. Ничек яшәр идем утсыз? Ничек яшәр идем сагынусыз? Сагынуларым булып кил син миңа, кил син миңа, яшьлегем!

## *Йолдызым*

Йолдызлар чынлап та зәңгәр микән? Әнә бит, зәп-зәңгәр кебекләр. Әллә минем күзләремә генә зәңгәр булып күренәме? Йолдызлар белән күк йөзе туп-тулы, эресе бар, вагы бар — шундый матур булып сибелгәннәр, һәрберсе балкый.

Мондый төннәрдә йоклап буламыни?! Таңга кадәр, таң йолдызы Чулпан кояш нурларына уралып күздән югалганчы керфек тә какмаган чакларым бар. Хыялларым артыннан кайчак җыр эзләп, күпвакыт, серле йолдызлар иленнән күңелне сагышларымнан юата алыр көч эзләп җирдән күккә атылам мин. Хыялым канатлары белән йолдызларга кагылып-кагылып үтәм, юк, йолдызлар ачуланмый, кагылган саен зәңгәрләнеп җемелдиләр. Йолдызлар кайчак бик еш атыла. Бер карасаң, йолдыз атылуы матур да, сине әйдәп, якты юллар сыза-сыза хыялың оча кебек. Ияреп китәсең, шундый рәхәт, мәңгелек рәхәтлеккә чумасыңмыни. Тик бу рәхәтлек берничә секундлык кына. Йолдыз атылганда калтыранып куям, мин генә түгел, балкып җемелдәгән йолдызлар да калтырана кебек. Ул атылган йолдыз кемнеке булды микән? Бу сорау мең тапкыр кабатлана. Йолдыз еракка-еракка китеп, беркайчан да кабат кабынмас өчен сүнеп кала. Менә эле генә дә бер йолдыз атылды. Кемнең шулай өмет йолдызы сүнде икән? Бу минутта кем өзгәләнә, кем сызлана, кемнең йөрәккәе телгәләнә икән? Тынычлан, дигәндәй йолдызлар зәңгәр нурларын керфекләремә кундырдылар. Йолдызлар да сөйли белә. «Без бит югары, без күрәбез. Дөньяда әлләниләр бар, — диләр алар, — бер үк мәлдә миллионнар үксеп елый, миллионнар көлә. Өметләр дә шулай, берәүләр күңелендә сүнсәләр, берәүнекендә кабыналар. Туу да бар, үлү дә бар бит дөньяда, шуңа да дөнья бит ул, зур дөнья. Атылган йолдыз онытылырга тиеш, күрәсең бит, без күк тулы. Син билдәсез берәүнең сүнгән йолдызы өчен борчылма, сайла, арабыздан беребезне үзеңә сайлап ал.

лар оча: син минем үзе газаплы, үзе татлы сагышым, моңым. Мин синең белән яшим. Җиремдә дә, күгемдә дә син бар. Җиремә яз булып киләсең, күгемдә йолдызым булып балкыйсың. Тик син ерак, күктә генә түгел, җирдә дә еракта син миннән. Ерак бул, ерак булсын арабыз, синең өчен дә, минем өчен дә шулай яхшырак. Мин инде сагынып, төшләремдә генә күреп яшәүгә күнектем. Сине төшемдә күреп уянсам, кышларым язга әйләнә, якты да, җылы да була ул көнем. Ешрак кер төшләремә, зәңгәр нурлар булып балкы, күңелемне иркәлә. Чакыр мине, үзеңә чакыр, яшьлегем. Альбомымда фоторәсемнәрең күптән инде юк. Кирәкмәгәнгә түгел, әллә онытырмын дип, мин аларны утка яккан идем. Фотоларны түгел, йөрәгемне сагыш утына ташлаганмын икән. Янган утка карап торам. Ялкын телләре арасында фоторәсемнәрең күренеп калыр кебек. Әгәр бу чынлап шулай булса, янудан да курыкмыйча кулларым белән утка керер идем, мөгаен. Фоторәсемнәрең белән бергә хәтерем учакларында син үзең дә янып онытылсаң, мин ничек яшәр идем икән? Янып көл булыр идең, учак сүнәр иде. Ничек яшәр идем утсыз? Ничек яшәр идем сагынусыз? Сагынуларым булып кил син миңа, кил син миңа, яшьлегем!

## *Йолдызым*

Йолдызлар чынлап та зәңгәр микән? Әнә бит, зәп-зәңгәр кебекләр. Әллә минем күзләремә генә зәңгәр булып күренәме? Йолдызлар белән күк йөзе туп-тулы, эресе бар, вагы бар — шундый матур булып сибелгәннәр, һәрберсе балкый.

Мондый төннәрдә йоклап буламыни?! Таңга кадәр, таң йолдызы Чулпан кояш нурларына уралып күздән югалганчы керфек тә какмаган чакларым бар. Хыялларым артыннан кайчак җыр эзләп, күпвакыт, серле йолдызлар иленнән, күңелне сагышларымнан юата алыр көч эзләп җирдән күккә атылам мин. Хыялым канатлары белән йолдызларга кагылып-кагылып үтәм, юк, йолдызлар ачуланмый, кагылган саен зәңгәрләнеп җемелдиләр. Йолдызлар кайчак бик еш атыла. Бер карасаң, йолдыз атылуы матур да, сине әйдәп, якты юллар сыза-сыза хыялың оча кебек. Ияреп китәсең, шундый рәхәт, мәңгелек рәхәтлеккә чумасыңмыни. Тик бу рәхәтлек берничә секундлык кына. Йолдыз атылганда калтыранып куям, мин генә түгел, балкып җемелдәгән йолдызлар да калтырана кебек. Ул атылган йолдыз кемнеке булды микән? Бу сорау мең тапкыр кабатлана. Йолдыз еракка-еракка китеп, беркайчан да кабат кабынмас өчен сүнеп кала. Менә әле генә дә бер йолдыз атылды. Кемнең шулай өмет йолдызы сүнде икән? Бу минутта кем өзгәләнә, кем сызлана, кемнең йөрәккәе телгәләнә икән? Тынычлан, дигәндәй йолдызлар зәңгәр нурларын керфекләремә кундырдылар. Йолдызлар да сөйли белә. «Без бит югары, без күрәбез. Дөньяда әллә ниләр бар, — диләр алар, — бер үк мәлдә миллионнар үксеп елый, миллионнар көлә. Өметләр дә шулай, берәүләр күңелендә сүнсәләр, берәүнекендә кабыналар. Туу да бар, үлү дә бар бит дөньяда, шуңа да дөнья бит ул, зур дөнья. Атылган йолдыз онытылырга тиеш, күрәсең бит, без күк тулы. Син билдәсез берәүнең сүнгән йолдызы өчен борчылма, сайла, арабыздан беребезне үзеңә сайлап ал.

Йә, кайсыбыз яктырак, матуррак? Күңел йолдызыңа кайсыбызны тиңләр идең?»

Йолдызлар күз кысышып мине шаярталар. Авыр уйларга бирелүдән саклый алар мине, җем-җем килеп күзләремне камаштырып каршымда биешәләр. Яратам мин йолдызларны, иң яктысын эзләп табып, кулларыма аласым килә. Юк, мин аны куеныма яшермәс идем, учларыма салып, туйганчы карап торыр идем дә кире күккә, үз урынына элеп куяр идем. Төннәр буе балкып, миңа елмаеп торачак бит ул. Мине бик бәхетле итәчәк.

Бар, минем дә үз йолдызым бар, беренче булып кабынган йолдызым. Син: «Йолдыз хакында шигырь яза башлаган идең, язып бетердеңме? Укып карыйсым килә», — дисең. Әйе, ул кич матур иде, йолдызлар зәңгәрлеге иде ул кичтә. Мин аны оныталмам. Ә шигырь язылмады, ул матур шигырь булалмас иде. Ул кич исемә төшкән саен күңелем кыллары өзгәләнә, моң сара ул кылларны.

Хәтереңдәдер, кадерле сеңелкәшем: бер төркем кызлар, гармунчы егетне уртага алдык та, матур көйләр уйна, без җырлыйбыз, дидек. Сез җырладыгыз, мин тыңладым. Җәйге кичнең талгын җиленә кушылып моң агылды, чишмә ягыннан сандугач тавышы ишетелде. Мин, кызларны тыңларгамы, әллә сандугачнымы, дип уйладым. Икесен дә тыңладым, икесе дә матур иде. Кызлар моңында яшьлек гүзәллеге, яшьлек сафлыгы горур яңгыраса, сандугачныкында бераз сагыш та бар иде.

Балкып бер йолдыз кабынды. Күктә бары бер йолдыз. Мин шулчак синең колагыңа күңелемдә

яңа гына бөреләнеп килгән шигъри юллар пышылдадым.

— Карагыз, бер йолдыз, — диде шул чагында кызларның берсе. Җыр өзелеп калды, кызлар күккә бактылар.

— Минем йолдызым, — диде икенчесе шатланып.

— Мин беренче күрдем, ул минеке, — дип кистерде беренче кыз.

«Кызлар, ул — минем йолдызым», — диясем килде минем. Әйтмәдем. Миңа сеңелкәшләр генә булган бу үсмерләр алдында, күңелем белән сезнең белән бергә, 17—18 дә генә булса да, «Ул минем йолдызым», — дип әйтергә әллә нигә оялдым.

Кая соң, башка йолдызлар кая? Нишләп берсе генә кабынган? Кызлар сабырсызландылар. Йолдызларны минем кебек алар да ярата икән. Әнә бит, йолдыз эзлиләр кызлар. Гашыйклар шул, гыйшык утында янган чаклары. Йолдызларга карата шул ул мәхәббәт. Сердәшең дә, күңел юанычың да була беләләр йолдызлар. Әле бу кызларның үз йолдызлары табылмаган, күрәсең, дип уйладым мин. Тапмаганнар да, югалтмаганнар да. Тапсыннар, югалтмасыннар берүк. Кабыныр, берничә минут үтүгә әллә ничә йолдыз булыр күктә, һәркемгә үз йолдызы елмаер. «Әйдәгез, кызлар, җырлагыз», — дидем мин күзләремне йолдызымнан алалмыйча. Гармунчы минем теләгем буенча «Һаман яратам»ны уйнады.

*Йолдызлы аяз күгеңне әгәр*
*Авыр болытлар каплап китсәләр...*

Юк, юк, күк йөзендә бармак бите кадәр дә болыт юк иде. Мин ул кичне бер табып югалтканымны янә таптым бит. Каршымда ике йолдыз иде. Минем зәңгәр йолдызым булып килеп басты ул каршыма. Нигәдер яныма килми генә читтән күзәтте ул мине, күзләрен миннән алмады. Әллә миңа гына бу шулай тоелды микән? Мин дә аңа карадым. Инде син мине беркайчан да югалтмаячаксың, дия кебек иде бит аның карашлары. Шул ук кичтә тагын югалттым мин аны. Йолдыз булып атылып, еракка, еракка китеп сүнде минем өметем. Күк йолдызлар белән тулды, мин үз йолдызымны табалмадым, күп йолдызларның берсе иде ул. Менә шул кичтән соң, һәр кичне беренче булып кабынган йолдызны минеке, димен мин. Сиңа пышылдаган шигыремне менә ни өчен язалмадым, ул матур шигырь булалмас иде. Ул йолдыз мине алдады. «Мин монда», — дип елмайды да, йолдызлар арасына кереп югалды. Һаман да, һәр кичтә җемелди ул: «Хыял-өметләр белән яшә син, ансыз яшәү юк дөньяда. Без, йолдызлар, — мәңгелек, хыял да — мәңгелек», — ди. Моңа ышанмау мөмкин түгел.

## *Соңгы сүз*

Быелгы язны җиргә аларның мәхәббәте китергәндер кебек тоя иде кыз. Үзе якты, үзе җылы, сандугачы да башка елларга караганда иртәрәк килде бит. Бүген шомырт та, алмагач та чәчәккә күмелеп утыра. Бик якында гына, шул чәчәкле ботакларның берсендә тибрәлеп сайрый бугай сандугач.

Кыз сөйгәне белән шушында, чәчәкле, сандугачлы бакчада очрашырга тиеш. Караңгы да төшеп килә, егет озаклый шикелле. Кызның түземлегә беттеме, йөрәге җырлап тибә башлады:

*Сайра, сайра, сандугачым,*
*Синең сайрар чакларың.*
*Җан дустымны эзләп китим,*
*Бирсәңче канатларың.*

Сандугач сайрады да сайрады. Канатларын бирер иде, мөмкин түгел ләбаса! Көтә белгәннәрнең сабырлыгы алай тиз генә сынмый.

*Сайра, сайра, сандугачым,*
*Сайра бакчам түрендә.*
*Сөйгән ярым үзе килер,*
*Сагыну булса күңелендә.*
*Сайравыңны тыңлыйм әле*
*Сагышларым тынганчы.*
*Сайра, сайра, сандугачым,*
*Безне кавыштырганчы.*

Сандугач әллә сайрады, әллә бөтенләй тынып калды — кыз аны ишетмәде, чөнки егете кызның кулларына кагылды.

Рәхәт иде, һәрвакыттагыча рәхәт иде бу минутлар. Очрашу минутлары бит!

— Озак көттердең, берәр мәшәкатең булдымы?

Кызның бу соравына егет җавапсыз калмады:

— Анысы синең эшең түгел!

Кыз кулларын егет кулыннан тартып алды. Егет тагы да салкынрак дәвам итте:

— Барысын да сиңа белү кирәкми.

Сөйгәненең шулай ямьсез сөйләшүеннән кыз күңеле идәнгә төшеп киткән пыяла савыт кебек чатнап ярылды, ватыкларын җыеп кына бетерерлек түгел! Ничә еллар буе сагынышып очраштылар, күңелләрне китәрлек сүзләр әйтелми иде. Ни сәбәптән бу шулай? Алай гынамы соң әле, йөрәк ярылыр минутлар алда икән. Кыз күңел тетрәүләрен егеткә сиздермәскә тырышты, караңгылыкны ертып егетнең җылы карашын эзләде, тик табалмады.

— Син эчкәнсең бит! Кайт, ял ит, иртәгә сөйләшербез!

Дулкынланудан чак ишетерлек итеп:

— Мин сине көтәрмен! — дип өсти. Керфекләре чылана түгелме?!

— Мин иртәгә синең янга килмим, башкача очрашмыйбыз. Сиңа соңгы сүземне әйтәм: мин сине яратмыйм!

— Ышанмыйм! Яратам, ди идең бит, күп еллар буе яратам дип пышылдадың, бәхетем, дип күкрәгеңә кыстың, киләчәгебез карашларың кебек якты булыр дип, күзләремнән үптең. Ал чәчәк кебек иреннәремә иреннәрең күбәләк булып кунды.

— Мин сине яратмыйм. Гафу ит! — дип егет читкә атлады.

Мәхәббәтнең саф хисләре шулай таплана икән! Матур хыяллар да шулай челпәрәмә килә икән! «Яратам!» дип әйтә белгән йөрәк «Яратмыйм» дип тә әйтә белә икән!

Йөрәк тавышы иде микән соң ул «Яратам!» диюе? Нигә кирәк булган ялган? Ялган белән кызның зур дөньясы тетрәде бүген, бәхет таулары ишелде, күңеленең яшел куагына оя корган хыял кошы куркып, еракка очып китте. Юк,

кызның горурлыгын җимерә алмады бу кич. Кызның: «Син киләчәксең әле!» дигән сүзләрен ишетте егет, башын түбән иде.

Әмма кыз көтмәгәндә үзе башлап:

— Хуш, бөтенләйгә хушлашабыз! — диде дә, егетне язгы бакчада калдырып китеп барды. Шау чәчәкле, сандугачлы гомер язында, кызнын сөю ялкыннарына төренеп калды егет. Бәлки әле, аның үзенең соңгы сүзе: «Мин сине онытал-мадым! Ратканмын бит сине! Яратып, сагынып сиңа килдем!» — диюе булыр. Гомер язы ерак калса да, килер язларның берсендә ул шулай әйтер кебек.

## *Мин әле килермен*

Ул кичне мин сине көттем. Беренче кабат шулай беркайчан да көтмәгәндәй көттем. Юк, үткәннәрне кабатлар өчен түгел, әлегә әйтел-мәгән, күңелдә сер булып сакланган сүзләр газа-быннан йөрәкне арындырыр өчен, бер сөйләшер өчен көттем сине. Нидер әйтмәкче булдың да син беркөн, әйтмәдең, әйтмим, дидең. Бармыни әле, әйтелмәгән сүзләрең дә бармыни, дип сора-дым мин. Бар шул, күп, бик күп әле әйтер сүз-ләрем, дигән идең син. Кулга-кул тотынышып үскән тупыллар янында очрашырга тиеш идек без. Сине көттем, күктә балкып йолдызлар ка-бынганын көттем.

Йолдызлар кабынырга өлгермәде, көтмәгәндә әллә каян гына килеп чыкты да күк йөзен болыт каплады. Мин сине көттем. Минутлар артыннан минутлар йөгереп үтте. Чамасыз күп икән ул ми-нутлар, бер-бер артлы үттеләр дә үттеләр, безне

очраштырыр бәхетле минутлар җитмәде дә һаман җитмәде. Килерсең, дөньямны балкытып елмаерсың, күзләремә сөеп карарсың, сөйләп торуның кирәге дә булмас, йөрәгем тибешен ишетерсең, барын да, барын да аңларсың кебек иде. Юк, мин сөйләр идем, бер юанып калыр өчен сөйләр идем. Килмәдең. Килмәдең түгел, килдең син, соңга калып килдең. Йөрәгем суырылып, өметләрем сүрелгәч, сүнгәч килдең.

*Сүнгән өметләр кабыныр яңадан,*
*Сине күргәч тә, сине күргәч тә,*

дип җырлыйлар да бит, юк, сине күргәч тә өметләрем кабат кабынмады. Кабынырга сүнмәгән, күрәсең. Сихри минутлар бүләк итәлмәдең син миңа. Сиреньнәр яныннан үткәндә бер яфрак өзеп алган идем. Сирень яфрагы йөрәк рәсемен хәтерләткән өчен өздем. Сине көткән чакта, минутлар үткән саен бармак очларым белән мин яфракны яра тордым. Яргаланып бетте яфрак, ләкин төсен югалтмады: яфрак булып кала белде. Йөрәк тә бит, меӊ ярасы булсын — йөрәк булып кала. Берничә генә минут без бергә булдык. Сине көтеп үткәргән минутларыма караганда, син килгәч үткән шушы берничә минут авыррак, газаплырак булды миңа. Көткәндә якты, өметле бит ул минутлар. Син кулыма кагылырга гына иткән идең, яфраклар шыбырдаша башлады. Алар миңа гына ишетелерлек итеп: «Көтмәдең түгел, көттең бит, соңлап килүенә гафу да үтенми ләбаса. Сиңа кайтырга кирәк, кайт син», — дип пышылдадылар кебек. Кайтыр сукмагыма төштем.

— Ашыкма, янымда бераз гына бул инде, — дидең син.

— Соң инде, — дидем, — кайтам.

Яңгыр да төшкәли башлады. Әйтерсең лә йөрәгемнең әрнеп сызлаганын белде, мин елар урында күктә болыт елады. Кинәт сискәнеп киттем. Мин башка берәүне сөям, кичер, диярсең дә миңа биргән йөрәгеңне кире сорарсың, менә шуңа гына килгәнсеңдер кебек тоелды. Юк, юк, йөрәгеңне кире бирмәячәкмен. Мин аны күкрәгемә, үз йөрәгем янына салып куйдым. Кайтырга ашыктым мин. Сиңа хәерле төн теләдем дә, яргаланып беткән яфракны учларыңа салып, китеп бардым.

Яфракны, яфракны нишләттең? Кая куйдың? Ул бит минем мең ярасы сызлап торган газаплы йөрәгем иде. Син шуны белдең микән? Очрашмабыз кебек, очрашмабыз кабат. Соңгы очрашуыбыз шушы булгандыр. Ах, әйтер сүзем бар иде бит, бер генә әйтер сүзем бар иде. Ул сүземдә кошлар сайравы, яфраклар шыбырдавы, йолдызлар җемелдәве, кояш кайнарлыгы бар иде. Әйталмадым инде, әйталмамдыр.

Күз сукмакларга сары яфраклар сипкәч мин әле монда янә килермен. Килермен, очрашу көтеп түгел, яфраклар җыяр өчен килермен.

## *Чәчәк язмышы*

Сабый чәчәккә Җир-ана болай диде:

— Син дөньяга килдең, сәлам бир! Тамырларың минем куенымда, үс, кояшка үрел!

Болын чәчәге беренче тапкыр күзен ачты һәм зәңгәр күкне, кояшны күрде. Дөньяга сәлам биреп елмайды ак Чәчәк, таҗларын ачты. Аның

күзләренә зәп-зәңгәр күк диңгезендә йөзгән ак болытлар чалынды.

— Җир-анам, алар нәрсә? — дип сорады ул.

— Болытлар алар, кояшның бик кызу чагы булыр, кибегерсең, болыт килер дә яңгыр булып явар, синең яшәү көнең артыр! — дип аңлатты Җир-ана.

Чәчәкнең матурлыгы минут саен арта барды, тәмам ачылып бетте. Нәкъ шулвакыт урман-кырларны, болыннарны бер әйләнеп үтим әле дип сәяхәткә чыккан Җил-егет, болын чәчәген күреп, туктап калды. Бер күрүдә Чәчәккә гашыйк булды Җил-егет, түзмәде ул:

— Нишләп әле бүген дөнья үзгә матур дисәм, син бар икән монда, гүзәлем! — дип Чәчәккә якын ук килеп, назлы сүзләрен пышылдады.

— Син кем? — дип сорады Чәчәк.

— Мин — Җил-егет, сиңа гашыйк Җил-егет!

Җил-егетнең җылы тынына Чәчәк иркәләнеп тибрәлеп куйды. Җил-егет аны кочагына ук алды да пышылдавын дәвам итте:

— Син дөньяга килгән бер матурлык! Синсез яз да, җәй дә, ялкынлы мәхәббәт тә булмас иде! Рәхмәт сиңа, дөньяга килеп тиңсез матурлыкка ия булганың өчен.

Син минеке, минеке генә! Беренче тапкыр шулай ялкынланып, шашып яратам! Мин гел шулай бүгенгедәй йомшак, назлы булып исәрмен. Җылымны гына тоеп яшәрсең, Чәчәгем, бердәнберем!

Чәчәкнең шатлыгы чиксез иде бу мәлдә. Назлы Җил-егетне тәмам үз итте ул, яратты. Көне буе бергә булганнан соң, Җил-егет Чәчәккә Җидегән йолдызлы төнне бүләк итеп, каядыр китеп

югалды. Таң белән килеп җитте ул, Чәчәкнең яшьле күзләрен үпте. Сөю яшьләре булып, Чәчәк таҗларына таң чыгы кунган иде. Җил-егет белән ак Чәчәкнең кайнар хисләреннән җыр яралды. Ул җырны кошлар отып алып, дөньяга яңгыратты. Җырлы иртәләрнең берсендә Җирана Чәчәккә эндәште:

— Кара аны, Җилгә ышаныч бик аз, бүген ул — җылы, йомшак, иртәгә — зәһәр суык. Матур сүзләренә ышандырып, ак чукларыңа уралып, Җил сине алдамасын, күңелеңне яраламасын!

Чәчәк Җир-анасы сүзләрен ишетсә дә, саф мәхәббәт дулкыннарында тибрәлә.

— Дөньядагы иң матур чәчәк син, ышан сүзләремә! Йә, ышанасыңмы?

Җил-егет Чәчәкнең күзләренә карап, җавап көтте.

— Ышанам, син әйткәч ышанам! — диде Чәчәк.

Яңа көн туды. Йокыдан уяныр да, җылы назлары белән килеп җитәр дип Җил-егетне көтте. Менә җил исә башлады, тик ул кичәге кебек түгел иде, Чәчәк аны танымады.

— Син Җил-егет түгел, Җил-егет талгын гына исә, иркәли! — диде Чәчәк елардай булып.

— Танымыйсыңмы, гүзәлем? Мин бу, мин! Хәер, «гүзәлем» дип сиңа гына эндәшү дөрес үк булмас, болында чәчәкләр күп, бар да үзенчә гүзәл. Ах, нишләп мин аларны күрмәгәнмен! Чәчәкләрнең аллары да, зәңгәрләре дә, сарылары да матурлар, алар бар да минем кочагымда!

Җил-егетнең бу сүзләре Чәчәк сабагын кисеп үткәндәй булды. Чәчәк калтыранып, үкседе.

— Нигә син шундый салкын? Таҗларымны йолкыма, иркәлә, кичәгечә ярат мине! — дип сулкылдады ул, Җил-егет шаркылдап көлде, Чәчәкне кызганырга уйламады да. Болын тулы чәчәк булганда, бер бөртек чәчәк өчен нигә борчылсын ул?

Чәчәк Җир-анасы күкрәгенә бөгелеп төште.

— Ни булды миңа, Җир-анам, нишләдем?

— Син сөю ләззәте белән яшәдең дә, инде хыянәт ачысын татыдың. Мәхәббәтең — Җил-егет башта йомшак кына исте дә, инде көчле давылларга әйләнеп, төбең-тамырың белән йолкып алмакчы. Юк, тамырларыңны бирмим! — диде Җир-ана. — Яңа язда яңа чәчәк булып терелерсең, синең киләчәгең бар!

Кеше күңеленең дә Җил-егет хыянәтеннән сулып калган Чәчәк хәлендә булганы бар. Сөйгәненең хыянәтеннән ул үлем чигенә җитсә дә, ихтыяр көче аны янә терелтә. Ярата белүе белән яңа язның яңа чәчәгенә тиң ул!

## *Очрашу*

Бүгенге көнне көзге көн дип әйтүе дә кыен. Артык кызу булмаса да, күктә кояш балкый. Көньяктан искән җилләр тирәкләрне кочып тибрәтә. Яңа гына яңгыр явып үтте, менә-менә нурланып салават күпере күренер кебек. Әле көз башы гына шул, көзге сукмактан бер генә адым ясалган. Көз айларының иң матур мәле бу. Җәйне сагынмый әле күңел, бүген дә җәй кебек. Көзге көндә җәй матурлыгын күреп булган кебек, кеше дә үзендә үткән яшьлек елларының

гүзәллеген тоеп яши. Кырыкка җиткән кеше күңелендәге кичерешләрне бүгенге көнгә карап аңларга була. Кырык яшь — көзнең бүгенге көне ул. Көн матур бүген, шушы матурлык белән яшәргә дә, яшәргә әле. Көзләргә кергәч тә җәй яктысын күреп, җәй җылысын тоеп яшәве нинди рәхәт! Бүген мин шушы рәхәт дулкында тирбәләм. Күкрәүләре еракта калган инде, яшьлегем бүген миңа сәлам бирә, кул изи. Ишетелә, күкрәүләре кайтаваз булып ишетелә, күңелнең кырык кылына кагылып, моңландыра.

Кеше кырыкка җиткәч үткән юлларына, елларына борылып карый икән.

Үткән яшьлеге белән ул беренче тапкыр шушында очраша икән. Аралар әле шундый якын, кул биреп күрешерлек. Бүгенге көзге көн белән кичәге җәйгесе әнә ничек якыннар бит, мәңге аерылмас кебекләр. Матур очрашу бу, ләкин кыска вакытка очрашу. Киләчәктә мондый якыннан очрашу булмаячак.

Әле көн — матур җыр кебек. Күз ачып йомганчы барысы да үзгәрер, салкын җиле исә башлар, кар катыш яңгыры сибәләр. Табигатьнең үз холкы бар бит: бала кебек көлеп торган җиреннән үксеп елап җибәрер, кабат көлдерермен димә. Көзнең килер көннәре үзгәрәк булыр, агачларда бер генә яфрак калдырмас ул, өзгәләп ташлар. Кеше дә гомеренең чын көзендә яши башлагач, әнә шул яфраклар кебек өзгәләнә башлыйдыр. Чын көз килә шул. Чын көз, салкын, моңсу көз җиткәч түтәлдәге гөлләр тере калалмый. Ә кеше күңелендәге гөлләр һәрвакыт тере булырга тиеш. Кырык яшендә кешенең күңел бакчасы шау чәчәккә күмелгән була. Илле, җитмеш, туксан яшен һәм аннан соңгы елларын

да кеше чәчәк бәйләмнәре белән каршыларга тиеш. Бүгенге көзге көн үзенең матурлыгын киләчәк көннәргә алып баралмый, ә кешедә андый мөмкинлек бар. Кырык ел буе җыйган чәчәкләремне кулыма тотып киләчәккә, чын көземә, алтын елларыма каршы китеп барам!..

## *Илһам китерер сәлам*

Үземә килгән барлык хатларны җыеп барам, алар миндә бик күп. Хатларны ертырга да, утка ташларга да кулым бармый — алар миңа сәлам алып килгән бит. Өшегәндә җылытканнар, борчылганда юатканнар ул хатлар. Шуңа да мин аларны кадерләп саклыйм. Хатлар үткәннәрем белән бәйле, алар минем йә кояшлы, йә буранлы көннәрем. Хатлар миңа күрешергә сузылган куллар кебек, мин дә сузылган кулларга кулымны сузам — хатларны җавапсыз калдырмыйм. Хатлар арасында танышу хатлары да күп. Унсигез яшемдә дә, егермедә, утызда да танышу хатлары алдым мин. Егетләр язган шундый хатлар һаман да килә әле. Танышып, хатлар алышырга, очрашырга теләп язалар аларны, мине яшь кыз дип уйлыйлар, күрәсең. Ә минем яшьлегем үткән шул инде. Гомернең язгы ташулары тынып калган, тәүге чәчәге умырзая да җырларымда, моң дулкыннарында гына тибрәлеп яши. Мин егеткә шулай дип дөресен язам һәм аннан башкача хат килми. Ул миңа сер булып кала: кем ул, язмышы, уйлары, хыяллары нинди? Мин бу сорауларга җавап алмыйм, сер булып калучылар күп. Яшь чагымда танышу хатлары артык көчле тәэсир итмәгән икән. Ныклап танышып өлгер-

мәгән кеше белән араны өзүе әллә ни кыен булмаган. Ул чактагы хатлар уйландырмаган, күңелне ярсытмаган. Юк, бөтенләй үк буш булмаган алар: мине канатландырган, хисләремә ялкын өстәгән. Чәчәккә бөреләнгән күңел гөлемә ләйсән яңгыры булып сибелгән ул хатлар. Мин моның шулай икәнен әле генә белдем. Әле килгән хатлар мине тирән уйларга сала. Танышырга теләүче бу егет сөйгән ярын югалткандыр да, үзен юата алырлык берәүне эзли кебек. Аның хыялында мин дә — бер яшь кыздыр. Хат язганчы ул минем белән уйларында очрашып сөйләшкәндер. Сандугачлар чут-чут сайраган матур кич булгандыр ул — без очрашкан кич. Хисләргә бирелеп, бер-беребезгә ялкынлы шигырьләр сөйләгәнбездер, җырлар җырлашканбыздыр. Мин аның күңелен аңлаучы бердәнбер кеше булганмындыр. Якты хыяллары аны күктәге зәңгәр йолдызларга караткандыр. Йолдызлар арасыннан иң якты йолдыз булып мин елмайганмындыр. Назлы җил булып чәчләренә кагылганмындыр. Якты көне итеп күргәндер ул мине. Язып салган хатына җавап алганчы, ул шулай сихерләнеп яшәячәк. Тик минем хатым аның күңелендә кабынган өмет утын өреп сүндерәчәк шул. Әйе, тагын берәү миңа сер булып калачак. Аның турында күп беләсем килсә дә, беләлмәячәкмен — кабат язмаячак.

Әйләнеп килгән язлар кебек, миңа танышу хатлары килә. Мин ул хатларны көтеп алам, алардан башка яшәве күңелсез булыр иде кебек. Танышу хатларын яшьлектән сәлам итеп кабул итәм. Хатлар укыганда яшәрәм, ямь-яшел яфрак ярган тирәк белән тиңләшәм. Рәхмәт хат язучыларга, алар миңа илһам китерә, мин аларга яшь кыз булып җырларымда барырмын.

## *Минеке бул!*

Минеке бул. Аяз күкле, матур көнем булып кил миңа. Ул көннең җилләре талгын гына исеп, тал-тирәкләрнең яшел ефәк чукларын җилфердәтсен, тәрәзә башларында күгәрченнәре гөрләсен, зәп-зәңгәр һаваны иңләп-буйлап, бер түбәнгә, бер югарыга атылып карлыгачлары канат каксын. Түтәлләргә сулар сибеп, матур гөлләр үстерик. Гөлләр хуш ис бөркеп утырсын, күзләрне иркәләсен, күңелне назласын. Тормышыбыз бакчасында чәчәк атсын ул гөлләр, берсен дә өзмик, сулдырмыйк. Бергә җырлыйк, бергә көлик. Бәхет үрләренә җитәкләшеп бергә күтәрелик тә: «Мин бәхетле, бик бәхетле. Бәхетем — кояштай түгәрәк!» — дип бертавыштан, бар дөньяны яңгыратып кычкырыйк. Мең тапкыр кайтаваз булып яңгырар бу аваз.

Минеке бул. Очрашу көннәрен көтеп талган йөрәкләргә ял бирик. Төн йокыларыбыз татлы булып кире кайтсын. Сагыш юшкыннары утырган күңелләребезне чайкатып түгик, сагышның тамчысы да калмасын. Күзләрдәге моң, яшь пәрдәсен ертып ташлыйк, дөнья яктысы, тормыш яме ачыграк күренсен. Кирәк икән — икәү бергә еларбыз, бергә суларга төшеп йөзәрбез, утларга кереп янарбыз. Давылларга каршы очарга туры килсә дә, коточкыч булмас, без бит пар канатлы булабыз. Канатлар канга тузып, хәлсезләнеп ятып калсак та, бер-беребезнең иреннәребезгә тере су булып тамарбыз. Без яшәргә тиеш, яшәр өчен тудык, яшәр өчен очраштык, яшәр өчен яратыштык.

Минеке бул. Гаҗәпләнеп тә, сокланып та карасын безгә күзләр. Ятларга бирмә мине, гомер

юлымны синең белән генә үтәсем килә. Хисләр ялкыны кар-бозларны эретсен, шатлыклы күз яшьләребез тамчылар булып тупылдап тамсын.

«Минеке бул!» Бу сүзләрне миңа син әйттең. «Минеке бул! Минеке бул!» Юк, кычкырып әйтмәдең, кычкырып әйтелми бу сүзләр, бер генә тапкыр пышылдап әйттең син. Күзләреңә карап, мең ишеттем шушы сүзләреңне, мең ишеттем. Мин дә сиңа күп нәрсәләр сөйләдем, күзләремнән аңлый алдың микән?

## *Елмаясың*

Кояш балкый, зәп-зәңгәр күк йөзендә кулъяулык чаклы да болыт күренми. Һава шундый саф, сулаган саен күкрәк рәхәтлектән иркенәя бара. Бәхетнең тулы чагы. Бу сихри дөньяның иге-чиге юк, хыялда гына була торган матурлыкның чынбарлыкта булуына ышанасы да килми.

Әйе, бу чынбарлык! Күңелләр — канатлы, иңнәрдә дә — көчле канатлар. Канатлар талмас та, каерылмас та кебек! Үзем якты күк йөзенә караганмын, үзем татлы хисләр дәрьясында йөзәм. Әнә, күккә бер кош күтәрелде. Күктән җиргә, җирдән күккә атыла — ул шулай очып уйный. Канат җилпүеннән аның бик бәхетле икәненә ышанасың. Шундый матур итеп сайрый кош, тирәгенә кунып болай ук сайрамыйдыр, мөгаен, юк, сайрамыйдыр! Ни булды, нәрсә котыртты мине шушы мәлдә: кинәт җәямнең кирешен тартып җибәрдем, ук очты. Күкләрне бизәгән тере матурлыкка, кошка туры очты ук. Ах! Нишләдем? Күз ачып йомган арада ук кире

әйләнде дә, килеп йөрәгемә кадалды. Кошны да, мине дә яралады бер ук. Кош йомарланып алдыма килеп төште, мин хәлсезләнеп аңа иелдем. Ук кошның канатын яралаган. Ыңгыраша-ыңгыраша үрелеп кошны учларыма алдым, учыма ярадан кан тамды. Тере бит, тере, бәгырькәем. Үлмәгән, юк, юк, үлмәячәк, минем кулларымда нишләп үлсен ул?! Мин аңа җылы тынымны өрәм, йомшак кына итеп күкрәгемә кысам. Кош минем дә яралы икәнемне белсен. Менә шулай, менә шулай якын булсак, икебезгә дә хәл керер сыман. Әлегә авырту көчле, кош та, күкрәк читлегендәге йөрәк тә авыртудан тыпырчыналар, ике ярадан да аккан кан бергә кушылып, дөнья тулып ага. Кояш юк, күкне болыт каплаган. Әле генә дөнья балкып тора иде бит. Нишләдем мин, нишләттем дөньяны? Нигә яраладым сине, ни сәбәп белән ук аттым? Минем алдымда яраланып яткан кош син бит ул, син, кадерле кешем! Саксыз кыландым, әле һаман да берәүне оныта алмавымны сиңа әйтеп, күңелеңнең очар канатларын имгәттем. Миңа авыр, бик авыр, гафу итә алсаң гына хәлем җиңеләер! Кадерлем, хәзер яраңны бәйлим. Сине дәвалар көч бар миндә, ышан, бар. Син мине яратасың, минем якты күз карашым, елмаюым, иркәләп-назлап дәшүем сиңа мең шифа булыр. Тизрәк савыктырыйм сине, дөньяма ямь кайтсын. Элеккечә күзләремә сөеп бак, күзләремдә яшь күреп, гаҗәпләнмә: йөрәгемдә әле сиңа әйтелмәгән сөю үкси. Башкача еламасын йөрәк, елап түгел, җырлап типсен ул, йөрәгемнең шат җыры булып дөньяга яңгыра! Мин беләм, менә инде сиңа рәхәт, авыртулар юк синдә. Канатларыңны җилпи-җилпи, кара карлыгачым булып күкләргә күтәрелерсең, сай-

рар сандугачым булып, зәңгәр кичләр, якты таңнар бүләк итәрсең, күңелкәем күлендә син аккош булып йөзәрсең! Юк, кабат ук атылмас! Кояш чыга, бу безнең үлеп терелүебез. Күрәм, мин синең елмаюыңны күрәм!

## *Яшьлегемә кайттым*

Күкләре чалт аяз, болыннары шау чәчәкле, бакчалары сандугачлы яшьлегемә кайттым. Ерак киткән идем инде, кире кайтыр юлларымны мәңге тапмас кебек идем, таптым, язгы кояш яктысына ачылып килгән чәчәк кенә чагыма әйләнеп кайттым. Үсмер генә чагымның назлы җилләре иңнәремнән коча, ефәк кебек шомырт кара чәчләремә кагылып-кагылып үтә. Кояш шундый зур, аның яктысы да, җылысы да килер көннәргә дә җитәр сыман. Яз, гомер язы! Җиргә язны кояш җылысы түгел, йөрәк ялкыны, хисләр кайнарлыгы китерәдер! Җемелдәп лэйсән сибелүе, беренче күкрәүләр, ярсып ярлардан ташулар — табигатьтә дә, җанда да шундый охшашлар. Моның шулай икәнлеген еллар үткәч, гомер языннан бераз ераклашкач кына беләсең, күрәсең икән. Мин ямьле чорыма кире әйләнеп кайттым. Бар да саф, бар да гүзәл! Гөлләр өзәргә якты көне бар, татлы хыялларга чумып бер әйләним әле дисәң, юлларыңны яктырткан айлы төне бар. Юк, өшемисең анда, анда яккан учакларның җылысы гомерең буена җитәчәк.

Мәхәббәт! Беренче тапкыр мәхәббәт белән очрашу — үзе бәхетле, үзе куркыныч. Күп анда сихри минутлар, андагы рәхәтлекне җан белән тоясың. Иңнәреңдә канат бар, күтәрелеп очасың,

бар дөньяны әйләнәсең, тик матурлык кына күреп, син шул матурлыкка гына колачың җәясең. Син көчле, синең канатларны җил генә түгел, давыл да каерып ташлый алмас кебек. Утларың тирә-ягыңны гына түгел, бар дөньяны балкыта, әйе, син моның шулай икәненә ышанып яшисең! Янасың! Ян! Ян да, яндыр да, син бу илдә, сөю илендә иректә.

Мин яшьлегемә кайттым. Әйдә, дип син дәштең, мине кулларымнан алдың, күзләремә бактың. Сафлык бөркелеп торган карашларыңнан качып китәр урын тапмадым, кулларымны тартып алсам, үкенермен кебек булды. Син бит мине адашырлык кара урманнарга чакырмыйсың, мәхәббәтем, без сандугачлы бакча юлында. Елларымны саный-саный, тартынып кына янәшәңдә барам. Бар тойгылар таныш миңа монда, бар да сәламле. Мин үсмер кыз, бит алмаларым алсу, керфек очларымда таң чыгы!..

## *Соң түгел*

Син шушы көннәрдә бер сәер хат алгансыңдыр. Кемнән икәне язылмаса да, син аны шунда ук белгәнсеңдер. «Ниләр язды икән, нинди хәбәрләре бар икән?» — дип уйлап конвертны ачкансыңдыр. Конверт эченнән бер генә сүз дә язылмаган ап-ак кәгазь бите алгач: «Язардай сүзе дә булмагач нигә...», — дип үпкәләп тә куйгансыңдыр. Шулай булса, син хаклы түгел: хатка язып бетерерлек кенә булмаганга язылмаган ул сүзләр. Халык әнә ничек җырлый бит: «Хатка язып сүзләр бетми, бик күп сүзләрем кала...» Син язылмаган ак кәгазь арасыннан бер яфрак

тапкансыңдыр. Сары яфрак аяк астыңа төшеп тапталмагандыр, син аны кәгазь арасыннан алып учыңа салгансыңдыр. Учыңдагы каен яфрагын җил очырып алып китмәдеме, син аның гади ак каен яфрагы булмавын аңладыңмы соң? Күңелем тирәгеннән өзелеп төшкән иде ул. Минем хәлләремне ятларга түгел, сиңа гына сөйләргә, моңнарымны сиңа гына көйләргә тиеш иде ул. Учыңда яткан яфракка карап син аның ямь-яшел бөре генә чагын хәтерләп, ерак язны, назлы язны сагынып куйгансыңдыр. Хисләр дә бит шулай бөреләнә. Бөреләр яз яктысына үрелеп яшел яфрак булып ачылгандай, йөрәктә дә тәүге хисләр булып бөреләнгән мәхәббәт гөлләре шау чәчәккә күмелә. Җылы җәйләр бигрәк тиз үтә шул, агач яфраклары саргаеп кибә. Җаныңда моң-сагышка әйләнеп калган мәхәббәт тә юк түгел шул. Уты бар, тик мәхәббәт үзе юк, үзе авыр газапка, сагынуга әйләнгән. Сары яфракка карап син шуларны аңлый алдың микән? Мин, ап-ак кәгазь арасына салып, сагынуларымның бер генә тамчысын җибәрдем сиңа. Сагынып яшәгәнемне белсен әле дидем, алай гына да түгел, үзе дә сагынып яшәсә, күңелкәен балкытып шатлыклар булып барыйм, якты өметләренә әйләнимн, дидем.

Агачлар яфрак коя, син сары буран арасыннан салмак кына атлап барасыңдыр. Яшел яз киләренә ышанасың, ә үткән яшьлек кире килмәячәк — син шуны беләсең. Белсәң дә, яшьлегеңә каршы барасың кебек. «Инде соң», — дип әйтергә кемнең теле барсын, юк, яшьлектәге матурлыкны, ялкын хисләрне яшәләчәк елларга алып барырга беркайчан да соң булмыйдыр.

Яфраклар оча, иңнәренә яфрак ята, әллә синең күңел тирәгеңнән өзелгәнме бу яфраклар?..

## *Сөю кайнарлыгы*

«Ничә кабат гашыйк булырга мөмкин дә, ничә кабат яратып була?» — дип сорасалар, йөз кабат, мең кабат, дияр идем. Азгын түгел күңелем, чиксез киң ул, йөрәгем дә әллә ничә түгел, бер генә. Бер йөрәккә мең ярату сыя алырына ышанмаучы булмас, димим. «Юкны сөйли», — диючегә йөрәгемне күкрәгемнән суырып алып күрсәтә алам. Тоташ сөю ялкынында ярсып типкән йөрәгемне үз күзләре белән күрер дә, аның әле әллә ничә яратырлык көче бар икәнен белер. Сызылып аткан таңның алсу буявына каләмен мана да шагыйрь, шигырь яза. Бу матурлыкка ничек гашыйк булмыйм, ди?! Тып-тып тамган тамчыларны, көчле ташкыннарга барып кушылырга ашыгып йөгергән гөрләвекләрне яратам. Шаулы яз. Моң агыла, язгы моң. Монда ярату гына аз сыман. Тиздән урман-кырда, бакчаларда кошлар концерты башланачагын хәбәр итеп сыерчык бер сызгырып җибәрүгә, кар китеп бетү белән җир йөзе шау чәчәккә күмеләчәгенә ышандырып беренче чәчәк — умырзая калкып, көләч көнгә керфекләрен ачуга күңел җырлый башлый.

Бөреләр! Менә-менә ачылырга торган бөреләргә яз саен гашыйк мин. Берничә көн үтүгә, бөреләр инде яфрак була. Мин аларга өр-яңадан гашыйк булам. Әнә, зәңгәр биеклектә кыр казлары, торналар оча.

Чылбыр-чылбыр тезелүләре шигъри юллар булып ак кәгазьгә ята, бу кошларны шуңа яратамдыр.

Хыялымны гелгенә үз яннарына чакырып торган җем-җем йолдызлар сүнүгә, тәрәзәмне ачып, сандугачны тыңларга яратам. Дәртле жы-

ры белән ул туып килгән өр-яңа көнне котлый. Сагышлылар өчен аның үзәк өзгеч моңнары бар. Сандугачка тургай кушыла.

Иген кырларында талгын гына җилгә тибрәлгән алтын башакларга гашыйк мин. Бу минем авылдашларым хезмәтенә чиксез соклануым, аларны яратуым.

Тау чишмәсенең челтер-челтер тавышын тыңлап, учларыма алып, суын эчәм дә, чәчәкләр янына ашыгам. Меңдә генә бетә микән чәчәкләрнең төре? Болынга чыккан саен, мин аларның һәрберсенә аерым-аерым гашыйк. Иң кайнар сөю белән назлап, иркәләп чәчәкләрне үбәргә үрелгән кояш нурларына гашыйк булмау мөмкинме соң?! Биттән сөеп искән йомшак җилләрне генә түгел, агач-гөл тамырлары сусап калган чакта яңгыр болытларын куалап китергән көчле җилләрне дә яратам мин.

Дөньяны ут алыр кебек, җирне дер селкетеп күк күкри. Көчле җилдә тирәкләр сынардай булып сыгыла. Җир өстендәге бөтен матурлык су астында калыр кебек яңгыр коя. Тик күңел курыкмый, шатлана, балкып салават күпере калкуга урман-болыннар яңа көч белән яшәүне дәвам итәчәкләренә ышана.

Мин су буенда таллар арасына качып кына су өстен күзәтергә яратам. Дулкыннар өстендә бер көйгә төнбоек тирбәлә. Мин аңа гашыйк. Су буенда тынлык буламы?! Камыш шаулый, казлар каңгылдаша. Тормышның бер матур бизәге, һичшиксез, шушыдыр.

Дөньяда асыл бизәкләр күп, ул бизәкләрне бар итүче кешеләрне яратам мин. Тирә-ягының гүзәллеген күрә белгән, яши һәм ярата белгән кешеләрне яратам. Кешеләрнең үксеп елар чак-

та йөзләрендә елмаю саклый белгәннәрен, кирәк чакта сине юата да, кирәк чакта синең ялгызыңны калдыра да белгәннәрен яратам.

Юк, бу минем яраткannнарымны санап күрсәтүем түгел. Чөнки аларны санап кына чыгу да мөмкин түгел. Йөрәгем тамыры буйлап аккан канымның һәр тамчысы саен — ярату.

Яратам! Тагы да ныграк яратырга иде. Яратырга кирәк: ташны ватсын, бозны эретсен йөрәктәге сөю кайнарлыгы!

*Эчтәлек*

Җир шары . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Йөрәкләргә дулкын кага . . . . . . . . . . . 5
Табигать һәм кеше . . . . . . . . . . . . . 6
Карлар булып явам . . . . . . . . . . . . 8
Матурлык артканда . . . . . . . . . . . . 9
Апрель . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Яз бәйрәм булып килә . . . . . . . . . . . 12
Һәйкәл янында . . . . . . . . . . . . . . 14
Алмагачлар чәчәк аткач . . . . . . . . . . 18
Уяу бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Ай яктысы . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Саумы, басу! . . . . . . . . . . . . . . . 22
Уян, Җирем! . . . . . . . . . . . . . . . 24
Чын бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Сөенеч хисе . . . . . . . . . . . . . . . 26
Тупылым-тирәккәем . . . . . . . . . . . . 28
Агачларда — кеше язмышлары . . . . . . . 29
Без — кешеләр . . . . . . . . . . . . . . 33
Якты өмет . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Көзге моң . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Тамырлар — туган якта . . . . . . . . . . 39
Җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Яну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Әнкәйләр еламасын! . . . . . . . . . . . . 45
Хатын-кыз матурлыгы . . . . . . . . . . . 47

Ана мәхәббәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Әнкәем гөлләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Сулар сибәмен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Зәңгәр чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Кабер ташы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Кайгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Югалту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Саубуллашу җыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Йөрәк тавышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Мин сиңа ышанам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Яшә, сабый! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Кар чәчәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Аклык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Хатлар язам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Елның иң гүзәл чоры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Май ае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Иңнәрдә — канат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Умырзая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Шатлык бәләкәй булмый . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Болын чәчәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Кочагыма нурлар җыям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Тамырдашлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Күз яшьләрең — көмеш тамчы . . . . . . . . . . . . . . 95
Мин елак түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Яратканга күрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Туй күлмәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Көтәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Ярата белгән кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Айлы-Кояшлы дөньям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Мәңгелек буласым килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Зәңгәрлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Җырлы кичләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Синең хатларың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Яшьлегем төсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Йолдызым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

Соңгы сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Мин әле килермен . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Чәчәк язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Илһам китерер сәлам . . . . . . . . . . . . . . 130
Минеке бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Елмаясың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Яшьлегемә кайттым . . . . . . . . . . . . . . . 135
Соң түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Сөю кайнарлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . 138

Литературно-художественное издание

ШАФИКОВА Каусария Фидаиловна

СЛЕЗИНКИ — КАПЕЛЬКИ СЕРЕБРА

новеллы

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире *Сабир Шәрипов*
Мөхәррире *Динә Морзакаева*
Рәссамы *Рида Шәйхетдинова*
Бизәүче мөхәррире *Азат Мөхтәруллин*
Техник мөхәррире *Наилә Зарипова*
Корректоры *Зилә Адыева*

Нәшр. лиц. № 0163, 10.04. 96. Җыярга бирелде 17.05.2000. Басарга кул куелды 26.07.2000. Кәгазь форматы $70 \times 90^1/_{32}$. Офсет кәгазе. Тип Таймс гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды. Шартлы басма таб. 5,26. Шартлы буяу отт. 5,55. Исәп-нәшер таб. 4,77. Тиражы 3000 данә. Заказ № 309.

Башкортстан «Китап» нәшрияты. 450001, Уфа, Левченко урамы, 4а.
Уфа полиграфия комбинаты, 450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.


Нәсерләр
Парчалар